Равил Шәймәрдәнов

Китәрбез, калырсыз сез дә бер көн,
Булырбыз килмәгәндәй монда бер көн.
Ризаэддин Фәхретдин

Таишлыяр авылы архыннан сәхифәләр

Казан
«Халкыбыз мирасы» нәшрияты
2020

УДК908
ББК29,89
Ш17

Шәймәрдәнов Равил Шамил улы –
проектның авторы һәм төзүчесе

Әдәби мөхәррире – **Фоат Садриев**

Җаваплы мөхәррире – **Рөстәм Сәрвәров**

Мөхәррире – **Рәшит Минһаҗ**

Шәймәрдәнов Равил

Ш17 Ташлыяр авылы тарихыннан сәхифәләр. – Казан: «Халкыбыз мирасы» нәшр., 2020. 176 б.

Китапта Мөслим районының Ташлыяр авылы, аның топонимнары, хәзергесе, тарихи фоторәсемнәр, нәсел шәҗәрәләре, авылның мактаулы, күренекле шәхесләре турында язылган.

ISBN 978-5-905160-19-6

© Шәймәрдәнов Равил, төзү, авторлык, 2020
© «Халкыбыз мирасы» нәшрияты, 2020



Кереш сүз

Еллар уза тора, буыннар алмашына. Һәр яңа буын килгән саен тарих арткарак чигенә, онытыла бара. Һәр кешегә үзенең кем икәнен, нәселенең, туган-үскән җиренең тарихын белү фарыз. Шундыйрак уйлар миндә, инде олыгаеп килгәндә, туып-үскән авылым Ташлыяр, аның кешеләре, үзем белгән хәтле фактлар турында язып калдыруга этәргеч булды.

«Кәгазьгә төшкән мәңгегә кала, төшмәгәне онытыла», – дип язган халкыбызның бөек акыл иясе Ризаэддин Фәхретдин. Бу язмалар бигрәк тә киләчәк буыннар өчен кирәк булыр, дип уйлыйм.

«Без барыбыз да җирдә кунак кына: шуның өчен дөньядан кунактан киткән шикелле, әйберләреңне җыярга да, хуҗаларга рәхмәт әйтеп, тыныч кына китәргә кирәк», – дип әйтеп калдырган икенче бөек акыл иясе Гомәр Хәйәм. Безнең буынга да әйберләрне җыя башларга вакыт җитеп килә. Шуның өчен, соңга калмыйча, бу язмаларны бастырып калдыру минем өчен бик тә мөһим.

Ошбу хезмәтне язганда мин авылыбызның хөрмәтле зыялыларының берсе, озак еллар мәктәп директоры һәм тарих укытучысы булып эшләгән Мәхмүт абый Фәтхуллинның язып калдырган хезмәтләрен, ул оештырган архив материалларын файдаландым. Шулай ук авылыбызның зыялысы, сугыш һәм хезмәт ветераны Тәһир абый Зариповның истәлекләрен һәм киңәшләрен кулландым. Тәһир абыйның киңәше дә миңа ошбу хезмәтне язарга этәрде. Татарстан һәм Башкортстан Дәүләт архивлары мәгълүматлары да, тарихка караган фәнни һәм әдәби әсәрләр дә, төрле газета-журналларда басылган материаллар да кулланылды. Язмам «Авыл тарихы» дип аталса да, чиста фәнни хезмәт калыпларыннан тайпылып, истәлекләр формасында бәян ителде. Авылыбызның бик күп хөрмәтле һәм бу язмада искә алырга лаеклы кешеләре, исемнәре искә алынмаган өчен (бигрәк тә хезмәт ветераннары) үпкәләмәсен иде. Барысын да язу мөмкин түгел.

Автор.

Борынгы тарих

Ташлыяр авылы (урыс телле рәсми кәгазьләрдә «Ташлияр татарский» буларак та билгеле) ике елга аръягындагы тигез калкулыкта, Мәллә елгасының сул як ярында, район үзәге Мөслимнән 17 чакрым ераклыкта урнашкан. Авылның икенче (төньяк) ягындагы зур булмаган Кәүҗияк елгасы, Сарман районы территориясендә башланып, Мәллә елгасына сул як кушылдык булып, Ташлыяр авылыннан түбәнрәк бер чакрым чамасы урында килеп кушыла. Мәллә елгасы хәзерге Азнакай районы, Мәлбагыш авылы җиреннән, чишмә булып башланып, 50–60 километр ара үтеп, Мәлләтамак авылы янында, Ык елгасының сул ягына килеп кушыла. Мәллә елгасы буенда тагын Мәсәгут, Кәкре Елга, Митрофановка, Чуар Абдул, Мәндәй (Азнакай районына керәләр), Яхшы Каран, Кетес, Рантамак (Сарман районы), Элемтә, Михайловка, Туйгелде, Игенче (Мөслим районы) авыллары урнашкан.

Элегрәк Яхшы Каран белән Рантамак авыллары арасында, елганың сул як ярында – бер генә рәтле Шуран дигән, шулай ук сул як ярда Элемтә авылына каршы гына 10–15 йорттан торган Николаевка исемле урыс авыллары бар иде. 1960–70 елларда бу авыллар, бик күп урыс авыллары кебек, күчеп, таралып бетте. Авылыбызның икенче ягындагы Кәүҗияк елгасы җәй көннәрендә урыны белән җәяү чыгарлык булып саега. Ә яз көннәрендә шушы кечкенә елга бик нык ташый иде. Бабаларыбыз бу елганы буып, тегермән дә корып караган. Әмма һәр елны язгы ташу буаны да, тегермәнне дә агызып китү сәбәпле, кабат анда тегермән кормаганнар.

Тарихта сакланган мәгълүматлардан күренгәнчә, 1735–1740 елларда Ташлыяр авылына Саба якларыннан күчеп килгән кешеләр нигез салган. Ташлыяр сигезьеллык мәктәбендә (хәзер ул Михайловка урта мәктәбенең филиалы) авылыбызның укымышлыларыннан берсе – Мәхмүт абый Фәтхуллин оештырган туган якны өйрәнү музеенда акчалар коллекциясе бар. Бу акчалар барысы да безнең авыл җирлегеннән табып тупланган. Шул коллекциядәге бакыр акчалардан иң «карт»ларының 1733, 1740, 1792 елларда сугылганы күрсәтелгән. Авыл зиратындагы иске кабер ташларындагы язулардан күренгәнчә дә, Ташлыярга XVIII гасыр башларында нигез салынган дип әйтергә тулы нигез бар (Фәннәр академиясе тикшеренүләреннән күренгәнчә, исән калган кабер ташларыннан Биби Гафифә Муса кызы – 1887 елгы, Фәйзулла бине Хәйрулла – 1902 елгы).

Авылыбыз җирләре Казан ханлыгы басып алынгач, 16–18 гасырларда башкорт биләмәләре булган һәм Уфа губернасына караган. Гомумән, татарларның Идел буйларыннан Урал якларына күпләп күчүләре Казан ханлыгы урыслар тарафыннан басып алынгач башлана. Халыкның күпләп күчү чоры XVIII гасырның беренче яртысына туры килә. XVIII гасыр урталарында татарларның

саны Урал буе өлкәләрендә – 89 меңгә, ә гасыр азагында 219,2 меңгә җитә (Исхаков Д.М. – Популярный очерк этнической истории и демографии татар, 1999). Безнең бабаларыбыз килеп урнашканчы, бу урында элек Балтач исемле мари авылы булган. Аларның авылы хәзер Тоба асты дип йөртелә торган, Кәүҗияк елгасының уң як ярында урман полосасыннан алып зиратка кадәр сузылган булган. Әле безнең бабаларыбыз Мәллә елгасы буена килеп урнашканчы, марилар Пучы якларына күчеп киткән.

1852 елгы сан алу документлары буенча, беренче күчеп килүчеләр барлыгы 85ләп хуҗалык тәшкил иткән. Алар арасында Мусин Гамир, Ишморатов Хәйбулла, Әхмәтов Габсаттар, Мөхәммәтрәхимов Асылгәрәй һәм башкалар була. Беренче күчеп килүчеләр арасында Сәйфетдин дигән кеше дә булуы мәгълүм. Авылда яшәгән һәм яшәүче Фәтхуллиннар нәселе менә шул Сәйфетдиннән килә.

Безнең бабаларыбыз бу җирләргә нинди кануннар нигезендә килеп урнашкан соң? Бу сорауга җавап бирү өчен тарихка күз салырга кирәк. Хәзерге Оренбург өлкәсе, Башкортстан Республикасы урнашкан җирләр 16–18 гасырларда башкортларныкы булган. Урыс дәүләте Урта Азия төрки дәүләтләре, беренче чиратта, Казах ханлыгы белән чикләрне билгеләү һәм саклау өчен Оренбург губернасы оештыра. 1735 елда губернаның үзәге Оренбургка крепость буларак нигез салына. Анда яшәүче урысларга «казак» сословиесе бирелә (Оренбургские казаки). Бу җирләрдә, урыслардан тыш, башкортлар, казахлар (аларны ул вакытта кыргызлар дип йөрткәннәр) һәм татарлар яшәгән. Мәсәлән, Оренбургтан ерак түгел генә урнашкан зур татар Сәет бистәсе (Каргалы) тарихта үзенең мәдрәсәсе, бай сәүдәгәрләре белән билгеле.

1865 елда Оренбург губернасыннан Уфа губернасын аерып чыгаралар. Башкорт тарихчылары бу вакыйганы башкортны бүлгәләү акты дип саный. (Юлдашбаев Б.Х. История формирования башкирской нации (дооктябрьский период), Башкортстан китап нәшрияты, Уфа, 1972).

1863 елда чыккан «Положение о башкирах» дигән документта күренгәнчә, башкорт җирләре күмәк файдалануда (общинное владение) була. Общинаның һәр кешесе үзенең өлешенә тигән җирне бүлеп ала һәм сата алган. Гадәттә, башкортлардан җирне урыслар һәм күчеп килгән башка халыклар, сәүдәгәрләр сатып алган. Башкортлар шәһәрләр төземәгән. Уфа, Стәрлетамак, Бәләбәй, Бөре (Бирск), Златоуст шәһәрләрендә 1865–1869 елларда барлыгы 500 башкорт (бу шәһәрләр халкының 0,93%ы) яшәгән (Юлдашбаев Б.Х., 1972).

1798 елдан 1865 елга кадәр башкортлар белән идарә итү формасы буларак, кантон системасы кулланылган. Ул ярымхәрби, регуляр булмаган казаклар сословиесенә охшаш булган. Урыс дәүләте башкортларны төрле сугышларда файдалана. Мәсәлән, 1812 елгы урыс-француз сугышында башкорт гаскәрләре дә катнаша. Алар Парижга кадәр барып җитә. Башкорт халкының «Кутузов», «Любизар», «Баек», «Француз көе», «Колой кантон», «Каһарман кантон» җырларында шушы заман чагылыш тапкан. Башкорт гаскәрләре составында татарлар да катнаша.

Югарыда әйтелгәнчә, башкортларның буш, эшкәртелмичә яткан җирләре

күп булган. XVIII гасырның икенче яртысында һәм XIX гасырның башларында бу җирләргә күпләп урыслар, татарлар, мещеряклар (мишәрләр), мукшылар (мордва), черемислар (марилар) күчеп килә. Башкорт җирләрен үзләштерүнең берничә юлы булган: беренчесе – Урыс хөкүмәте үзенең дәүләт эшлеклеләренә, югары чиндагы хәрбиләренә, дәүләт алдындагы хезмәтләре өчен, җирләр бүләк иткән. Мәсәлән, безнең районның хәзерге Михайловка авылы җирләре Россиянең күренекле дәүләт эшлеклесе, тышкы эшләр министры, 1867 елдан канцлер (премьер-министр) Александр Михайлович Горчаков (1798–1863) биләмәләре булган. Бу җирләргә ул 1852 елда Орлов губернасы, Елецкий өязенең Вознесенский авылыннан үзенең крепостной крестьяннарын күчергән (12 гаилә). Атасы хөрмәтенә авылны Михайловка дип атаган. Шулай итеп Михайловка авылы 12 крепостной крестьян гаиләсеннән башланып киткән. А.М. Горчаков, әлбәттә, Михайловкада булмаган. Ул Царское Село лицеен тәмамлаган. А.С. Пушкин аның турында: «Питомец мод, большого света друг, обычаев блестящих наблюдатель», – дип язып калдырган.

Хәзерге Элемтә авылы җирләре боярлар Алексей һәм Александр Кукаркиннарныкы булган. Атлас авылы җирләрендә Тамбов губернасыннан Пальчиков фамилияле бояр хуҗа булган. Ул үзе Петербургта яшәгән. Тарихта Пальчиковның Минзәлә шәһәрендә кирпечтән беренче буларак больница төзетүе мәгълүм. Атлас авылы урынында гаиләсе белән аның управляющие Павел яшәгән. Аның турында соңрак әйтелер. Башкорт җирләрен үзләштерүнең икенче юлы – җирләрне сатып алу була. Күренекле урыс язучысы С.Т.Аксаков үзенең «Семейная хроника» дип аталган әсәрендә бабасы – Сембер губернасы бояры Багровның ничек башкортлардан җир сатып алуын тәфсилләп язган. Ул әүвәл башкорт җирләрен карап кайта. Дим, Ык елгалары буендагы төрле җәнлеккә бай урманнарга, күп балыклы елга-күлләргә, кара туфраклы уңдырышлы җирләренә соклана. Башкорт җир биләүчеләреннән җир сатып алгач, үзенең крепостной крестьяннары белән күчеп килә.

Башкорт җирләрен үзләштерүнең өченче юлы – килешү (договор) нигезендә билгеле вакытка (елларга), билгеле бәягә һәм билгеле шартлар нигезендә урнашып, җирдән файдаланып яшәү, хәзергечә әйтсәк, арендага алу юлы булган. Бу юл белән җиргә килеп урнашкан кешеләр припущенниклар дип аталган. С.Т.Аксаков үзенең югарыда искә алынган әсәрендә: «Припущенники, люди, которые за известную единовременную плату, по заключенному договору на известное число лет, живут на башкирских землях. По истечении срока договора почти ни одна деревня припущенников не оставили земли башкирские. Из этого завелись сотни дел, которые обыкновенно заканчивались тем, что припущенники оставляются на месте своего жительства с нарезкой пятнадцати десятинной пропорции на каждую ревизскую душу по пятой ревизии (десятина – 1,09 га, пятая ревизия – 1795 елда халык санын алу. *Р.Ш.* искәрмәсе). Вот так перешло огромное количество земель Оренбургской губернии в собственность татар, мещеряков, чувашей, мордвы и других казенных поселян», – дип язган.

Договор срогы чыккач, припущенниклар аз җирле крестьян булып кала (җан башына 0,109 га – 5 сутый). Һәм типтәрләр сословиесенә керә. Минзәлә

өязендә 1880 елда 3336 припущенник (душ) яшәгән. Алар арасында мишәрләр, типтәрләр һәм татарлар булган. (Юлдашбаев Б.Х. «История формирования башкирской нации». 1972, стр. 107).

XVIII гасыр башларында Сабадан күчеп килеп безнең авылга нигез салучылар, күрәсең, припущенниклар булган. Чөнки алар гомерләр узу белән, килешү срогы чыккач, аз җирле крестьян булып калган. Аларны «жителләр» дип йөрткәннәр. Жител атамасы «житель» сүзеннән алынган булырга тиеш – «припущенный житель». Бу термин хәзер дә кулланыла. Авылның түбән очында һәм урталыкта яшәүчеләрен жителләр дип йөртәләр.

Авылга Ташлыяр исеме кушылуның нигезе төгәл генә билгеле түгел. Тарихта безнең авыл «Ташлияр татарский» буларак билгеле. Шул ук Саба якларында Теләче районына керә торган «Ташлияр русский» дигән урыс авылы да бар (ул авылны Мочалино дип тә йөртәләр). Бәлки, авылның Ташлыяр дип аталуында бу фактның берәр бәйләнеше бардыр. Татарда таш сүзе белән бәйләнгән топонимнар еш очрый: Ташкичү, Ташъелга, Ташкүпер, Ташлыяр, Акташ һ.б. Әйтергә кирәк, элек безнең авыл урамнарында таштан өелгән коймалар күп иде. Әле хәзер дә Шәфыйкова Мәрьямнәрнең таштан өелгән урам коймалары исән. Мәхмүт Фәтхуллин авылның исемен Мәллә, Кәүҗияк һәм Каран елгалары ярларында таш күп булуга бәйледер дип саный.



Ташкойма

Аблаковлар

Авылның югары очында яшәүчеләрне «Аблаклар» дип атыйлар. Кемнәр соң ул Аблаклар?

Байлар Сабасында XVIII гасыр азагында һәм XIX гасыр башында Аблаков фамилияле бай яшәгән. Ул мануфактура фабрикасы тоткан. Аның бәз туку мануфактурасында 600–700 кеше хезмәт куйган. Алар арасында калмык, мордва, чуаш, мари һәм башка милләт кешеләре дә эшләгән һәм үзләренең аерым бистәләрендә яшәгән. Сабада әле дә онытылмаган калмык очы, чирмеш зираты исемнәре моңа дәлил. Истәлекләр буенча, фабрика Саба мәдәният йорты тирәсендә урнашкан булган. Аблаковлар зур кавем тәшкил иткән. Алар үз кавемнәренең әрвахлары өчен зиратларын кирпеч диварлар белән әйләндереп алган. Ирләр һәм хатын-кызлар өчен ике зират булган. Чардуган-төрбәләренең биеклеге гадәти өй биеклегенә җиткән. 1930 елларда Саба районы оешкач, Байлар Сабасында әлеге чардуган-төрбәләрне сүтеп, кирпечен мәктәп һәм банк биналарын салганда файдаланалар (Тәлгать Нәҗмиев, Мәгъсум Хуҗин. – Яшә Сабайорт. 1999. 272 бит). Күрәсең, бәзне Аблаков урыс хөкүмәте өчен дә җитештергән. Аның патша исеменнән медаль белән бүләкләнгәне билгеле. Бәз мануфактурасыннан башка, Бикчәнтәй һәм Монасыйп Аблаковларның Янбай авылында тире эшкәртү һәм поташ заводлары булуы билгеле. (История Татарстана в документах и материалах. Таблица: «Состояние промышленности в Татарии в 1812 году, 286 бит).

Саба авылы кешесе, укытучы-пенсионер Равил Гомәров Татарстан дәүләт архивы фондындагы халык санын алу документларын өйрәнеп («Ревизские сказки». 1834, 1850, 1858 гг.) Аблаковларның Сабага Мамадыш шәһәреннән күчеп килүчеләр икәнен ачыклаган. Алар мещаннар булган. (ТР дәүләт архивы, фонд 3, опись 2, дело 54, лист 4 б; Ревизские сказки 1850 г. октября 24 дня. Казанская губерния, г. Мамадыш). 1835–1840 еллар тирәсендә Аблаковка ялланып эшләүчеләр бунт күтәрәләр, фабрикага ут төртеп, зур янгын чыгаралар. Фабрика бөтенләй янып бетә һәм бүтән торгызылмый. Аблаковлар кавеме Сабадан төрле якларга тарала. Шуларның бер төркеме 1840 елларда Ташлыяр авылына күчеп килә. Алар башта үзләренең авылын Кәүҗияк елгасының Мәллә елгасына кушылган урында төзиләр һәм аны Кәүҗияк-Тамак дип атыйлар. Һәр язда су басу аркасында безнең авылның югары очына (Ташлыярдан аерым) күченәләр һәм үзләренең авылын элеккечә Кәүҗияк-Тамак дип йөртәләр. Архив документларыннан күренгәнчә, 1852 елда безнең якларның административ бүленүе болай булган:



Озак еллар Кәүҗияк-Тамак һәм Ташлыяр аерым авыллар булып яши. Соңрак бергә кушылып, Ташлыяр авылы дип йөртелә башлый. Октябрь революциясеннән соң, Кәүҗияк-Тамак авылы исеме рәсми документларда кулланылмый һәм бөтенләй онытыла.

Сабадан күчеп килүче Аблаковлар башында отставной солдат Аблаков-Мусин Сәйфулла була. Ул 1852 елда Кәүҗияк-Тамакта үлә.

Аблаковлар күп җирләрне сатып алалар. Мәллә елгасы ярыннан, Абдуллин Нәсимнәр тыкрыгыннан имәнлеккә кадәр һәм Петровка авылы белән чиктәш җирләр Аблаковларныкы була. Бу җирләрне сатып алуны һәм рәсмиләштерүне Аблаков-Мусин Сәйфулланың улы Гарифулла башкара. Ул 1838 елда туган. 1914 елда 76 яшендә Кәүҗияк-Тамак авылында үлә. Архив документларда Аблаков-Сәйфуллин Гарифулла исеменә бирелгән таныклыкларның күчермәләре сакланган. Алар биредә китерелә.

Билет 1881 года

Предъявитель сего крестьянин Мензелинского уезда Уфимской губернии Александро-Карамалинской волости деревни Ковзияк-Тамак Гарифулла Сайфуллин-Аблаков отпущен от Карамалинского волостного правления для жительства в разных губерниях, сроком нижеподписанного числа сроком на 1 месяц. Если же в течении месяца после сего срока не явится, то с ним поступлена будет как с бродягою. Дан в десятый день сего июня месяца тысяча восемьсот восемьдесят первого года.

Волостной старшина: Назаров.

Писарь: Маркелов.

№ 299. Приметы: лета 42, рост 2 ар., 7 верш., волосы, брови русые, глаза карие, нос, рот, подбородок обыкновенные. Лицо чистое. Особые приметы: не имеются.

Искәрмә: 1 аршин – 71 см, 1 вершок – 4,4 см. Димәк, Гарифулланың буе 1 м 73 см тирәсендә булган

Икенче документ. Удостоверение


Александро-Карамалинского Дано сие от Ал.-Карамалинского Волостного
Волостного Правления Правления о том, что предъявитель сего есть
Мензелинского уезда Уфимской губернии действительно крестьянин здешней волости,
дер. Ковзияк-Тамака Гарифулла Сейфуллин
Сентябрь 1904 г. Аблаков, 64 л.
Волостное Правление и удостоверяет.
Волостной старшина: Ризванов.
Писарь: Соколов.
Печать.
Подписи.

Искәрмә: Волостной старшина – Ризванов Әбубәкер, Мәндәй авылы кешесе, минем әбием – әтиемнең әнисе – Аблакова Фагыйләнең (кыз фамилиясе Ризванова, ул Мәндәй авылыннан) атасы Әсәдулланың бертуган энесе.

Аблаков Гарифулланың Минзәләдә дә йорты булган. Ул өяз почтасында эшләгән. Картларның сөйләве буенча, үзенең яхшы атлары белән Минзәлә белән Ташлыяр авылы арасын (60–70 чакрым) ике сәгатьтә үтә торган булган.

Аблаковларның җирләре нәселдән нәселгә күчкән. Ташлыяр авылының башка җирләре община карамагында булган. 1862 елда община җирләрен, шобага салып, яңадан бүлгәннәр. Ләкин авылдагы 226 җанга гына (ирләр җенесеннән) җан башына 7шәр дисәтинә исәбеннән бүленеп бирелгән. Хатын-кызлар һәм 1862 елдан соң туган ир балалар да җирсез булган. Җирләр 1904 елга кадәр яңадан бүленмәгән.

Биредә Аблаков-Мусин Сәйфулланың нәсел шәҗәрәсе китерелә.



Аблаков Сәйфулла шәҗәрәсе

Равил Шәймәрдәнов төзеде

Бикмөхәммәт мулла – югары оч мәчете мулласы. 1931 елда кулак дип игълан ителеп, Урта Азиягә сөргенгә сөрелгән.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы архивы материалларыннан күренгәнчә, Аблаков Бикмөхәммәт Гарифулла улы Мөслим районы Башкарма комитетының 1931 елның 12 июнь карары нигезендә, балалары Тажимөхәммәт, Шәмсемөхәммәт, Рифгать, Әнвәр, Әхәт, Мәрьям һәм хәләл җефете Хәерлефатиха белән Урта Азиягә сөргенгә сөрелә. 1993 елның 22 мартында барысы да аклана.

Бикмөхәммәт мулланың Шәмсемөхәммәт исемле улы Ташлыяр авылы тарихында беренче булып Минзәлә шәһәрендәге урыс гимназиясен тәмамлый (мулла малае!). Соңрак, сөргенгә сөрелгәч, югары юридик белем ала. Казахстанда өлкә прокуроры булып эшли. Тажимөхәммәт исемле улы Гражданнар сугышы чорында акларда офицер булып хезмәт итә. Мин хәтерлим: илленче еллар уртасында аның Әхәт исемле улы авылга кайтып йөрде, Сабуров Гафур абыйларда (күршеләре) туктала иде.

Югары очның су буенда ике рәт бик мәһабәт тупыллар үсә иде. Алар – Бикмөхәммәт мулла утырткан тупыллар. Без, сугыш һәм сугыштан соңгы чорның югары оч малайлары, шушы тупыллар башына үрмәләп үстек. Авылга кайтканда, ерактан беренче булып зират агачлары һәм шушы тупыллар күренә иде. Кызганычка каршы, бакчада бәрәңге үстерми, дип әлеге тупылларны кисеп бетерделәр.

Аблаков Шәмсемөхәммәт улы Нурмөхәммәт (Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт, 1899–1979) – Аблак нәселеннән. 1975 елда миңа Казанда Нурмөхәммәт абыйның ашказанына операция ясарга туры килде. Без аның белән озаклап сөйләшеп утыра торган идек. Хәтере яхшы: авылны сагынып сөйли иде. Нурмөхәммәт абый әтисеннән 8 яшендә ятим калган. Әнисе икенче иргә кияүгә чыккач, түбән очта үскән. Үги әтисе үлгәч (Нурмөхәммәткә 13 яшь була), ул Чаллыда байларда батрак булып хезмәт итә. 19 яшендә Кызыл Армиягә китә, анда партиягә керә. Армиядән кайткач, Рантамак авылында укытучы булып эшли. Ташлыяр авылы кешесе, танылган журналист Сәләхетдинов Зыятдин (Зыя Сәләхи) белән авылда беренче партячейка төзиләр. Нурмөхәммәт абый соңгы елларда Шуганка авылында яшәде, укытучы булып эшләде.

1861 елгы реформадан соң, Ташлыяр авылында бары тик Аблаков фамилияле кешеләргә генә җир бирелгән. Бу фамилияне барысы 28 кеше йөрткән. Алар: Әпсәләм, Әбелкасыйм, Абдулла, Талип, Зариф, Сәхәбетдин, Мостафа, Кәрим, Морзахан, Монасыйп, Муса, Гайсә, Садыкай, Вәлкәй, Афзал, Гайфулла, Миндияр, Юныс, Шәймәрдән, Әхмәтхафиз, Сабиржан, Гарифулла (Бикмөхәммәт), Сабур, Сафа, Закир, Шакир, Латыйп исемле кешеләр. 1897 елгы халык санын алу мәгълүматларыннан файдаланып, авылыбыз зыялыларыннан берсе – Таһир абый Зарипов (Аблак нәселеннән) Аблаковлар урамының картасын ясаган. Биредә шул карта китерелә

Садыкай		Сәрвәретдин
Афзал		Гайсә
Вәлкәй		Муса
Гайфулла	Авыл урамы	Монасыйп
Миндияр	(Югары оч)	Тыкрык
Юныс		Морзахан
Шәймәрдән		Кәрим
Әхмәтхафиз		Мостафа
Сабиржан		Сәхбетдин
Тыкрык		Тыкрык
Бикмөхәммәт		Зариф
Сабур		Талип

Закир	Әбелкасыйм
Шакир	Әпсәләм
Латыйп	Мәчет

Архив документларыннан күренгәнчә, Аблаков фамилиясен Шәймәрдән бабай үзенең ике олы баласына гына (Бану, Шәйсолтан) яздырган. Калганнарының фамилияләрен үз исеме белән атаган – Шәймәрдәновлар. Хәзерге вакытта авылда Аблаков фамилиясен йөртүче юк.






Е.Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесе чорында безнең як

1773–1775 еллардагы крестьяннар восстаниесе хәрәкәте безнең төбәкне дә читләтеп узмаган. 1773 елның 11 ноябрендә Юзеево авылы янында (Оренбург өлкәсе) Пугачев армиясе хөкүмәт гаскәрләрен тар-мар иткән. Бу җиңүдән соң, Минзәлә, Алабуга, Зәй, Бөгелмә, Бакалы тирәсендәге җирләр баш күтәрүчеләр кулына күчә. Пугачевның якынлашуын ишетеп, 1773 елның октябрендә Ногайбәк крепостенда һәм аның якын-тирәсендә восстание башлана. Ногайбәк казакларының командиры итеп В.И.Тернов сайлана. Ул башкорт һәм татарлардан торган 400 кешелек отряд оештыра. Анда Олы Чакмак авылыннан Габделкәрим Рахманкулов дигән кеше җитәкчелегендә бер отряд була. Рахманкулов бик кыю һәм батыр кеше булган, старшинадан полковник дәрәҗәсенә күтәрелгән. Пугачев хәрәкәтенә безнең якларда яшәүче крестьяннар да актив катнашкан.

Казан губернаторы Мещерскийның патша хөкүмәтенә язган рапортында баш күтәрүче крестьян отрядлары булган авыллар саналган. Алар арасында: Тугаштан – 500, Ташлыярдан – 60, Крәш-Шураннан – 50, Дусайдан – 200, Катмыштан – 100, Чишмәдән – 150, Күбәктән 400 кеше катнашканы күрсәтелгән. Бу факт Ташлыяр авылының XVIII гасырның икенче яртысында шактый зур авыл булганын күрсәтә.



Октябрь революциясенә кадәрге чорлар

Административ яктан безнең авыл 1919 елга кадәр Уфа губернасы, Минзәлә өязе, Карамалы-Александровка волостена караган. Бу волостька тагын Тат.Шуган, Чуар-Абдул, Мәндәй, Буралы, Яхшы Каран, Рангазар, Кәүҗияк, Петровка (б.к), Михайловка, Балтамак авыллары кергән. Алар үзара бик аралашып яшәгәннәр, бер-берсенә килен төшергәннәр, кызларын кияүгә биргәннәр.

1919-1920 елларда Башкортстан һәм Татарстан Автономияле Республикалары төзелә. Минзәлә өязенең күп өлеше, шул исәптән, Карамалы-Александровка волосте да ТАССРда калдырыла. Безнең авылның 1919 елга кадәрге документлары Башкортстан дәүләт архивында саклана. Тарихи документларга караганда, («Сборник статистических сведений по Уфимской губернии, часть П, Список земельных владений губернии», 1901), Ташлыяр башкорт авылы саналган. 1896 елда анда барлыгы 822 кеше яшәгән. Шулардан ирләр – 401, хатын-кызлар 421 кеше булган. Карамалы-Александровка волостенда тагын 5 авыл башкорт авылы саналган. Аларның урысча исемнәре:

1. Балыклы (Баланны) – 451 кеше.
2. Мендеево (Мәндәй) – 80 кеше.
3. Тангазар-Тамак (Рантамак) – 276 кеше.
4. Тукметово (Тукмәт) – 222 кеше.
5. Ушуган (Өшегән, Тат. Шуган) – 930 кеше.



Яңа Ташлыяр авылы гомер кичергән урындагы язу тактасы

«1882 елда Уфа губернасында 881617 башкорт саналган. Ләкин алар этник чыгышлары белән барысы да башкорт булмаган. XVIII гасырның башында башкорт җирләренә күчеп килгән башка халыкларны (татар, мишәр, мордва, черемис һ.б.) башкорт сословиесенә керткәннәр һәм аларны яңа башкортлар дип йөрткәннәр. XVIII гасырда һәм XIX гасырның башларында «башкир из черемис» гадәти атама булган.» (Юлдашбаев Б.Х. История формирования башкирской нации. Уфа, 1972).

Әйткәннәрдән чыгып, Ташлыярны башкорт авылы дип атар өчен бернинди дә нигез юк. Аннан соң без үзебезнең бабаларыбызның Сабадан күчеп килгән татарлар икәнен яхшы беләбез.

Яңа Ташлыяр авылы оешу

Столыпин реформасы чорында (1910–1913 еллар) Кәүҗияк-Тамак авылыннан 20–30 крестьян хуҗалыгы Карамалы-Александровка волостеның Буралы авылыннан ерак түгел урында 1870 дисәтинә җир сатып алган һәм үз авылын оештырган. Бу эшнең башында Аблаковлар һәм Ихсанов Шәйхелисламнар булган. Авылларын Яңа Ташлыяр дип атаганнар. Халык арасында аны «Буклы» дип тә йөрткәннәр. Бу авылдан атаклы татар артистлары Нәҗибә Ихсанова һәм Әзһәр Шакиров чыккан. Нәҗибә Ихсанова – әлеге авылга нигез салучы Ихсанов Шәйхелислам нәселеннән. Хәзер бу авыл таралып беткән, зираты гына сакланган.

Столыпин реформалары чорында Горчаков җирләрендә вак, кечкенә авыллар барлыкка килгән. Урыслар аларны «отруб» дип йөрткән. Алар арасында:

Чия-Түбә (Вишневка).

Каен-Түбә (Березовка) – Чия-Түбәдән ерак түгел урман буенда урнашкан булган.

Таллы Елга (Лозняк) – хәзерге вакытта Салатовка дип йөртәләр.

Камышлы (Камышовка) – хәзерге Элемтә һәм башкалар.


Бүгенге көндә бу авыллардан Чия-Түбә, Элемтә һәм Таллы Елга (Салатовка) гына сакланып калган. Саналган хутор-отрубларда Туйгелде, Ташлыяр, Утар-Тимеркәй (Рантамак) һәм башка күрше-тирә авыллардан күчкән крестьяннар яшәгән. Мәсәлән, Чия-Түбә авылында Ташлыярдан – Сабуров Шәкүр, Таллы Елгадан – Шәрифуллин Сәхәбетдин, Каен-Түбәдә Шәрифуллин Сәләхетдин торган. Беренче империалистик сугыш елларында (1914–1915) Буралы авылы сәүдәгәре Әхтәмов Нурмөхәммәт хаҗи Горчаковның управляющиеннан 35 дисәтинә җир сатып ала. Хәзерге «Михайловка» совхозының үзәк утары турында, Мәллә елгасында буа буып, ташлы тегермән төзетә. Тегермән Америкадан кайтартылган тимер турбиналар белән эшләгән. Аның эшләп чыгарылышы зур булган. Бу тегермәнне коруда якын-тирә авыллар – Михайловка, Ташлыяр, Рантамак, Петровка һ.б. авыл крестьяннары катнаша. Заманында бу тегермәндә безнең авылдан Ибраһимов Вәли, Фәтхуллин Гомәр, Гәрәев Миңнәхмәтләр ялланып эшли.

1929 елда байларны эзәрлекләү башлангач, Әхтәмов Нурмөхәммәт хаҗи семьясы белән качып китә. Аның качып китүен Ибраһимов Вагыйз оештыра. Тегермән буасы язгы ташу вакытында җимерелә һәм яңадан торгызылмый. Буаның дамбасы калдыклары әле хәзер дә Мәллә елгасының сул як ярында авылның югары оч башында калкып тора. Тирән чокырда кечкенә күл барлыкка килгән. Бу урыннарны хәзер дә буа башы дип атыйлар.

1914 елда Беренче Бөтендөнья сугышы башлана. Бу сугышка яше кергән авылдагы барлык ирләр мобилизацияләнә. Мәсәлән, Камалов Шәмсемөхәммәт пленда булган («камрат» кушаматы шуңа бирелгән). Мифтахов Гыйльфан Австриядә пленда булган. Мин авылда фельдшер булып эшләгәндә (1958–1960 еллар), ул медпунктка еш керә иде (йорты урам аркылы гына), үзенең Австрия бюргерында хезмәт иткәннәрен сөйли иде. Сугыштан гарипләнеп кайтучылар да була. Сөләйманов Галимәрдән, Гобәйдуллин Зиннурлар – сыңар аякларын, Вил-

данов Имаметдин ике бармагын өздереп кайткан. Җәләев Фәрхетдин, Бакиев Сабиржан, Камалов Якуб һ.б. бу сугыштан исән-имин кайтканнар. Үлеп калучылар да булган. Гомумән, бу сугышта татарлар күп катнашкан. Татар халкының «Герман көе» шушы елларда туган.

1874 елда, патша Александр II заманында, яңа гомуми хәрби хезмәт тәртибе кертелә. Яңа устав буенча 21 яше тулган хезмәткә яраклы барлык ирләр армия хезмәтенә чакырыла. Хезмәт срогы 6 ел була. Моңа кадәр рекрут наборы тәртибендә алынган солдат хезмәте 25 ел булган. Безнең авылдан, мәсәлән, 25 ел хезмәт иткән Кәлимулла солдат була. Ул 25 ел хәрби хезмәтен тутырып, өйләнеп, авылга хатыны һәм улы Мостафа белән кайта. Мостафаның Мортаза һәм Шәйдулла исемле уллары туа. Авылда Мостафин һәм Шәйдуллин фамилияләрен йөртүче нәселләр Кәлимулла солдаттан килә.



Безнең якларда бакыр чыгару

XVIII гасырның беренче яртысында Ык елгасының урта һәм түбән агымнарында күп кенә урыннарда бакыр рудасы ятмалары табылган. Барлыгы 16 чыганакның рудага иң бай икесе хәзерге Мөслим районы җирендә урнашкан булган. Безнең авылда да өч урында – Чагыл тавында, Үтәш чокырыннан көнчыгышта һәм Каран коесыннан ерак түгел генә урында бакыр базлары була. Әле XX гасырның илленче елларында «Уба» чокырлары бар иде. Бу чокырлар элек бакыр рудниклары булган. М.Фәтхуллин язып калдырган истәлекләрдә күрсәтелгәнчә, әле 1925–1930 елларда идән-түшәмнәр һәм имән баганалар белән ныгытылган җир асты юллары сакланган. Авыл малайлары хәтта шул шахта базларына төшеп тә йөргәннәр. Соңыннан бу чокырларны үлгән малларны күмү урыны итеп файдаландылар. Хәзер инде алар бөтенләй күмелеп, басу булып калганнар.

Бу шахталардан алынган руда бакыр эретү заводларына озатылган. Безнең якларда Бәгрәш елгасында Иноземцев тарафыннан төзелгән Иштирәк һәм Ольгино авылында бояр Хвощинскийның бакыр эретү заводлары булган. Руданы һәм утынны якын-тирә авылларның крестьяннары җәен – 10, кышын – 20 тиен хисабына олау белән китергәннәр. Казан губернасында да 1720–1760 елларда Саранск, Шилнә, Таишево, Берсут, Мишә, Пижма һ.б. бакыр эретү заводлары төзелә.

Даулы еллар, шанлы еллар...

Революциягә кадәр татар крестьяннары арасында бернинди революцион хәрәкәт формалаша алмаган. Октябрь революциясе хәбәре авылга килеп җиткәч, иң элек Атлас авылының чишмә башы һәм буасы янында урнашкан Пальчиков Павел дигән боярның өенә һәм каралтыларына ут төртеп яндыралар. Пожар вакытында кайбер кешеләр боярның мал-мөлкәтен дә үзләштерә. Мәсәлән, Шәйдуллин Миңнулла көрән алаша алып кайта. Бу вакытта Пальчиковның утарында Бикмәттән килгән Петруха дигән кеше управляющий була. Пожар вакытында ул качып китә. Утарны кем ут төртеп яндыруы турында төрле риваятьләр сакланган. Чынлыкта, утны Ташлыярның бик тыныч холыклы кешесе Фәйзулла төртә. Ул картның балалары – Зәкия апа, Шәйдулла абыйлар әле исән. Бу вакыйганы миңа авылыбыз укымышлыларының берсе, СССР Журналистлар берлеге әгъзасы, Татарстанның өлкән журналисты Сәләхетдинов Зыятдин (Зыя Сәләхи) абый сөйләгән иде. Искәрмә рәвешендә әйтеп китим: Зыятдин абый 1905 елда туган. Аның әтисе Сәләхетдин бабай түбән очта, Мөслимгә китә торган тыкрык буенда (Харисов Зөфәрләргә тыкрык аша гына) бер кечкенә йортта яшәде. Аның бер күзе зәгыйфьрәк иде, шуның өчен аны «Сукыр Сәлах» дип тә йөрттеләр. Заманында ул Яруллин Хөснулла («тишек» Хөснулла) картның әнисенә өйләнгән, шулай итеп Хөснулла бабай белән Зыятдин абый бер ана балалары булып чыга. Семья бик ярлы була. Шуның өчен үзенең малай чагында Гомәр муллаларда батраклыкта булганнарын сөйли иде. Аңа тамак хакына мал карау, су һәм мичкә утын китерү эшләрен башкарырга туры килә. Яшьли Урал якларына чыгып китә, анда рабфакта укый, партиягә керә. Армиягә китәргә яше җиткәч (ул заманда кануннар буенча армиягә туган җиреннән алганнар), авылга кайта. Карамалы-Александровка волостена килгәч, мондый егетләр безнең үзебезгә дә кирәк, дип аны армиягә җибәрмиләр, волостьта калдыралар. Ул волостьның җәмәгать-партия эшенә тартыла, Совет властен урнаштыруда актив катнаша. Сугыштан соңгы елларда ул «Кызыл Татарстан» газетасының Минзәлә ягында (Минзәләдә яшәп) үз хәбәрчесе була. Казанда без аның белән якын танышып аралаша башлаган 70 нче елларда ул Горбунов исемендәге авиация заводы газетасының баш редакторы булып эшләде.



Сәләхетдинов Зыятдин (Зыя Сәләхи)

Зыятдин абыйның сөйләве буенча, байның урманы аркылы ат белән чыккан өчен Фәйзулланы управляющий Петруханың стражниклары тотып алып, агач келәткә бикләп куялар һәм өч көн бай басуында урак урдыргач кына кайтарып җибәрәләр. Революция булып, патшаны тәхеттән төшергәннәр, дигән хәбәр авылга килеп җиткәч, Фәйзулла беренче булып үзе бикләп тотылган келәткә барып ут төртә һәм бөтен утары янып бетә. Бояр Горчаковның Михайловкадагы управляющие качып китә. Бояр җирләре дәүләт файдасына тартып алына. Волость управасы җирләренең шактый өлеше

Михайловка, Удобновка авылы крестьяннарына бүлеп бирелә. Революциядән соң җирләр, болыннар, урманнар бөтен халыкныкы – дәүләтнеке дип игълан ителә.

1917 ел азагында авылда Совет власте урнаштырыла. Халиков Габдерәкыйп, Биккинин Хафизетдин, Вәлиуллин Хөснулла, Бакыев Шәймәрдән, Бакыев Гали, Мәннәнов Хәйбрахман, Мусин Ибраһимнар составында крестьян депутатлары Советы сайлана. Авыл Советы председателе һәм секретаре сайлап куела. Халык җыеннарына (җыелышларга) кешеләр пүнәтәйләр (сельский исполнитель) аркылы авыл уртасындагы пожарный янына чакырыла. Пожарный лапасы Халиков Зиннур абыйлар турында, урам уртасында урнашкан була. Җыелышларга һәр йорттан хуҗа ир, ире булмаса, балигъ булган ир баласы, яки хуҗа хатын (битен каплап) килергә тиеш була.

1918 елның апрель аенда җир бүлү үткәрелә. Басуларны иң элек өчкә бүлгәннәр: уҗым, сабан, пар басулары. Хатын-кызларга да авыл тарихында беренче тапкыр, җир бүлеп бирелгән. Шуннан соң җир бүлү һәр елны яз көне үткәрелгән. Үлгәннәрнең җир өлеше «чикерелгән», яңа туган балалар «душына» җир бүлеп бирелгән. Җан башына кырык атлам (кырыклы дисәтинә) җир бирелгән. Җир бүлү 1930–31 елларга, тоташ коллективлаштыруга кадәр дәвам иткән. Җир бүлү Аблакларда булмаган, чөнки аларның элек-электән һәрберсенең үз җире булган. Дөрес, кайберләре (ялкаулары) үз җирләрен сатканнар яки арендага биргәннәр һәм бөлгәннәр. Алар хисабына икенчеләре (тырышраклары) баеган.

Бүлеп биргән җирләрен крестьяннарның барысы да эшкәртә алмаган. Авылның хәллерәк һәм баерак кешеләре аларның җирләрен арендага алып файдаланган. 1918 елда крестком (крестьяннар комитеты) – комбед (комитет бедноты) оешкач, ярлы крестьяннарга дәүләттән чәчүлек орлык белән һәм башка ярдәмнәр күрсәтелгән.

Авылда Совет власте урнашкач, сугышчан дружина оештырыла. Аның составына түбәндәге кешеләр сайланганнар:

Мәннәнов Хәйбрахман
Фәйзуллин Ибраһим
Габидуллин Фәррах
Мәгалимов Фазлый
Фәтхетдинов Камалетдин
Вәлиев Таҗетдин
Сәетов Динмөхәммәт.

1918 елда илдә Гражданнар сугышы башлана. 1919 елның март башларында Колчак армиясе Уфа, Чишмә, Бөгелмә шәһәрләрен ала һәм Минзәләгә якынлаша. Шушы дәһшәтле көннәрдә авылның түбәндәге кешеләре, үзләре теләп, Кызыл Армия сафларына китәләр:

Вәлиев Таҗетдин
Габидуллин Фәррах
Гаделшин Әюп
Зарипов Һади
Йосыпов Гайсә

Йосыпов Хөсәен
Мәгалимов Фазлый
Мәннәнов Хәйбрахман
Сөләйманов Вәлимәрдән
Сөләйманов Галимәрдән
Фәйзуллин Ибраһим
Халиков Зиннур
Хафизов Бикмөхәммәт
Хәлилов Гыйният



Йосыпов Хөсәен Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан.



Сөләйманов Галимәрдән Сөләйман улы Гражданнар сугышында катнашкан. Яраланып кайта.



Хафизов Бикмөхәммәт Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан.



Халиков Зиннур Рәкыйп улы Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан.



Хәлилов Гыйният (Атлас) Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан.



Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан.

Алар, Минзәлә аркылы үтеп, Кожевников отрядында һәм Азин дивизиясе составында сугышалар. Гражданнар сугышы дәвамында бик күп кешеләр яшь Совет республикасын сакларга алынган. Мәсәлән, Сәетов Динмөхәммәт, Миңнекәев Бикмөхәммәт, Фәтхетдинов Камалетдин, Солтанов Җиһангәрәй, Гыймранов Фазылҗан, Ибраһимов Вагыйз, Галимов Фатыйх, Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт, Хәлилов Гыйниятулла, Солтанов Асылгәрәй, Йосыпов Хөсәен, Хафизов Бикмөхәммәт. Безнең авылдан киткән сугышчыларның шактый өлеше Азин дивизиясе составында сугыша. Уфа юлындагы, Алабуга – Мамадыш юнәлешендәге сугышларда түбәндәге авылдашлар һәлак булган:




Атлас авылы кешеләре – Мөгаллимов Фазлыйәхмәт белән Мөхтәрова Җәүһәрия

Габидуллин Фәррах (1888–1919)
Сәетов Динмөхәммәт (1895–1919)
Миңнекәев Динмөхәммәт (1895–1919)
Фәтхетдинов Камалетдин (1893–1919)
Вәлиев Таҗетдин (1899–1919)

Сугыш тәмамлангач, исән калган кызылармиячеләр авылга кайта. Алар арасында Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт, Халиков Зиннур, Фәйзуллин Ибраһим, Ибраһимов Вагыйз, Мәннәнов Хәйбрахман, Гаделшин Әюп, Хәлилов Гыйният, Йосыпов Хөсәен, Галимов Фатыйх, Сөләйманов Галимәрдән һ.б. була.

1920 елда яңа административ бүленеш – кантон системасы кертелә. Ул елдагы административ бүленеш:



һ.б.

Сәнәкчеләр фетнәсе

1920 елда, Гражданнар сугышының иң кызган чагында, Татарстанның – көнчыгыш һәм Башкортстанның көнбатыш җирләрендә сәнәкчеләр фетнәсе башлана. Фетнәне оештыручыларның башында Зәй бояры Медведев (керәшен татары) тора. Бу хәрәкәт Минзәлә өязендә бөтенләе белән, Бөгелмә өязенең күпчелек өлешендә, Бәләбәй өязенең яртысында, Бөре һәм Уфа тирәләрендә тарала. Халык арасында фетнәчеләрне вәлидовчылар дип тә йөртәләр. Чынлыкта, Зәки Вәлидовның бу фетнәгә бер катнашы да булмый. Фетнәне оештыручылар халыкны шушы хәрәкәткә тарту өчен, озакламый безгә Зәки Вәлидов килеп кушылачак һәм сәнәкчеләр хәрәкәте регуляр армия рәвешендә булачак, дигән фикер тараталар. Фетнәчеләр коммунистларны һәм активистларны эзәрлеклиләр, Совет органнарын таркаталар. Кайбер урыннарда Совет хөкүмәтенең глубинкаларда саклаган икмәген халыкка тараталар. Авылларда дәүләтнең «глубинка» дип атап йөртелгән икмәк саклау складлары бар иде. Фетнә 20 көнләп дәвам итә һәм Совет ягыннан Беренче империалистик сугышта пленда калган венгр солдатларыннан төзелгән отрядлар көче белән бастырыла. Карамалы-Александровка волостенда сәнәкчеләр белән Мәндәй авылы баеның малае – поручик Гарифуллин җитәкчелек итә. Алар авыл активистларын, Кызыл Армия сафына киткән кешеләрнең семьяларын, туганнарын эзәрлеклиләр. Кәүҗияк авылына килеп, 31 кешене олауларга төяп, Метрәй авылында урнашкан штабларына алып китәләр. Сәмигулла һәм Бәдыкшан исемле авыл активистларын Калмыя Карамалысы авылына алып китеп аталар. Фетнәчеләрнең төп штабы Бакалыда урнашкан була. Сәнәкчеләрнең вәкилләре безнең авылга да килеп халыкны фетнәгә кушылырга өнди. Әмма Ташлыярдан аларга кушылучылар булмый. Шулай да Хәмидулла Хәбибуллин һәм берничә кеше сәнәкләр белән коралланып, фетнәчеләргә кушылырга китә. Карамалы-Александровка авылына килеп җиткәч, мылтыктан аткан тавышлар ишетелә, кире борылып кайталар. «Нигә борылып кайттың?» – дип сорагач, Хәмидулла: «Анда, малай, чәтер дә чөтер пулеметтан аталар», – дип җавап кайтарган. Шуннан соң аңа «Чәтер Хәмидулла» исеме ябышып кала. Мәндәй авылында минем әбием Фагыйләнең туганы Әхмәт Ризвановны сәнәкчеләр эзәрлекләвеннән качырып, арбага төялгән тирес астында авылдан алып чыгалар. Ул фетнә беткәнче Ташлыярда яшеренеп ята. Кайбер кешеләр сәнәкчеләрдән качып, урманнарга, чокыр-чакырларга яшеренә. Халиков Габдерәкыйпны сәнәкчеләр хәрәкәтенә кушылмаган өчен, урамга алып чыгып, канга батырып кыйнап китәләр; изба-читальняларны (уку йортын) тар-мар итәләр. Фетнә бастырылгач, коммунистларны һәм активистларны эзәрлекләүдә катнашучыларны урында ук аталар, аеруча явызлык кылучыларын Казанга озаталар. Аларның да күбесе юлда һәм Казанда кырылып бетә.

Атлас авылының оештырылуы

1921 елда корылык һәм икмәкнең бөтенләй булмавы аркасында, Идел буендагы җирләрдә, шул исәптән, безнең якларда да коточкыч ачлык була. Хәтта кешеләрнең үз балаларын суеп ашау очраклары билгеле. Крестьяннар мохтаҗлыктан чыгу юлларын эзлиләр. Илдә вак авыл хуҗалыгы артельләре – коммуналар оештыру эше җәелеп китә. Безнең якларда Алга авылы янында, Карамалы, Горбуновка, Воскресенка авыллары тирәсендә «Карл» коммунасы төзелә. Ташлыярда да коммуна оештыру мәсьәләсе күтәрелә. Авылдашлары авылның иң белемле кешеләрдән саналган Фәтхуллин Гомәргә авыл хуҗалыгы артеле оештыру буенча эш йөртүне тапшыралар.

Кантонда, Казандагы югары органнарда яклау тапкач, берләшергә теләгән кешеләрнең җыелышы уздырыла һәм артель төзергә карар чыгарыла. Артель членнарыннан 60 млн. (Керенский акчасы белән), кием-салым, мануфактура җыйнап, 1921 елның 25 декабрендә кантоннан алынган № 65, № 66 удостоверениеләре белән, Фәтхуллин Гомәр, Фәйзуллин Ибраһим, Мусин Гайсә, Кәлимуллин Бикмөхәммәт һәм башкалар ачыгучыларга икмәк, чәчәргә орлык эзләп, Сарапул якларына барып чыгалар. Үзләрен азмы-күпме канәгатьләндерерлек ашлык алып, Әгерҗе – Казан юлындагы Цухинск станциясенә җибәрәләр. Һәр хуҗалык башына өчәр центнер ашлык алып кайталар.

1922 елда Ташлыярга землемер килеп, авыл хуҗалыгы артеле өчен аерым җир бүлеп бирә. Артельгә аерылып чыккан крестьяннар 1922 елда аерым иген игәләр һәм 1923–1924 елларда Атласка күчә башлыйлар. 1925 елда Ташлыярда зур янгын чыгып, 80нән артык йорт янгач, күчәсе кешеләр Атласка күчеп бетә. Авылга Атлас исемен күчүчеләр арасында әйдәп йөрүчеләрнең берсе Кәлимуллин Бикмөхәммәт бирә (әллә туганының, әллә баласының исемен кушкан, дигән сүз дә йөри.)

Атласка күчәргә теләүче кешеләр түбәндәгеләр булган:

Мусин Гайсә – 6 җан
Кәлимуллин Бикмөхәммәт – 7 җан
Гобәйдуллин Фәйзулла – 11 җан
Фәтхуллин Гомәр – 6 җан
Шәрифуллин Хөснетдин – 6 җан
Вәлиуллин Миңнулла – 6 җан
Кәлимуллин Хафиз – 5 җан
Хантимеров Әхмәтзакир – 6 җан
Каһарманов Шәймәрдән – 7 җан
Хантимеров Муллагали – 5 җан
Бикиев Шәймәрдән – 6 җан
Вәлиуллин Нигъмәтулла – 6 җан
Шәрифуллин Афзалетдин – 7 җан
Мусин Монасыйп – 8 җан
Вилданов Мослахетдин – 7 җан
Зарипов Харис – 6 җан

Рәхмәтуллин Тимербай – 7 җан
Шәймөхәммәтов Галиәхмәт – 8 җан
Габдрахманов Латыйп – 5 җан
Камалетдинов Хөснетдин – 4 җан
Ямалетдинов Гыймазетдин – 8 җан
Фәйзуллин Ибраһим – 4 җан
Хәбибуллин Хәмидулла – 9 җан.

Төрле сәбәпләр табып, Фәтхуллин Гомәр, Камалетдинов Хөснетдин, Хәбибуллин Хәмидулла Атласка күчми. Алар урынын башка кешеләр ала. Хәлилов Гыйниятулла, Мөгаллимов Фазлыйәхмәтләр әнә шулай авыл хуҗалыгы артеленә соңрак кереп, Атласка күчкәннәр. Анда соңыннан башка авыллардан да теләгән кешеләр җыелган. Кәүҗияк-Тамактан (Аблактан) Атласка бер семья да күчмәгән. Анда күчүчеләр арасында иң бай кеше, бу авыл хуҗалыгы артеленең башлап йөрүчесе Кәлимуллин Бикмөхәммәт була. Әйткәнемчә, авылга исемне дә ул бирә. НЭП заманында ул Туйгелде авылы тегермәнен сатып ала. Коллективлаштыру чорында милке тартып алынып, Магнитогорскига сөрелә. 1931 елда Атласта колхоз төзелә. Аңа «Удар» исеме бирәләр. Хуҗалыкның беренче председателе итеп Мусин Гайсә сайлана.

«Удар» колхозының төрле елларда эшләгән председательләре:
Мусин Гайсә
Галиев Тимергали
Хәлилов Гыйниятулла
Раскулов Мәхмүт



Мөгаллимов Абрик Фазлыйәхмәт улының 60 яшьлек юбилей кичәсендә

Вәлиуллин Миңнулла
Юнысова Фатыйма (күрше Юныс бабай кызы)
Фәйзуллин (Фәтхуллин) Ибраһим
Латыйпов Габдерәүф һәм башкалар.

1953 елда «Удар» колхозы Ташлыярдагы «Марс» коллектив хуҗалыгы белән кушыла. Хәзерге вакытта Атлас авылы урамнары асфальтланган, һәр йортка газ кергән, артезиан коесыннан су белән тәэмин ителгән. Мөслим – Әлмәт трактына асфальт юл белән тоташтырылган заманча авыл. Анда бу авылга нигез салган кешеләрнең балалары һәм оныклары яши. Берничә килгән гаилә бар.

Атласны төзекләндерүгә, буасын һәм чишмәләрен яңартуга, авылга, аның урамнарына асфальт юллар уздыруга шушы авылда туып-үскән СССР һәм ТР Дәүләт премияләре лауреаты, техник фәннәр кандидаты, озак еллар «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең бүлек мөдире булып эшләгән Мөгаллимов Абрик Фазлыйәхмәт улы зур өлеш кертте.



Сабанга чыгу

Күмәк тормыш адымнары

1929 елда илдә, авылларда аерым крестьян хуҗалыкларын коллективлаштыру, колхозлар төзү кампаниясе башлана. 1929 елның октябренда республикада инде 647 күмәк хуҗалык була. Авылларга колхоз оештыру өчен егермебишмеңчеләр җибәрелә. Коллективлаштыру хәрәкәте 1930 елда аеруча көчәя. 1930 елның январь аенда Ташлыярга Мәскәү заводларының берсеннән – егермебишмеңче, коммунист Мөхетдинов Сәет Фәхригалләм улы килеп төшә. (Мин Мөслимдә врач-хирург булып эшләгәндә – 1967–1970 еллар – ул Мөслимдә

яши иде. Миңа әле Сәет абыйга операция дә ясарга туры килде.) 2 февраль көнне гомуми җыелыш җыелып, коллективлашу мәсьәләсе карала. Җыелыш зур каршылыклар белән үтә. Нәтиҗәдә, колхоз төзергә дигән карар кабул ителә. Шул җыелышта ук 40ка якын кеше колхозга алуны сорап гариза яза. Бер атна эчендә күмәк хуҗалыкка берләшүчеләрнең саны 99га җитә. Колхозның беренче председателе итеп Ибраһимов Вагыйз сайлана. Идарә членнары итеп Фәтхуллин Гомәр (хисапчы), Мөхетдинов Сәет, Сөләйманов Гайнетдин, Морзаханов Салихҗаннар сайлана. Колхозга «Марс» исеме бирелә.



«Марс» колхозында беренче сабанга чыгу, 1930 ел

10-29 февраль көннәрендә чәчүлек орлык җыйнала һәм чистартыла. 11 март көнне кичке ут алынгач, колхозга икеләнебрәк кергән кешеләр идарә урнашкан бинаны уратып алалар һәм колхозга керергә дип биргән гаризаларын кире алалар. Шулай итеп хуҗалыкның таралу куркынычы туа. Ашыгыч рәвештә партиянең Чаллы кантон комитетыннан уполномоченный Шакиржанов килеп җитә. Кантоннан килгән землемер колхозга җир бүлеп бирә. Беренче язгы чәчүгә «Марс» колхозында 42 ярлы һәм урта хәлле крестьян кала. Сабанга 28 ат, 14 сабан катнаша. Чөнки колхозга кергән ярлыларның аты да, сабаны да булмый. Шуңа күрә авылларда баерак кешеләрнең мөлкәтен конфискацияләү, үзләрен чит җирләргә сөрү кампаниясе башлана. Шул елларда йорт-җирләре конфискацияләнгән түбәндәге кешеләр авылдан сөрелә:

Аблаков Сабиржан (Кара Сабиржан) – Магнитогорскига
Аблаков Әхмәтлатыйп – Магнитогорскига
Биккинина Мәчтүрә (үлгән Биккинин хәзрәтнең хатыны)
Бикиев Әхмәтгариф – Магнитогорскига
Кәлимуллин Бикмөхәммәт – Магнитогорскига.

Рамазан байны (йортлары Әгъләмов Әнвәр абыйларга каршы, хәзерге тыкрык урынында була) мәчет янындагы келәткә бикләп, Ситдыйков Садыйк («Сана Садыйгы») кыйнап үтерә, йорт-җирләрен конфискациялиләр. Ситдыйков Садыйк сугыштан соңгы елларда Элемтә авылында яшәде, мин аны яхшы хәтерлим. Авылның хәлле крестьяны Вилданов Әгъләметдиннең (30–40 сарыгы, берничә аты һәм сыеры була) бөтен мөлкәтен конфискацияләп, йортын сүтеп алып китәләр һәм ул гаиләсе белән мунчада яшәп кала. Сөргенгә сөрмиләр.

Әхмәтлатыйп байның йортын сүтеп, арткы урамда колхоз идарәсе һәм клуб итеп салалар. Мәчтүрә абыстайның йортын урта (зәңгәр) мәчеткә ерак түгел урынга күчереп салалар. Бу йорт арткы урамда мәктәп бинасы итеп файдаланылды. Сугыштан соңгы елларда башлангыч классларда без шул мәктәптә укыдык.

Раскулачивать ителгән кешеләрнең йорт-җирләрен сүтеп, колхозның төрле хуҗалык биналарын (ферма, контора, келәтләр) төзүдә файдаланалар. Күренгәнчә, баерак кешеләрне талап сөргенгә сөрү, күбрәк аларның сыйнфый дошман булган өчен түгел, колхозны оештырырга мөлкәтләре кирәк булган өчен эшләнгән.

Колхозлашу һәм сугыш чорында репрессияләнеп, озак еллар узгач акланган (реабилитацияләнгән) авылдашларыбызның исемлеге:

Халиков Абдрей (Габдерәкыйп). 1867 елда Ташлыяр авылында туган һәм шунда яшәгән. 1932 елның 26 апрелендә Тат. ЦИК тарафыннан хөкем ителгән, кулак дип гаепләнгән. 1997 елның 17 апрелендә реабилитацияләнгән. *(ТР Эчке эшләр министрлыгы (ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Халиков Хәй. 1912 елда Ташлыяр авылында туган һәм шунда яшәгән. 1932 елның 26 апрелендә Тат.ЦИК тарафыннан хөкем ителгән. 1997 елның 17 апрелендә реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Аблаков Әнвәр Бикмөхәммәт улы. Ташлыяр авылында яшәгән. 1931 елның 12 июнендә Мөслим райбашкарма комитеты тарафыннан хөкем ителгән. 1993 елның 22 мартында реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Аблаков Әхәт Бикмөхәммәт улы. Ташлыяр авылында яшәгән. 1931 елның 12 июнендә Мөслим райбашкарма комитеты тарафыннан хөкем ителгән. 1993 елның 22 мартында реабилитацияләнгән.

Аблаков Рифгать Бикмөхәммәт улы 1911 елда туган. Ташлыяр авылында яшәгән. Мөслим райбашкарма комитеты тарафыннан 1931 елның 12 июнендә хөкем ителгән. 1993 елның 22 мартында реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Аблаков Таҗимөхәммәт Бикмөхәммәт улы Ташлыяр авылында яшәгән. 1931 елның 12 июнендә Мөслим райбашкарма комитеты тарафыннан хөкем ителгән. 1993 елның 22 мартында реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Аблаков Шәмсемөхәммәт Бикмөхәммәт улы Ташлыяр авылында яшәгән. 1931 елның 12 июнендә Мөслим райбашкарма комитеты тарафыннан хөкем ителгән. 1993 елның 22 мартында реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Аблакова (Шәйхетдинова) Мәрьям Бикмөхәммәт кызы 1915 елда туган, Ташлыяр авылында яшәгән. 1931 елның 12 июнендә Мөслим райбашкарма комитеты тарафыннан хөкем ителгән. 1993 елның 22 мартында реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Аблакова Хәерлефәтиха 1873 елда туган. Ташлыяр авылында яшәгән. 1931 елның 12 июнендә Мөслим райбашкарма комитеты тарафыннан хөкем ителгән. 1993 елның 22 мартында реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Халиков Габделәхәт 1904 елда туган. Ташлыяр авылында яшәгән. 1932 елның 26 апрелендә Тат. ЦИК тарафыннан хөкем ителгән. 1997 елның 17 апрелендә реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Халиков Котдус 1908 елда туган. Ташлыяр авылында яшәгән. 1932 елның 26 апрелендә Тат. ЦИК тарафыннан хөкем ителгән. 1997 елның 17 апрелендә реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Халикова Мәрьям 1872 елда туган. Ташлыяр авылында яшәгән. 1932 елның 26 апрелендә Тат.ЦИК тарафыннан хөкем ителгән. 1997 елның 17 апрелендә реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Халикова Хатирә 1914 елда туган. Ташлыяр авылында яшәгән. 1932 елның 26 апрелендә Тат.ЦИК тарафыннан хөкем ителгән. 1997 елның 17 апрелендә реабилитацияләнгән. *(ТР ЭЭМ мәгълүматларыннан.)*

Гулявцев Иван Перфилович 1905 елда Чистай районында туган. Ташлыяр авылында яшәгән; урыс; Кр-ц, өлкән пешекче; медсанротада. 151 отд.стр. бригада. Чиләбе шәһәрендә яшәгән. 1942 елның 16 октябрендә кулга алынган. 151 стр. Бригада отделениесе хәрби трибуналы тарафыннан хөкем ителгән: ст.58-10 ч.2 (совет хөкүмәтенә, Кызыл Армиягә яла ягу, аның җиңәчәгенә ышанмау). Хөкем: төзәтү хезмәт лагеренда 10 ел, акчаларын конфискацияләү, 5 елга хокукларын алу. 1997 елның январенда реабилитацияләнгән. *(ТР Хәтер Китабы мәгълүматыннан.)*

Фәрхетдинов Мирсәет Сабит улы 1916 елда Ташлыяр авылында туган; татар; инженер-урман транспортчысы, техник җитәкче, Лубян урман хуҗалыгы. Кукмара районы, Сердоусь авылында яшәгән, 1948 елның 20 июлендә кулга алынган. ТАССР Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы тарафыннан 1948 елда хөкем ителгән: 19-58-8, 58-10 ч.1 («Совет властена ризасызлык белдерү, партия һәм хөкүмәт җитәкчелегенә карата террор нияте»). Хөкем карары: гаепләү расланмаганлыктан эш туктатыла. *(ТР Хәтер Китабы мәгълүматы.)*

Муратаев Нурулла Хәйрулла улы 1877 елда Тукай районы Бәйрәкә (?) авылында туган; татар; мулла. Ташлыяр авылында яшәгән. 1931 елның 1 мартында кулга алынган. 1931 елның 27 июлендә ТАССР ГПУ өчлеге тарафыннан хөкем ителгән: 58-11 («солтангалиевчеләр төркемендә катнашучы»). Хөкем: 10 ел концлагерь. 1989 елның 9 октябрендә реабилитацияләнгән. ТР Хәтер Китабы мәгълүматы.

Аблаков Бикмөхәммәт Гафият улы 1870 елда Кәүҗияк-Тамак авылында туган; татар; аерым хуҗалыкчы. Ташлыяр авылында яшәгән. 1931 елның 25 февралендә кулга алынган 1931 елның 27 июлендә ТАССР ГПУ өчлеге тарафыннан 10 ел концлагерьга хөкем ителеп, ОГПУ Коллегиясе тарафыннан 4.3.33 ст. – Урал өлкәсе һәм Россиянең 12 өлкәсендә яшәү хокукыннан мәхрүм ителүгә алыштырылган. 1989 елның 9 октябренда реабилитацияләнгән. *(ТР Хәтер Китабы мәгълүматы.)*

Әлбәттә, архив материаллары нигезендә төзелгән бу исемлек һич тә тулылыкка дәгъва кыла алмый.

Ташлыяр авылында туып-үскән (1924), хәзерге вакытта Уфа шәһәрендә яшәүче инженер-химик Өлфәт Лотфулла улы Рамазановның (Рамазан байның оныгы) язма истәлекләрендә авылда конфискация уздыруда актив катнашкан кешеләрнең исемлеге китерелә. Ул аларны актив талаучы фанатиклар дип атый. Менә аларның исемлеге:

Сана Ситдыйгы – Садыйков Ситдыйк

Гомәр мулла (Фәтхуллин Гомәр)

Кәҗә Вәгыйзы (Ибраһимов Вәгыйз)

Камил (Вәлиев Камил, авыл Советы председателе)

Бәширә – укытучы (Туйкина Бәширә)

Сөләйман Гайнетдине (Сөләйманов Гайнетдин, авыл Советы председателе)

Атлас «Бүре» (Хәлилов Гыйният)

Тимерхан Дәүләте (Тимерханов Дәүләтҗан, колхоз председателе)

Мөхетдинов Сәет – колхоз председателе.

1931 елның көзендә авылдагы крестьян хуҗалыкларының 72 проценты колхозга берләшә. 1931 елның 3 мартында Мөслимдә колхозчыларның беренче съезды уза. Анда делегат булып Ташлыяр авылыннан Мөхетдинов Сәет һәм Фәтхуллин Гомәр катнаша.

1931 елда Мөслимдә МТС төзелә. Ташлыярга Кадыйров Габдрахман дигән Югары Табын кешесе «Фордзон» тракторы алып кайта. Ул заман өчен бу зур вакыйга була.

Авылда беренче булып колхозчы Сафина Гыйзденисә, Фәррахова Гөлбостан, курсларда укып кайтып, трактордa эшли башлый. 1932 елда колхозчыларга эшләгән өчен хезмәт көне язу кертелә. 1934 елда күмәк хуҗалыкның 1220 гектар чәчү мәйданы, 260 баш аты була. Сыер һәм сарык асрау фермалары оеша. 840 гектар бөртекле культураларның һәр гектарыннан 8әр центнер уңыш үстерелә. Тулаем җыем 2820 центнер тәшкил итә. Һәр хезмәт көненә 2шәр кг исәбеннән ашлык бүлеп бирелә. Сугышка кадәрге елларда колхозлашу төгәлләнә. «Марс» колхозы экономик яктан ныгый, алга киткән хуҗалыклардан санала. Колхозның сугыш башланыр алдыннан булган экономик хәле түбәндәге саннарда күренә:

Экономик күрсәткечләр	**1934 ел**	**1940 ел**
Гомуми чәчү мәйданы (га) *Шул исәптән бөртекле культуралар мәйданы (га)*	*1220*	*1404* *900*
Бөртекле культуралардан (га) уңыш	*8 центнер*	*9 центнер*
Тулаем җыем	*6820 центнер*	*8134 центнер*
Атлар саны	-	*272 баш*
Мөгезле эре терлекләр	-	*103 баш*
Савым сыерлар	-	*34 баш*
Ана дуңгызлар	-	*3 баш*
Һәр ана дуңгыздан алынган бала саны	-	*2 баш*
Һәр сыердан алынган сөт	-	*1004 кг*
Тракторлар саны	-	*Юк*
Машиналар саны	-	*1*
Комбайннар саны	-	*юк*

Авыл хуҗалыгы машиналары (трактор, комбайн), килешү нигезендә, МТСтан китерелә. Аның өчен акчалата яки натуралата (икмәк белән) түләү тәртибе була.



Сугыштан соңгы елларда авыл йорты (бәрәңге бакчасы ягыннан)



Югары оч күл буенда
Мирзасалих Хөснуллин

Сугышка кадәр колхоз белән җитәкчелек иткән председательләр:

1. Ибраһимов Вагыйз, 1900 елда Ташлыярда туган. 1930 елда беренче председатель була.
2. 1930–1932 елларда – Мөхетдинов Сәет Фәхригалләм улы, 25 меңче, Башкортстанда туган, 1972 елда Мөслимдә үлгән.
3. 1932–1934 елларда – Фәтхуллин Хантимер Фәтхулла улы. 1901 елда туган, Әмәкәй авылыннан. 1966 елда Казанда үлгән.
4. 1931–1936 елларда – Газизов Вагыйз, 1901 елда туган. Түбән Табын авылыннан. Сугышта һәлак булган.
5. 1936–1938 елларда – Тимерханов Дәүләтҗан, 1910 елда Ташлыярда туган. Сугышта һәлак булган.
6. 1938–1940 елларда – Арсланов Шәйхегали, 1908 елда туган, Яңа Сәфәр авылыннан. 1972 елда Мөслимдә үлгән.
7. 1940–1941 елларда – Сәетов Вагыйз, Олы Чакмак авылыннан. Сугышта һәлак булган.

Колхозның хисапчылары:

1. 1930–1935 елларда – Фәтхуллин Гомәр.
2. Галиев Тимергали
3. Шәйгазамов Нәҗип
4. Авзалов Сәхәбетдин

Сугышка кадәр елларда колхозның төрле тармаклары белән җитәкчелек иткән активистлар: бригадирлар, ферма мөдирләре, кладовщик, табельщик, агроном һ.б.:

Закиров Ситдыйк
Шәрәфетдинов Сабиржан
Шәймәрдәнов Гафур
Шәймәрдәнов Шәйсолтан
Вәлиев Минһаҗ
Ибраһимов Вагыйз
Авзалов Сәхәбетдин
Бикиев Сабиржан
Морзаханов Салихҗан
Вәлиуллин Хөснулла
Гайфуллин Салих
Шәйдуллин Рәхмәтулла
Шакирова Мөкәррәмә
Шәйгазамов Нәҗип
Фәтхуллин Әбүбәкер
Шәйдуллин Нигъмәлгата
Шәрәфетдинов Нурулла һәм башкалар.



Мөнәвәрә Сәлахова, хатын-кызлар арасында беренче коммунист. 1929 ел

Якты өметләр чоры (1930–1940 еллар)

1930 елларда илне индустрияләштерү башлана. Беренче, икенче, өченче, дүртенче, бишенче бишьеллыкларда халыктан ихтыярый-мәҗбүри заем (салым) җыйнала. Мәсәлән, Ташлыяр мәктәбе профсоюз членнары (укытучылар һәм техник эшчеләр) һәр ел айлык хезмәт хакы күләмендә дәүләт заемына язылганнар һәм аны 10 ай эчендә процентлап түләп барганнар. Мәсәлән, 1934 елда түбәндәге күләмдә заемга язылганнар:

Директор Мөхәммәтҗанов Нурлыгаян	260 сум
Завуч Мусин Лотфулла	200 сум
Укытучы Вагизова Разия	170 сум
Укытучы Виноградов Н.	110 сум
Укытучы Мохтарова Җәүһәр	130 сум
Укытучы Әхмәтова Өмбел	150 сум
Укытучы Туйкина Бәширә	110 сум
Укытучы Камалова Н.	75 сум
Техник эшче Авзалова З.	20 сум

Су тегермәне кору

1936–1937 елларда Ташлыярда Мәллә елгасы аркылы су тегермәне корыла. Колхозчылар белән тегермән буасын буу, келәтләрен салу һәм тегермән ташын урнаштыруда Петровка б.к. авылыннан килгән Василий дигән урыс җитәкчелек итә. Тегермәнче булып башта Василий, аннан соң Миндияров Гариф, ул үлгәч, Мәлләтамак авылыннан килгән Газизов Габдулла, ул картайгач, Баһаветдинов Авзалетдин, аннан соң Авзалов Сәхәбетдин эшли. Газизов Габдулла ярма яргычы да ясый.

Тегермәндә күрше-тирә авыллар халкы да он тарта, колхоз маллары өчен фураж ясыйлар. Ташлыярның тегермән буасын ел саен диярлек язгы ташу ярып, агызып китә иде. Яңадан буаның ярылган өлешен төзәтү, ә аның соңгы көне буа басу дип атала һәм ул бәйрәм төсендә үтә иде. Барлык авыл халкы җыелып, булган арбаларга салам, таш, балчык, тал чыбыгы төяп ташыды. Буа буылгач, түбән агымда мордалар куеп, балык тоту бер күркәм гадәт иде. Тарихи документлардан күренгәнчә, безнең авылда элегрәк заманнарда да су тегермәне булганы билгеле. Мәсәлән, 1877 елда Санкт-Петербургта басылган «Список населенных мест по Уфимской губернии по сведениям 1870 года» дип аталган Россиянең Эчке эшләр министрлыгының Үзәк статистика комитеты чыгарган җыентыкта, 2027 номер белән: «Ташляр – деревня при реки «Мерли» (Мәллә елгасы дип укырга кирәк. – *Р.Ш.*), до Мензелинска 55 верст. Дворов – 94, мужчин – 276, женщин – 257. Мечеть. Училище (мәктәп дип укырга кирәк. *Р.Ш.*), мельница водяная. Плотничество. По проселочной дороге из г. Мензелинска в г. Бугульму», – дип язылган. Димәк, бездә элек тә су тегермәне булган. Ләкин аның кайсы елгада салынганы билгесез. «По проселочной дороге из г. Мензелинска в г. Бугульму» дигән җөмләне ачыклау

фарыз. Минзәлә белән Бөгелмә арасында почта тракты була. Туйгелде авылының Мөслимгә киткән ягындагы таш күпер шул почта тракты өчен салынган була. Почта юлы Минзәләгә таба Мәлләтамак, Түбән Табын, Тугаш, Сөренчәк, аннары Минзәлә районы авыллары (Юшады, Иске Каран) яныннан узган. Мин Минзәләдә медучилищеда (ФАШ) укыганда (1954–1957 еллар), җәй көне велосипедта шушы юлдан йөри идек. Патша заманында бу юлда юлбасарлар кешеләрне талау, үтерү белән шөгыльләнгән. Риваятьләргә караганда, бу җәһәттә Сөренчәк урыслары ерткычлык күрсәткән (бу авыл хәзер юк, халкы күчеп киткән.)

Сливочный пункт (май заводы) оештыру

1933–1934 елларда сөргенгә сөрелгән Аблаков-Шакиров Сабиржанның («Кара Сабиржан») таш амбарында сливочный пункт («май заводы») оештыралар. Аның беренче мастеры Гайфуллин Талибулла абый була. Бу пункт минем туып-үскән нигездән бер йорт аркылы гына (Ситдыйков Әхмәтхафиз – күрше бабай йорты) урнашкан иде.

Без, югары оч (Аблак) малайлары сугыш һәм сугыштан соңгы ачлык елларда даими шушы май заводы янында кайнаша идек. Бу пунктта янәшә-тирәдәге – Элемтә, Михайловка, Атлас, Игенче, Туйгелде авылларының аерым гражданнарыннан җыелган «Марс», «Искра», «Кызыл Сабанчы» колхозларыннан һәм «Овцевод» совхозының дәүләткә тапшырылган сөтне кабул итеп, сепараторларда аертып, сөт өсте (сливки) әзерлиләр иде. Сөт өстен Түбән Табын май заводына Талибулла абыйның олы уллары Дамир һәм Мөдир абыйлар ташыды. Без, якынтирә малайлары, аларның кайтканын «дүрт күз» белән көтеп каршы ала идек. Чөнки бидоннарның стеналарына сыланып калган сөт өсте юлда кайта-кайта, агып төшеп, бидон төбендә кайвакыт шактый гына җыела иде. Без ул бидоннарны (кемгә ниндие эләгә инде) «ялап» чыга идек. Бу пунктта казеин да ясалып дәүләткә озатылды. Әләккәндә, безгә – мохтаҗ заманның ач малайларына – казеин да бик ярап куя иде. Сөт аерта торган зур сепараторларны икешәр хатын-кыз кул белән әйләндерә иде. Бер хатирә истә калган: миңа, 10–11 яшьлек малайга, сепараторны майлау өчен имәнлек буенда (3 чакрым чамасы) эшләүче трактор-лар янына барып, солидол алып кайтырга куштылар. Солидол алып кайткач, сөт өсте белән буталган эремчек биреп сыйлаганнары истә калган.

Кыш көне, яз якынлашкач, май заводының «боз базы»на буадан кисеп ташып боз тутыралар иде. Бу эш өмә рәвешендә эшләнеп, бәйрәм төсе ала иде.

1957 елны сливочный пункт «Игенче» бүлекчәсенә күчерелде. Колхоз, совхоз фермаларыннан һәм халыктан җыелган сөтне молоковоз машиналары белән турыдан-туры Мөслим сөт заводына ташый башладылар.

Партия ячейкасы төзү һәм комсомол оешмасы

Авыл активистларыннан һәм алдынгы яшьләреннән 1925–1926 елларда ук партиянең теләктәшләр группасы төзелә. Шулардан Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт (1926 елдан партия членлыгына кандидат), Сөләйманов Гайнет-

дин, Шәйхетдинов Нуриәхмәт, Закиров Мөхәммәтнәҗип, Гаделшин Әюп, Галимов Фатыйх, Фәрхетдинов Мөхсин һ.б. теләктәшләр була. Карамалы-Александровка волостенда ул вакытта 9 ВКП(б) члены исәптә тора. Шулар арасында: Вахитов, Вәҗетдинов, Яхин Ибраһим, Ганиев, Иванов А.А. була. 1927 елда Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт партия члены итеп алына. Ташлыярда территориаль партия ячейкасы төзелә. Аның составына Шәймөхәммәтов Н.Ш. (Ташлыярдан), Иванов Андрей (Петровка-Михайловка), Козырев Роман (Петровка) кертелә һ.б. Акимов Дмитрий (Михайловка), Әхмәтҗанова Фатыйма (Рантамак), Сәлахова Мөнәвәрә (Ташлыяр) ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алына. Партячейка секретаре итеп Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт сайлана. 1928 елда Свердловск шәһәреннән кайткан Сәләхетдинов Зыятдин 1929 елның көзенә кадәр партячейка секретаре булып эшли. Ул күчеп китү сәбәпле, секретарь итеп яңадан Шәймөхәммәтов Н.Ш. сайлана. Аннан соң Туйгелде авылыннан килгән укытучы Мәксутов Галиәхмәтне секретарь итәләр.

1930 елны колхоз оештыру өчен 25 меңче Мөхетдинов Сәет килгәч, ячейка составы тагын бер кешегә арта. Тимерханов Дәүләтҗан, Сөләйманов Гайнетдин, Ибәтова Хәят һ.б. ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алына.

1939–1940 елларда партия оешмасында түбәндәге ВКП(б) членнары исәптә торган:

Мөхетдинов Сәет	1930–1932
Мәксутов Галиәхмәт (укытучы)	1929–1932
Сөләйманов Гайнетдин (авыл Советы председателе)	1930–1935
Галимов Зиннәт (авыл Советы секретаре)	1930–1932
Фәтхуллин Хантимер (колхоз председателе)	1932–1934
Мөхәммәтҗанов Нурлыгаян (мәктәп директоры)	1932–1935
Газизов Вагыйз (колхоз председателе)	1934–1936
Шәйхуллин Мирза (мәктәп директоры)	1935–1941
Тимерханов Дәүләтҗан (колхоз председателе)	1936–1938
Баязитова Гатифә (укытучы)	1933–1935
Сөләйманов Ибраһим (колхоз председателе)	1933–1940
Арсланов Шәйхегали (колхоз председателе)	1938–1940
Сәетов Вагыйз (колхоз председателе)	1940–1941
Шәймәрдәнов Гафур (колхоз члены)	1940–1941
Вәлиев Камил (авыл Советы председателе).	1937–1941

Исемлектән күренгәнчә, авыл коммунистларының күбесе килгән кешеләр була. 1967 елны Ташлыярда парт. ячейка оешуның 40 еллыгын районда зурлап билгеләп уздылар. Бу тантанада ячейканы оештыручылар Шәймөхәммәтов Н.Ш. һәм Сәләхетдинов Зыятдин абыйлар да катнашты. Юбилейны уздыруда партия райкомының икенче секретаре Вәлитов Марсель Галиәкбәр улы башлап йөрде.

Сугышка кадәр Ташлыярда авыл Советы председателе булып түбәндәге кешеләр эшләгән:

Сөләйманов Гайнетдин	1929–1936
Вәлиев Минһаҗ	1931–1932
Ибраһимов Вәгыйз	1932–1933

Шәрәфетдинов Сабиржан 1934–1937
Вәлиев Камил 1937–1941
Исмәгыйлов (Мәлләтамак). 1941–

Авыл Советы секретарьлары булып эшләүчеләр:
Галимов Зиннәт
Шакиров Нәҗип
Шәйдуллин Нигъмәлгата

Авыл тормышында халыкны агартуда, тәрбияләүдә комсомоллар дәртләнеп эшлиләр. ВЛКСМ членнары – укытучылар Галимуллин, Мусин Лотфулла, Хафизов (секретарь) белән бергә, Нуретдинова Нәсиха, Мөгыйнова Нәкыя, Вәлиев Мөнирләр 1931–1932 елларда укый-яза белмәүчелекне бетерүдә актив катнашалар, стена газеталары чыгаралар, газета-журналларга, заемнарга язылу һәм башка күп төрле чаралар уздыруда башлап йөриләр. Авылда беренче комсомол секретаре Фәрхетдинов Мөхсин була (1926–1928).

Аеруча актив комсомоллар буларак билгеле яшьләрнең кайберләрен исемләп күрсәтәм:

Шәрипов Галимҗан
Тимерханов Дәүләтҗан
Мөгалимов Нуриәхмәт
Латыйпов Галимҗан
Садыйков Ситдыйк
Шәйдуллин Нигъмәлгата
Сәлахова Мөнәвәрә
Гарифуллина Гайникамал
Закиров Мөхәммәтнәҗип



Закиров Мөхәммәтнәҗип белән Вәлиев Мөнир. 1930 елларда Ташлыяр авылының актив комсомоллары



Сугыш елларында көзге Ташлыяр урамы

Илгә дошман янганда

1941 елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башлана. СССР Верховный Советы Президиумының 23 июнь Указы нигезендә, 1905–1918 елларда туган хәрби хезмәткә яраклы кешеләрне сугышка мобилизацияләү башлана. 1938–1940 елларда армиягә алынган кешеләр сугышның беренче көннәреннән үк дошманга каршы күтәрелә. Минем әтием Шәймәрдәнов Шамил сугыш алдыннан хәрби әзерләүгә (переподготовка) чакырылган була. Сугыш башланганда ул Киев Хәрби округында атлы артиллериядә хезмәт итә һәм беренче көннәреннән үк сугышка керә. Ак финнәргә каршы сугышта катнашып кайткан кешеләр дә, мәсәлән, Шәйдуллин Нурулла, тагын фронтка китәләр. Архив документларыннан күренгәнчә, район военкоматы аркылы безнең авылдан 136 кеше сугышка чакырыла. Бүтән өлкәләрдән киткән авылдашлар бу исемлеккә кермәгән. Шунлыктан Ташлыярда туып-үскән кешеләрнең күпмесе сугышка киткәнен төгәл әйтүе кыен.

Сугышның беренче көннәреннән үк хатын-кызлар фронтка киткән ирләрен, аталарын алыштырып, аларның урыннарына баса. «Марс» колхозында: Зөләйха Шәйгазамова, Хәят Шәйдуллина, Тайфә Әгъләмова, Фатыйма Юнысова, Маһруйбикә Латыйпова, Мәсхүдә Фәрдиева, Нажия Фатыйховалар кырчылык бригадасы бригадирлары, Бәдрисафа Насыйрова – ферма мөдире, Мөкәррәмә Шакирова – ветсанитар, Фәрдәнә Закирова мәктәп директоры булып эшлиләр, колхозны, авылны җитәклиләр. Колхоз председательләре Ибраһимов Вагыйз (1941), Шәймәрдәнов Шәйсолтан (1941), Вәлиев Минһаҗ (1941–1942), Шәрәфетдинов Нурулла (1942–1943) һәм башкалар сугышка киткәч, колхозны 1888 елда туган Вәлиуллин Хөснулла җитәкли.

1941 елны игеннәр бик уңа. Ләкин аны җыеп алу мөмкинлеге бик аз була. Колхозның ул вакытта 1000 гектар чамасы чәчү мәйданы, 240 баш аты булган. Шулардан иң яхшы 85 баш яшь атны җигүле килеш фронтка озатканнар. Нәтиҗәдә, 1941 елны байтак ашлык тамырда килеш кар астында кала. Колхозчыларның хезмәт көннәренә ашлык граммлап кына бирелә. Ягулык җитмәү аркасында, тракторлар утын ягып газогенератор белән эшләүгә күчерелә. Биктимер аланында, Үтәш чокыры башында, кыр станнары һәм колхоз ихаталарында үскән агачларны кисеп, «чурки» (турап киптерелгән агач шакмаклары) ясыйлар. Урманнан утын кисү тыела.

Ул дәһшәтле чорда иң авыр хезмәт хат ташучы Шәйхелова Мөшәрәфә апаныкы булгандыр. Көн саен диярлек авылга үлү хәбәре (извещениеләр) килеп тора. Бу хәбәрләрне һәлак булучыларның якыннарына Мөшәрәфә апага, утлы күмер тоткан кебек, тапшырырга туры килә. Яу кырында ятып калган ир-егетләр өчен хатыннарының һәм балаларының күз яшьләре түгелә. Колхоз басуларының гектарыннан 3–4 центнердан артык уңыш җыелмый. Кырлар тулысынча эшкәртелә алмый, калдау җирләр барлыкка килә. Терлек азыгы җитмәү аркасында колхоз маллары күпләп үлә. Язгы айларда салам түбәләрне сүтеп малга ашату гадәти хәлгә әйләнә. Халык, ярым-ярты ашап, ачлы-туклы яши. Язга чыккач, төрле үлән, бакчалардан өшегән бәрәңге казып алып, кәлҗемә ясап

ашау, кырда җыйналмый калып, кар астында кышлаган башакларны җыйнап, аларны азыкка куллану, тамак туйдыру чаралары була. Ләкин 1944 елның язында кар астында кышлаган башаклар агулы булып чыга. Аларны ашаган кешеләр авырый, шешенә башлыйлар. Врачлар бу авыруның септик ангина икәнен ачыклый. Авыру эпидемия рәвешен ала. Бик күп үлем очраклары була. Мәсәлән, Шәрифуллин Фәрхетдиннең 13 һәм 16 яшьлек ике кызы үлә. Район буенча септик ангинадан 820 кеше вафат була.

1942 елның октябреннан 1943 елның көзенә кадәр колхоз белән фронттан яраланып кайткан Шәйдуллин Рәхмәтулла җитәкчелек итә. Ул киткәч, председатель булып Шәрипов Бижан, аннан соң Нарат-Асты авылыннан килгән Сәхапов Җәләй 1944 елның 24 июненә кадәр эшли. Сәхапов Җәләй киткәч, колхозны Локманов Әхмәт исемле кеше җитәкли.

1945 елның 15 апрелендә колхозны өчкә бүләләр. Авылның югары очындагы колхоз – «Марс», түбән очындагысы – «Ярыш», Атлас авылында оешканы «Удар» дип атала. «Марс» колхозы белән Локманов Ә.Л. (1913 елгы, Салауз-Мухан авылыннан), «Ярыш» колхозы белән Шәйхетдинов Нурулла (1915 елда туган, Ташлыярдан), «Удар» колхозы белән Фәйзуллин Ибраһим (Атласныкы, 1906 елда туган) җитәкчелек итә.

1942 елда илдә беренче хәрби заем (салым) чыгарыла. Ташлыяр авыл Советына ул вакыттагы акча йөреше белән 55 мең сумлык план җиткерелә. Ул 110 мең сум итеп үтәлә. Аерым гражданнар 2000, 1500, 1000әр сум заемга язылган. Мәсәлән, Вилданов Әгъләметдин, Мифтахов Гыйльфан, Нәфыйков Габделганиләр иң күп заемга язылучылар булган.

Сугыш вакытында, заемнан башка, мәҗбүри страховать итү, авыл хуҗалыгы налогы, үзара салым, баласызлык налогы, лотерея җыемнары, «Татарстан колхозчысы», «Кызыл Татарстан» авиаэскадрильясына самолетлар төзү өчен взнослар җыйнау, дәүләткә сөт, ит, мал тиресе, бәрәңге тапшыру йөкләмәләре була. Һәр елны көз көне фронттагы сугышчыларга оекбаш, бияләй, шарф, портянка, киез итек һ.б. җылы киемнәр, иләнгән тиреләр, сарык йоннары, чигелгән кулъяулык, тәмәке янчыгы кебек әйберләрне авыл Советы башкарма комитеты җыеп, район үзәгенә озата. Ул елларда халыкның тормыш хәле гаять авыр була. Кешеләр мохтаҗлыкка, бөтен кыенлыкларга түзеп һәм авырлыкларны җиңеп, «Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!» дигән лозунг астында яшиләр һәм эшлиләр. Архив документлардан күренгәнчә, Мөслим районы буенча 1942 елның 1 октябреннән 5 ноябренә кадәр (35 көн эчендә) район кешеләре фронт өчен 39 135 сум акча, 660 сарык түшкәсе, 641 килограмм сарык йоны озаталар. 1941–1942 елларда гына ТАССРдан фронтка 23 мең кыска тун, 54 мең пар киез итек, 53 мең телогрейка һәм шаровар, 106 мең пар җылы эчке кием җибәрелә. *(Во имя Победы. Книга памяти, Казань, медицина, 2015. – 370 бит.)*

Якынча мәгълүматларга караганда, Ташлыяр һәм Атлас авылларыннан Ватан сугышында катнашучыларның саны түбәндәге таблицадан күренә:

Авыл исеме	*Фронтка яки хәрби заводка киткән*	*Исән кайткан*	*Һәлак булган, хәбәрсез югалган*
Ташлыяр	*208*	*115*	*93*
Атлас	*29*	*8*	*21*
Барлыгы	*237*	*123 (51,6%)*	*114 (48,4%)*

Таблицадан күренгәнчә, сугышка киткән һәр ике кешенең берсе һәлак булган, яисә хәбәрсез югалган. Сугыштан исән кайтучылар арасында аеруча батырлык һәм кыюлык күрсәткәне өчен, СССРның хәрби орден-медальләре һәм Верховный главнокомандующий Сталинның Рәхмәт язулары белән бүләкләнгән бик күп кешеләр була. Шулар арасында:

Монасыйпов Миңнәхмәт Монасыйп улы, 1916 елда туган, «Сугышчан Кызыл байрак», «Кызыл Йолдыз» орденнары, дистәләгән медальләр һәм Верховный главнокомандующийның рәхмәт язуы белән бүләкләнгән, офицер, артиллерист, кавалерист. 1976 елда Казанда үлде.



Монасыйпов Миңнәхмәт Монасыйп улы.



Вәлиев Камил Вәли улы, 1919 елда туган, гвардия өлкән лейтенанты, разведчик. Минск шәһәр комендантының ярдәмчесе була. «Кызыл Йолдыз» ордены һәм күп медальләр белән бүләкләнгән. Әлмәт шәһәрендә яшәде.

Фәтхуллин Мидхәт Гомәр улы, 1920 елда туган, лейтенант, зенитчик, ике «Кызыл Йолдыз» ордены һәм 10 медаль белән бүләкләнгән. Мөслим урта мәктәбендә хәрби җитәкче булып эшләде.

Гайсин Мирза Гайсә улы (1915–1967), лейтенант, «Кызыл Йолдыз» ордены, «Варшаваны азат итү өчен», «Берлинны алу өчен» медальләре белән бүләкләнгән.




Фәтхуллин Мәхмүт Гомәр улы, 1918 елда туган, гвардия старшинасы, чекист, II дәрәҗә «Ватан сугышы» ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән

Әгъләмов Әнвәр Әгъләм улы, 1915 елда туган, артиллерист, өлкән сержант, «Кызыл Йолдыз» ордены һәм күп медальләр белән бүләкләнгән.



Әгъләмов Әнвәр Әгъләм улы шәҗәрәсе (2015)





Шәйдуллин Нурулла Шәйдулла улы 1913 елда туган. Фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнашкан. «Кызыл Йолдыз» ордены һәм күп медальләр белән бүләкләнгән.



Заһидуллин Нурулла Заһидулла улы 1907 елда туган, элемтәче. Варшава, Берлинны азат итүдә катнашкан. «Кызыл Йолдыз» ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән.



Шәймәрдәнов Шамил Шәймәрдән улы (уңда).

Шәймәрдәнов Шамил Шәймәрдән улы 1913 елда туган, танкист-механик йөртүче, «Кызыл Йолдыз» ордены һәм күп медальләр белән бүләкләнгән. Аны 26 мәртәбә Верховный командующийның Рәхмәт язуы белән бүләклиләр. Бу бүләкләр буенча солдатның үткән юлын күзәтеп була. Менә алар ни өчен бирелгән:

23.07.1943 ел – Курск-Орлов Дугасында поляк-немец һөжүмен туктаткан өчен.

16.09.1943 ел – Орел шәһәрен азат иткән өчен.

23.09.1943 ел – Чернигов шәһәрен азат иткән өчен.

19.11.1943 ел – Овруч шәһәрен азат иткән өчен.

30.12.1943 ел – Коростенев шәһәрен азат иткән өчен.

03.01.1944 ел – Новгород-Волынский шәһәрен азат иткән өчен.

12.01.1944 ел – Сарна шәһәрен азат иткән өчен.

05.02.1944 ел – Ровно шәһәрен азат иткән өчен

05.03.1944 ел – Изаславль шәһәрен азат иткән өчен.

17.03.1944 ел – Дувно шәһәрен азат иткән өчен.

19.03.1944 ел – Кременец шәһәрен азат иткән өчен.

18.07.1944 ел – Львов юнәлешендә немецлар оборонасын өзгән өчен.

20.07.1944 ел – Рава-Русская шәһәрен азат иткән өчен.

28.07.1944 ел – Ярослав шәһәрен азат иткән өчен.

18.08.1944 ел – Висла елгасын кичкән һәм Сандомир шәһәрен азат иткән өчен.

13.01.1945 ел – Көнбатыш юнәлештә немецлар оборонасын өзгән өчен.

15.01.1945 ел – Кельни шәһәрен азат иткән өчен.

18.01.1945 ел – Петраков шәһәрен азат иткән өчен.

21.01.1945 ел – немец шәһәре Трахтенбергны алган өчен.

11.02.1945 ел – Одер елгасын кичкән һәм немец шәһәре Штеинауны алган өчен.

14.02.1945 ел – немец шәһәре Шпротауны алган өчен.

15.02.1945 ел – немец шәһәре Зорауны алган өчен.

23.04.1945 ел – Шпрее елгасында немецлар оборонасын өзгән өчен, Шпрее елгасыннан Эльба елгасына чыгуны оештырган өчен.

27.04.1945 ел – немец шәһәре Биттенбергны алган өчен.

02.05.1945 ел – Берлинның көньяк-көнчыгышындагы немец гаскәрләрен тар-мар иткән өчен.

09.05.1945 ел – Чехословакия башкаласы Праганы азат иткән өчен.



Солдатның куен кесәсендә сугышны (Европаны) узган фото. Кечкенә Равил, ягъни мин (ике яшь), абыем Әзһәм һәм әбием Фагилә белән.

Берлинга 60 чакрым кала аларның частен Прагада чолганышта калган Власов армиясен һәм Прага шәһәрен азат итәргә юнәлтәләр. Прага шәһәре инде Берлин алынганнан соң һәм Җиңү игълан ителгәннән соң гына азат ителә. Шулай итеп Шамил Шәймәрдәновка сугышның беренче көненнән башлап соңгы көненә кадәр сугышырга туры килә.

Изге җиребез өчен яуларда һәлак булучылар арасында да бик күп батырлыклар күрсәткән авылдашларыбыз була. Мәсәлән, Шәйхетдинов Сабиржан («Хәтер» китабында ул Юнысов Сабир Шәрәфетдинович дип китерелгән), 1905 елда туган, гвардия өлкән сержанты, 89 номерлы укчы дивизия составында сугыша. 1944 елның 3 февралендә Черкасск (Киев) өлкәсе, Шполянский районы, Крымки авылында җирләнгән. Сугышка кадәр колхозда бригадир, авыл Советы председателе булып эшләгән. Шәрәфетдинов (Юнысов) Сабиржан белән бергә сугышкан, ул һәлак булгач, аны җирләгән. Сарман районы, Шәрләрәмә авылы кешесе Гайнетдинов Мөхәммәтнең М. Фәтхуллинга язган хатында мондый юллар бар: «Шәрәфетдинов Сабиржан погиб в боях Херсон-Шевельковского направления в феврале 1944 года. Похоронен в дер. «Крымки» (Крынки.) Звенигородского

района во дворе частного дома. Награжден: орденами «Отечественной войны» I и II степеней, дважды орденом «Красной Звезды», Орденами «Славы» II и III степеней, медалью «За отвагу». Старшина-наводчик станкового пулемета. Бик кыю кеше иде. Ташлыяр авылында авыл Советы председателе булып эшләгән». Бу хат Мәхмүт абый оештырган мәктәптәге архивта саклана.

Сугыштан соң авылга кайтмыйча, бүтән өлкәләрдә яшәп калучы авылдашлар да була. Мәсәлән, мин әле сугыштан соң капитан дәрәҗәсендәге Фәттах абыйның әнисе янына (Мочтак Фәттахы дип йөртәләр иде) кайтканын хәтерлим.

Фәтхуллин Фәрит Әбүбәкер улы – өлкән лейтенант, авиация технигы. Сугыштан соң Мәскәүдә Внуково аэродромында авиация технигы булып эшли.

Сугышта һәлак булучылар арасында:

Абдуллин Мөхәммәтулла – 1917 елгы, лейтенант, разведчик.

Абдуллин Яббар – 1914 елгы,

1943 елны Воронеж өлкәсендә һәлак була

Бакиров Мөнәвир – 1922 елгы, пантонер,

Гомәров Суфиян – 1923 елгы, лейтенант, танк командиры.

Сәйфуллин Габдулла – 1926 елгы, офицер.

Сәрвәров Фәррәхетдин Сәрвәр улы 1902 елда туган.

1942 елның 21 мартында вафат була. Новгород өлкәсе, Старорусский р-он, дер. Пенно (Деревково)

Нуретдинов Әмир – өлкән лейтенант, очучы-истребитель.

Хөснимәрдәнов Шәйхелмәрдән – лейтенант.

Шәрәфетдинов Нурулла – 1904 елгы. 1942 елда Сталинградта Мамай кургашында һәлак була.

Сугышта һәлак булучыларның исемен «Хәтер» китабыннан укырга була. Ләкин бу китапка сугышка бүтән өлкәләрдән, шәһәрләрдән киткән авылдашлар кермәгән.



Фин сугышында катнашкан Абдуллин Яббар Абдулла улы (уңда), 1911 елда туган. 1943 елның 24 гыйнварында төшерелгән фото.



Абдуллин Яббар Абдулла улы күмелгән туганнар каберлеге Воронеж өлкәсе, Хохлов районы, Скупой авылында.



Ганиев Фазлый Гани улы 1901 елда туган. 1945 елда госпитальдә үлә.



Сәрвәров Фәррәхетдин Сәрвәр улы 1902 елда туган. 1942 елның 21 мартында вафат була. Новгород өлкәсе, Старорусский районы, Пенно (Деревково) авылында җирләнгән.



Шәйдуллин Нигъмәтгата Шәйдулла улы 27.06.1941 хәбәрсез югала (сулда), Гатауллин Мәхмүт Гата улы исән кайта (уңда).



Шәрәфетдинов Сабиржан Шәрәфетдин улы 1905 елда туган, офицер. 1943 елгы фото. Сугыш беткәч, Украинада бандитлар пулясыннан һәлак була.



Абдуллин Әсгать Абдулла улы 1913 елда туган, 1942 елда Смоленск өлкәсендә яраланган.



Авзалов Сәхбетдин Авзал улы 1904 елда туган, Киевне азат итүдә катнашкан.



Вәлиев Камалетдин Вәли улы 1907 елда туган, стрелок-автоматчик-пулеметчик.



Гайфуллин Салих Гайфулла улы 1903 елда туган, Мәскәү оборонасында сугышкан.



Галимов Идият Гали улы. Ленинград оборонасында сугышкан.



Гыйльфанов Госман Гыйльфан улы 1921 елда туган, Кырымны азат итүдә катнашкан.



Дәүләтов Миңнемөхәммәт Дәүләт улы 1911 елда туган, артиллерист. I Украина фронтында яраланган.



Заһидуллин Хәбибулла Заһидулла улы 1915 елда туган, артиллерист. Белоруссия фронтында сугышкан.



Зарипов Таһир Зарип улы 1925 елда туган.



Зиннуров Сәхбетдин Зиннур улы 1922 елда туган, кече сержант, пулеметчы. Японнарга каршы сугышта катнашкан.



Зиннуров Мизхәт Зиннур улы 1925 елда туган.



Кашапов Ясир Кашап улы 1927 елда туган, сержант. Литва, Латвияләрне азат итүдә катнашкан.



Латыйпов Сәхипҗан Латыйп улы.



Миңһаҗев Мәүҗетдин Миңһаҗ улы (уң якта). 1921 елның 15 феврале. Разведчик. Украина фронтында сугышкан.



Миңһаҗев Таҗетдин Миңһаҗ улы 1925 елда туган. Старшина (Атлас авылыннан).



Насыйров Сабиржан Насыйр улы 1923 елда туган, артиллерист, элемтәче. Японнарга каршы сугышта катнашкан.



Сафин Әхмәтзыя Сафа улы 1909 елда туган, Калинин фронтында сугышкан.




Сәрвәров Мөхәммәтдин Сәрвәр улы 1926 елда туган, кавалерист. Японнарга каршы сугышта катнашкан.



Сәлимов Касыйм Сәлим улы 1915 елда туган.



Сәхбетдинов Гыйззетдин Сәхбетдин улы 1902 елда туган. Калинин фронтында яраланган.



Талипов Шәймәт Талыйп улы 1903 елда туган. Калинин фронтында яраланган.



Фәтхуллин Мидхәт Гомәр улы 1920 елда туган, лейтенант, артиллерист. Кавказда һәм Белоруссия фронтында сугышкан.



Харисов Зөфәр Харис улы (уртада) 1925 елда туган.



Фәйзуллин Шәйдулла Фәйзулла улы – Атлас авылыннан.



Хәмидуллин Нуриәхмәт Хәмидулла улы 1915 елда туган, кладовщик. Варшава, Сталинград, Берлинны азат итүдә катнашкан.



Хөснуллин Мирзасалих Хөснулла улы 1900 елда туган.



Хөснуллин Зиннәт Хөснулла улы 1909 елда туган. Варшаваны азат итүдә катнашкан.



Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт Шәймөхәммәт улы



Шәймәрдәнов Тәлгать, Атлас авылы



Шәйхлисламов Ислам Шәйхислам улы 1915 елда туган. гв.өл.лейтенант. Взвод командиры. Белоруссия фронтында яраланган.



Әюпов Әфган Әюп улы 1927 елда туган, Һава Көчләре гаскәрендә японнарга каршы сугышта катнашкан.



Бөек Ватан сугышында катнашучылар:
Басып торучылар: Абдуллин Ә., Кашапов Я., Минһаҗев М., Фәтхуллин М., Сәлимов К., Сафин Ә.
Утырып торучылар: Авзалов С, Гайфуллин С., Халиков З., Талипов Ш., Хөснуллин М.

Шатлык булып Җиңү килгәч...

Сугыш беткәч, яуда исән калган авылдашларыбыз кайта башлый. Колхоз хуҗалыгын торгызу өчен бөтен көчне тупларга туры килә. Тормышның авырлыгы һаман да хатын-кызлар җилкәсенә төшә. Яз җитүгә, 70–80 чакрым ераклыктагы Чаллы, Курья элеваторларыннан бәләкәй чана белән чәчүлек орлык ташу башлана. Март азагы, апрель башларында кузгала торган бу эш хатын-кызларга йөкләнә. Юлга дип бирелгән бер-бер ярым килограмм онның яртысын алар балаларына бүлеп калдыралар. Ярымач хатын-кызларга, чана тартып, сулы лыштырдык кар ярып барырга, һәр чанага салынган 50 килограмм орлыкны тартып кайтырга туры килә. Авылга әйләнеп кайтканда, аларның аякларындагы чабаталары тузып, таралыр хәлгә җитә торган була иде. Мин – бу хәлләрнең шаһиты. Басуларны буш калдырып булмый, ничек тә чәчәргә кирәк. Кайберәүләр үгез җигеп, икенчеләре үз сыерларын җигеп, җир эшкәртергә мәҗбүр иделәр. Ат сабанына 6–8әр кеше арканнар белән җигелеп, үзләренең бәрәңге бакчаларын сөргән чаклар да булган.

Дәүләт тарафыннан «СССР халык хуҗалыгын торгызу һәм үстерү заемнары» чыгарыла. Ярлы, ач халык шуның өстенә заемнарга (салымга) язылырга тиеш булды. 1947 елның 17 декабрендә акча әйләнешенә реформа үткәрелә.

Дәүләт заемнары 1958 елга кадәр чыгарылды. Заемнарга яздыру аңлату юлы белән генә түгел, мәҗбүриләп тә алып барылды. Кешеләрне төнлә идарәгә чакырып, көчләп-көчләп заемга яздырдылар. 1947 елда базарда бер кием чабата 10–15 сум, бер кадак (400 грамм) май – 10–15 сум, бер пот арыш оны 750 сум булган. Гомумән, сугыш һәм сугыштан соңгы елларда халыкны ачлыктан сыер белән бәрәңге җире коткарып калды.

Сугыш елларында авыл Советы территориясендәге өч колхоз да икономик яктан бик нык какшый. 1953 елда «Марс», «Ярыш», «Удар» колхозлары яңадан «Марс» исеме белән бер хуҗалыкка берләшәләр. Аның белән агроном булып эшләгән Шәяхмәтов Хаҗи (1953–1955) җитәкчелек итә. 1955 елда колхозны ныгыту өчен утызмеңче Сафиуллин Хәбиб Насрулла улы (1915 елда туган, Мәлләтамак авылыннан) килә. Ләкин ул август аеннан декабрь азагына кадәр генә эшли. 1956 елда хуҗалык белән Баязитов Зәки (1921 елгы, Баланны авылыннан), ә 1957 елның 1 январеннан 14 мартына кадәр Фәтхуллин Мәхмүт җитәкчелек итә.

«Марс» колхозының сугыштан соңгы икономик хәле түбәндәге саннарда ачык күренә:

Икономик эш юнәлешләре	**1940**	**1950**	**1952**	**1953**
Колхозда тотылган хезмәт-көннәр саны	*96114*	*82685*	*82701*	*77143*
Чәчү мәйданы (га)	*1404*	*1489*	*1832*	*1990*
Бөртеклеләрнең 1 га-дан уңыш	*5,57 ц* *8,87 ц*	*6,43 ц* *15,70 ц*	*8,44 ц* *27,30 ц*	*8,71 ц* *9,82 ц*
Бер хезмәт көненә бирелгән акча	*2 тиен*	*4 тиен*	*22 тиен*	*24 тиен*
Бер хезмәт көненә бирелгән икмәк	*900 г*	*425 г*	*1,1 кг*	*1,1 кг*
100 гектарга җитештерелгән ит	*60 кг*	*300 кг*	*460 кг*	*800 кг*
Бөртеклеләрнең тулай җыемы	*8194 ц*	*9887 ц*	*12760 ц*	*13751 ц*
Мөгезле эре терлекләр саны	*103 баш*	*153 баш*	*180 баш*	*230 баш*
Дуңгызлар	-	*144*	*234*	*262*
Сарыклар	*104 баш*	*559*	*593*	*708*
Кошлар саны	*534 баш*	*894*	*2262*	*3889*
Атлар саны	*272 баш*	*138*	*148*	*160*
Буаз бияләр	*30 баш*	*37*	*53*	*53*
Савым сыерлар	*34 баш*	*36*	*50*	*67*
Зур сарыклар	*84 баш*	*337*	*224*	*486*
Ана дуңгызлар	*3 баш*	*47*	*35*	*62*
Бер сыердан савылган сөт (кг)	*1004*	*1143*	*976*	*740*
Һәр тавыктан йомырка (данә)	-	*33*	*9*	*21*
Колхозның акча кереме (сум)	*85853*	*100030*	*128048*	*150210*
Колхозның төп кереме (сум)	*54877*	*204919*	*805686*	*223830*
Чәчүлек орлык салу (центнер)	-	-	*2748*	*2530*
Фураж салу (центнер)	-	-	*715*	*1377*

Ташлыяр «Мөслим» совхозы составында

1957 еллар башында дәүләт һәм партия колхозларны, авыл хуҗалыгы предприятиеләрен эреләндерү политикасын уздырырга кереште. Районда берничә колхозны «Мөслим» совхозына кушу көн тәртибенә куела. Берләшәсе хуҗалыкларның алдан гомуми җыелышларын уздырып карар чыгаралар. Шундый җыелыш 1957 елның 14 мартында район җитәкчеләре, «Мөслим» совхозы директоры, партком секретаре һәм «Марс» колхозы җитәкчеләре (председатель Фәтхуллин М.Г., партком секретаре Нуретдинова Р.Н., авыл Советы председателе Сәлимов К.С.) катнашында Ташлыяр авыл клубында уздырыла. Халык бертавыштан совхозга кушылырга дигән карар кабул итә. Ул вакытта бу карарның үзләренең ата-бабадан калган җирләреннән баш тартып, аларны хөкүмәткә тапшырырга ризалык бирү икәнлеге беркемнең дә башына килми. Шуның аркасында бүгенге көндә Ташлыяр кешеләренең бер сутый да пай жире юк.

1957 елның мартында район Советы башкарма комитеты, «Кызыл Сабанчы» (Туйгелде), «Марс» (Ташлыяр), «Искра» (Михайловка), «Мәдәният» (Баланны), «Красный путь» (Ново-Егорьевка) колхозчыларының гомуми җыелышлары беркетмәләрен карап, бу хуҗалыкларның «Мөслим» совхозына кушылулары турында карар чыгара. Ул вакытта совхозның директоры Комаров Л.И., партком секретаре Исмәгыйлов Г., баш агроном Төхбәтуллин Ч., баш зоотехник Николаевский Н., вет.врач Блинова Н., прораб Гайсин Мирза була.

ИСКӘРМӘ: «Мөслим» совхозы 1929–1930 елларда оеша, «Овцевод» исемен йөртә. 1929–1931 елларда совхозның беренче директоры Федоров дигән кеше була. Совхозга 30 меңнән артык сарык кайтарыла. 1931–1942 елларда хуҗалыкны Власов дигән кеше җитәкли. Ул эшләгәндә 33 мең сарыкның күпчелеге бруцеллез авыруыннан үлә. Исән калган 3000 сарыкны Кавказга озаталар. Совхоз директорын гаепләп, атарга хөкем чыгаралар. Соңыннан аны сугышка, штраф.батальонга җибәрәләр. Ул сугыштан бер аягын өздереп исән кайта, Мамадышта заготконтора директоры булып эшли.

Совхозның сарык фермалары Михайловка авылыннан кордонга бара торган юл өстендә тау башында урнашкан була. Әле илленче елларда да бер ак бинасы исән иде. Шуның өчен бу урынны «Ак йорт тавы» дип йөрттеләр. Ул тауда жир жиләге бик уңа иде. Хәтта без, Ташлыяр авылы кешеләре, шул тауга жиләк җыярга бара идек. Ул елларда «Игенче» авылы (аны халык телендә «Ник килдем» дип тә йөрттеләр) «Овцевод» совхозы составында була. Игенченең урман артында урнашкан Югары Табын авылы янындагы басуларын «Донбасс» дип атадылар. Донбасста терлекчеләр өчен йортлар төзелә һәм бу басуларны сарык көтү өчен файдаланалар.

1941–1942 елларда «Овцевод»та, соңрак «Мөслим», «Михайловка» совхозында директор булып Моратов Гали Хафиз улы – 1946–1948 елларда; Гаделшин – 1948–1958 елларда; Комаров Леонид Иванович – 1958–1963 елларда; Сәләхетдинов Гадел Касыйм улы – 1963–1978 елларда; Хәлиуллин Вәли Сибгат улы; 1978 елдан Әхмәтов Мәхмүт Әхмәт улы эшләде. 1957 елдан «Овцевод» совхозы – «Мөслим» совхозы, ә соңрак «Михайловка» совхозы итеп үзгәртелде.

Совхозга кушылгач, Ташлыяр бүлекчәсендә управляющий булып түбәндәге кешеләр эшләде:

Фәтхуллин Мәхмүт	1957 елның 14 мартыннан 18 июненә кадәр
Шәйхетдинов Нурулла	1957–1960
Гайсин Ягъфәр	1960–1963
Фәрхетдинов Мөкәррәм	1963–1964
Гыйлажев Әнвәр	1964–1965

Элекке колхоз җирләренә «Игенче» хуҗалыгының Югары Табын авылы ягындагы җирләре («Донбасс» басуы) кушыла һәм бүлекчәнең чәчү мәйданы шактый арта. Бүлекчәдә, иген үстерүдән тыш, атлар, мөгезле эре терлекләр, дуңгызлар һәм тавыклар асрала. 1958 елда төзү бригадасы бригадиры Шакиров Нәҗип җитәкчелегендә 30 мең данә сәмән, 8000 данә кызыл кирпеч сугалар, сыерлар торагы төзелә. 1958 елда зур дебитлы яшелчә чишмәсенә ике гидротурбина (гидротаран) куела, чишмәдән колхозның мал абзарларына кадәр чуен торбалар сузыла, су китерелә. Соңрак бу чишмә суы колонкалар куеп, авылга да китерелә.

ИСКӘРМӘ: Бу яшелчә чишмәсе суын хәзерге вакытта куәтле насослар ярдәмендә район үзәгенә куалар, Мөслим халкы Ташлыяр чишмәсе суын эчә.

1958 елда совхоз директоры Л.И.Комаров инициативасы белән Каран суын буып, Кавказдан алып кайтып, 3000 данә алтын карп маймычлары җибәрелә. Ләкин чишмә суының салкын булуы аркасында, бу балыклар 600–700 граммнан артык үсә алмый, кайбер кешеләр балыкны җыю нияте белән, хәтта, буаны яралар. Мәллә елгасына карп балыклары менә шулай тарала.

1958 елда авылда 137 штатлы эшче (профсоюз членнары) була. 1959 елда Туйгелде, Ташлыяр, Михайловка авыл Советлары кушылып, Михайловка авыл Советына берләшә. Авыл Советы председательләре булып Исмәгыйлов Габдрахман, Кошкин Валентин Иванович, Солтанов Нургали; секретарьлары булып Җәләева Рәзимә, Черногорлов Василий эшли. Хуҗалыкның баш зоотехнигы Хисмиев Серенад, баш инженеры Сәлиев Фәгыйл була. Шушы ук елларда Атласта яңа мәктәп бинасы төзелә. Укытучы булып Мәлләтамак авылыннан Уразманова Сәлимә эшли. 1959 елда «Мөслим» совхозы бөртекле культураларның һәр гектарыннан 17,1 центнер уңыш җыеп ала.

1960 елда, Н.С.Хрущев инициативасы белән, авылларның шәхси хуҗалыкларында сыерлар бетерелә. Сыерларны совхоз сатып алды. Сөтне совхоз фермасыннан халыкка урам буйлап сатып йөрделәр. Мин бу елларда авылда фельдшер булып эшли идем һәм кызыл сыерыбызны үз кулларым белән илтеп тапшырдым. Сыерларны бетерүне авыл халкы бик авыр кичерде. Чөнки сыер гомер буе авыл халкының туйдыручысы, сугыш һәм сугыштан соңгы мохтаҗ елларда ачлыктан, үлемнән коткаручысы булды.

1961 елда Ташлыярда яңа ясле-бакча салына һәм Нуретдинова Нәсиха җитәкчелегендә ясле эшли башлый, аңа 17 бала кабул ителә.



Балалар бакчасында тәрбияләнүче балалар һәм тәрбиячеләр. 1972 ел.

1963 елда Мөслим районы бетерелеп, Сарманга кушыла һәм бу административ система 1965 елга кадәр дәвам итә. Бу берләштерү безнең файдага булмады. Районның кайбер биналарын Сарманга күчереп салдылар (колхозлашу чорларында байларның йортларын күчереп салуны хәтерләтә бу.)

1963 елдагы административ бүленеш:



1965 елда яңадан Мөслим районы оешкач булган административ бүленеш:



1957 елны Ташлыяр авылына чыбыклы радио керттеләр. Михайловка авылыннан югары оч болыны аркылы 1-1,5 чакрым арага баганалар утыртып, чыбык суздылар. Һәр йортның түбәсенә тимердән таяклар (гусаклар) җайлап (күбесенчә салам түбәле йортларга бу эшне башкару аерым кыенлыклар тудыра иде), һәр йортка радио-точка – сөйли торган кара төстәге тарелкалар куелды. Моңарчы яңалыкларны колактан-колакка гына ишетеп, яки сирәк килә торган газеталар аша белгән халыкка бу хәл зур революцион вакыйга булды. Баштарак кешеләр, дөнья эшләрен ташлап, радио тыңлау белән шактый нык мавыктылар. Минем өчен радио, яңалыклардан кала, беренче чиратта музыкаль зәвыкны арттыру чарасы булды. Радиодан көн саен концерт программасы бирәләр. Яңа көйләр, яңа башкаручылар белән танышу мөмкинлеге артты. Хәтерлим: мин бер тыңлауда «Яшьлек вальсы»н отып алып, шунда ук гармунда уйный башладым.

1964 елда җәй көне, баганалар утыртып, безнең авылга электр кертелде.

Ташлыяр бүлекчәсендә барлыгы 1806 гектар чәчүлек җирләрнең һәр гектарыннан 1958-1964 елларда алынган уртача уңыш түбәндәге таблицадан күренә:

1958 елда – 10,64 центнер
1959 елда – 17,2 центнер
1960 елда – 12,2 центнер
1962 елда – 13,4 центнер
1963 елда – 9,3 центнер
1964 елда – 16,95 центнер

Гомумән, «Мөслим» совхозы составында яшәгән елларда (1957-1965) Ташлыярда терлек тораклары, амбарлар, социаль объектлар төзүгә зур игътибар бирелә. Бу елларны яңарыш еллары дип атарга нигез бар.

«Трудовик» совхозы белән берләшкәч...

РСФСР Министрлар Советының 1965 елның 11 декабрь № 119-1 карары нигезендә, «Мөслим» совхозы составындагы Ташлыяр, Игенче, Туйгелде, Атлас, Баланны авылларының бер өлеш җирләрен бүлеп алып, «Трудовик» совхозы оештырыла. Аның үзәге Туйгелде авылында була. Яңа совхозга 9225 гектар җир

беркетелә. Хуҗалык өч бүлекчәдән тора, һәрберсенә түбәндәге күләмдә сөрүлек җирләре беркетелә:

Туйгелде бүлекчәсе – 2144 гектар
Игенче бүлекчәсе – 2024 гектар
Ташлыяр бүлекчәсе – 3295 гектар
Башка җирләр:
II – бүлекчәләргә – 1010 гектар
III – Ташлыяр бүлекчәсенә – 752 гектар.



Камалов Мисбах.

Шулай итеп, Ташлыяр бүлекчәсенә 4047 гектар, яки совхозның 54,2 процент җире беркетелә. Совхоз директоры итеп Морзаханов Әзһәр Морзахан улы (Нарат-Асты авылыннан) билгеләнә. Ул 1975 елга кадәр эшли. 1975 елдан совхозны Баһауов Мирзаян Әсләхетдин улы җитәкли. М.Ә.Баһауов эшләгән елларда Ташлыяр авылында һәрбер йортка табигый газ кертелде, Мәллә елгасы аркылы капиталь күпер төзелде. Авылга асфальт юл китерелде һәм Ташлыяр урамы асфальтланды. Бу эшләрне башкаруда «Трудовик» совхозының баш бухгалтеры булып эшләүче Ташлыяр кешесе Камалов Мисбах зур өлеш кертте.

«Ташлыяр» совхозы

1990 елда «Трудовик»тан аерылып, Ташлыяр бүлекчәсе нигезендә яңа хуҗалык – «Ташлыяр» совхозы – тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы оештырыла. Совхозга Ташлыяр һәм Атлас авылы басулары (барлыгы 4047 гектар, шулардан 3295 гектар чәчүлек җирләре) беркетелә. Бу совхозга сортлы чәчү орлыклары үстерү бурычы куела. Хуҗалыкка директор итеп Минзәлә районының «Гигант» колхозында баш агроном булып эшләгән ТАССРның атказанган агрономы Ташлыярда туып-үскән Шәймәрдәнов Илдус Гафур улы чакырыла. ОПХ оешу белән аның материаль базасын ныгытуга зур әһәмият бирелә. 1250 башка исәпләнгән дуңгыз симертү комплексы, мастерской, ябык ындыр табагы төзелә; 10 трактор, 10 яңа машина сатып алына. Атлас авылына газ һәм телефон уздырыла. Ленинград, Ярославль өлкәләреннән һәм Бөгелмә районы хуҗалыкларыннан нәселле таналар кайтарыла. Ташлыяр авылы урамына асфальт җәелә, мәчет төзелә. Совхоз ярдәме белән авылда бу елларда 15 яңа йорт салына. 1991 елда совхозда һәр гектардан 25,4 центнер (район буенча – 20,4 ц) уңыш җыела, һәр сыердан 3236 кг (район буенча – 3025 кг) сөт савып алына. Совхозда 1250 баш мөгезле эре терлек була. 1994 елдан 2000 елга кадәр совхозны Авзалов Ринат Сәхәбетдин улы җитәкләде.

2000 елда «Ташлыяр» кабат «Трудовик» совхозына кушыла һәм бүлекчә булып кала. Бүлекчәнең управляющие булып Авзалов Р.С. эшли.

1990 елда «Трудовик» совхозының директоры М.Ә. Баһауов Мәслим район



Авзалов Ринат Сәхәбетдин улы туганнары белән.

Советы башкарма комитеты рәисе итеп сайлангач, совхозга директор итеп Ташлыярда туып-үскән, моңарчы төрле колхозларда партком секретаре, председатель булып эшләгән югары белемле агроном Камалов Рафаэль Зиннур улы билгеләнә. Ул директор булып эшләгәндә, Татарстан Югары Советы депутаты итеп сайланды.

1990 елларда башланган «Перестройка» шаукымы авылларның яшәү рәвешен үзгәртә башлады. Колхоз-совхозлар бетерелде, аларның җирләрен, малларын, техникасын һәм торак-каралтыларын инвесторларга бирделәр. Ташлыяр, Михайловка, Баланны хуҗалыклары җирләре белән бергә, «Полимэкс» дип аталган акционерлык җәмгыятенә тапшырылды. Бу җәмгыятьнең хуҗасы Баланны авылында туып-үскән Вагыйзов Рамил Мөхтәр улы иде. Беренче эш итеп авыллардагы фермалар бетерелде, аларны саттылар. Ферма биналары, мастерскойлар сүтелеп, таралып бетте. Чәчү җирләре кыскартылды, күп кенә эшкәртелмәгән, калдау җирләр барлыкка килде, аларны чүп үлән, вак агач басты. Халык җирдән аерылды, яшьләр ата-бабадан килгән игенче һөнәреннән бизеп килә. Яңа буын яңа сугылган икмәкнең исен белми үсә. Ташлыяр җирләре хөкүмәтнеке булу аркасында, халык бөтенләй җирсез калды. Колхоз булган авылларда әле кешеләргә пай өлешенә җир бүлеп бирделәр. Шулай итеп, безнең ата-бабаларыбыздан калган җирләрдә «инвестор» дигән «яңа хуҗалар» ни тели, шуны эшләп йөриләр.

Кайчан гына булмасын, авылның социаль һәм экономик үсешен җитәкчеләр генә түгел, нигездә шушы җирдә эшләүче хезмәт кешеләре тәэмин итә. Алар – механизаторлар, терлек караучылар, авыл хуҗалыгы белгечләре һәм башка эшчеләр. Механизаторларның роле аеруча зур булды һәм ул бүген дә шулай булып кала. Авылның сугыштан соңгы еллардагы атаклы механизаторларыннан беренче чиратта Абдуллин Әсгать (тракторчы, комбайнчы), Абдуллин Миңнемөхәммәт



Фәтхуллин Мәхмүт белән Насыйров Сабиржан.



Сабуров Гафур.

(комбайнчы), Сабуров Гафур (тракторчы) абыйларны атап китәргә кирәктер. Бу буын механизаторлар чын мәгънәсендә легендар шәхесләр иде.

Алардан соң килгән буын механизаторларыннан Насыйров Сабиржан, Җәләев Мөдәррис, Гомәров Яхъя, Мөҗипов Шәйхенур кебек авылдашларыбыз игенче намусын югары тоту үрнәген күрсәттеләр.

Алардан соңрак Шәймәрдәнов Фарсый, Абдуллин Нәсим (тракторчы, комбайнчы), Гайфуллин Нурулла (комбайнчы) фидакарь хезмәтләре белән район күләмендә танылдылар.



Ташлыяр авылының бер төркем механизаторлары.





Мөҗипов Шәйхинур.

Язгы кыр эшләре вакытында уза торган семинарда.

Авылның шоферларыннан: Шәймәрдәнов Шамил, Галиев Хажи, Сөләйманов Мөдәррис, Нуруллин Рәис, Заһидуллин Гыйздулла, Шәрифуллин Зөфәр һ.б. үзләренең тырышлыклары, игелекле эшләре белән халыкның олы хөрмәтен казандылар. Авылның күп хезмәтчәннәре, шул исәптән, интеллигенция вәкилләре дә дәүләт бүләкләренә лаек булды.



1955 ел. Урып-җыю вакытында бер төркем авылдашлар.

«Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены белән бүләкләнүчеләр:

Туйкина Бәширә Шакир кызы – укытучы.

Камалов Зиннур Якуп улы – агроном.

Вәгыйзова Салиха Вәгыйз кызы – укытучы.

Минһаҗева Хөршидә – сыер савучы.

II дәрәҗә «Хезмәт даны» ордены механизатор Абдуллин Нәсим Яббар улы лаек булды.



Абдуллин Нәсим.



Харисов Рәшит.



Галиев Хаҗи.

ВДНХ медальләре белән бүләкләнүчеләр:

Авзалов Ринат, механизатор, управляющий

Камалов Зиннур, агроном

Абдуллин Нәсим, механизатор

Харисов Рәшит, шофер, бригадир.

Социализмнан ярым капиталистик җәмгыятькә күчкәч, кайберәүләр совет чорын тоташ хурлауны, шул исәптән, кешеләргә бирелгән мактау кәгазьләрен, хәтта орден-медальләрне дә калай кисәге дип мыскыллауны кәсеп итеп алды. Мин андый затларга нәфрәтләнеп карыйм. Дөньяны башлыча хезмәт кешесе тота. Алар тормыш өчен кирәкле барлык нәрсәне җитештерә: иген үстерә, азык-төлек әзерли, мәһабәт биналар күтәрә,



Сулдан уңга: Илдус, Әзһәм, Факил, Равил (1960 ел).

юллар сала, машиналар ясый. Алар буыннан-буынга шулай хезмәт куеп, илне үстерүгә үз өлешләрен кертеп, әллә ниләр дауламыйча, бу тормыштан тыныч кына китеп барганнар. Аларның фидакарьлеген күрсәтү билгесе булган грамоталарга, мактаулы исемнәргә, орден-медальләргә мәңге ихтирамлы булсак иде.

Авылда мәгариф эше

Революциягә кадәр укыту эше авылның өч мәхәллә мәдрәсәләрендә алып барыла. 1922 елларда балаларны советча укыту башлана. Укыту аерым кешеләрнең (Солтанов Асыл, Галимов Фатыйх, Раскулов Габделхак) өйләрендә оештырыла. Ата-аналар башта ир балаларны гына укытырга җибәрәләр. 1926 елга кадәр укыту эшен башлангыч классларда Чуар-Абдул авылыннан килгән Миңнегулова Сорур, Минзәләбаштан – Газизова Нәбирә, Мәндәй авылыннан – Зарипов Әхмәди, Ташлыярдан – Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт, Сарайлыдан Шакирова Әсхияләр бер-бер артлы дәвам итә.





Ташлыяр мәктәбендә – хезмәт дәресләре.



1926 елда авыл халкы Хафизетдин хәзрәттән калган иске мәдрәсәне үз көче белән, хәзерге Шәрифуллин Мөхәммәтдин һәм Баһманов Сабиржанның ихатасы башына, су буена мәктәп итеп сала. Укыту эше Раскулов Габделхакның таш амбары өстендәге өйдән яңа салынган мәктәпкә күчерелә. Укытуны Чукмарлы авылыннан килгән Мохтарова Җәүһәр, Шакирова Әсхияләр яңа мәктәптә дәвам итә. 1928 елда Минзәләбаш авылыннан мәктәп мөдире һәм укытучы булып Туйкина Бәширә (атаклы мәгърифәтче Туйкин Фазылның туганы) килә. Мәктәпне клуб итеп тә файдаланалар: халыкка докладлар укыла, концертлар, спектакльләр куялар.

1929 елның декабрь аенда Вәлиев Минһаҗ белән Туйкина Бәширәнең туе беренче комсомол туе итеп шушы бинада уздырыла. Туйкина Бәширә, Мохтарова Җәүһәр апалар һәм Туйгелде авылыннан килгән Максутов Галиәхмәтләр төп укытучылар булып, хөкүмәттән хезмәт хакы алып эшлиләр. Кәшиф Кормашовка, өстәмә комплект укытучы буларак (Чаллы кантоны мәгариф бүлеге белән төзелгән килешү буенча), халык үзе 20 сум хезмәт хакы түли.

1929 елда зур янгын вакытында бу мәктәп янып бетә. Бу янгында 82 йорт яна. Көн тәртибенә мәчетләрне мәктәп итеп файдалану мәсьәләсе килеп баса. Башта Аблак очындагы «Күк» мәчетне мәктәп итеп файдаланалар. Ул мәчет янгач, урта мәхәлләнең «Зәңгәр мәчет»ен мәктәп итеп үзгәртәләр. Укыту шушы мәчет бинасында 1983–1984 елларга, кирпечтән ике катлы мәктәп бинасы салганга кадәр дәвам итә. Мин үзем дә җидееллык мәктәпне шушы бинада укып тәмамладым.



Мәктәптә хезмәт дәресендә ясалган сыерчык ояларын урнаштыру

1929–1930 еллардан укыту яңалиф, латин графикасы нигезендә башлана. 1930 елның 14 августында Үзәк башкарма Комитет һәм СССР Халык комиссарлары Советы «Гомуми мәҗбүри башлангыч укыту турында» карар кабул иткәч, мәктәптә укучылар саны бик күпкә арта. 1929 елда наданлыкны һәм ярымнаданлыкны бетерү хәрәкәте илдә киң колач ала. Ташлыярда культармеецлар (активистларны шулай атыйлар) укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча «поход» башлыйлар. Бу эштә партия һәм комсомол членнары башлап йөри. 1929 елда язу гарәп алфавитыннан латин графикасына күчерелә (яңалиф). Укулар югары һәм түбән оч мәктәпләрендә көндез дә, кич тә оештырыла. Авыл Советы башкарма комитеты укуларның барышын көн дә тикшереп тора. Белем



Ташлыяр җидееллык мәктәбенең уку бинасы (Зәңгәр мәчет). 1958 ел.

алуга укый-яза белмәгән 16 яшьтән 35 яшькә кадәр ирләр дә, хатын-кызлар да тартыла. Уку программасын төгәлләгәч, мәктәпне тәмамлаган һәр кешегә матур итеп эшләнгән таныклыклар бирелә. Бу эштә түбәндәге «культармеецлар» зур активлык күрсәтәләр: Галимов Зиннәт, Мәксутов Галиәхмәт, Авзалов Миңнәхмәт, Шәфыйков Вагыйз, Шәйхетдинова Разия, Туйкина Бәширә, Нуретдинова Нәсиха, Вәлиев Мөнир һәм башкалар.

1938–1939 елларда авылда, нигездә, укый-яза белмәүчелек бетерелә. ТАССР Верховный Советы Президиумының 1939 елгы 5 май Указы нигезендә, татар язуы латин графикасыннан урыс графикасына (кириллицага) күчерелә. Клуб, уку йорты эшчеләре, мәктәп укытучылары, барлык активистлар «Кызыл Татарстан» газетасында кайта торган уку үрнәкләре белән башта үзләре танышалар, аннан соң, авылны участокларга бүлеп, халыкны яңа уку графикасына өйрәтәләр.

1935 елда Ташлыяр мәктәбе 7 класслы тулы булмаган урта мәктәп статусын ала, 1962 елда сигезьеллык, ә 1991 елда урта мәктәп итеп үзгәртелә. 1965 елда, кичке бүлек ачылып, VIII–IX–X классларда укулар башлана. 1969 елда кичке бүлекне 12 кеше тәмамлый. Елдан-ел укучылар саны кимүне сәбәп итеп, Ташлыяр мәктәбе 2005 елда – тугызеллык, ә 2010 елда башлангыч мәктәп кенә булып калды. Ә инде 2012 елда ул урыс авылы Михайловка урта мәктәбенең филиалы итеп үзгәртелде. Дөрес, элек тә безнең авылдан күршедәге Михайловка мәктәбендә урыс телендә белем алучылар аз булмады. Мәсәлән, безнең гаиләдә 7 баланың өчесе Михайловка урта мәктәбендә укыды.

1990–1997 елларда Татарстан Республикасы мәгариф министры булып эшләгән Васил Габдулла улы Гайфуллин, Минзәлә дәүләт педагогика укуханәсен тәмамлагач, хезмәт юлын Ташлыяр җидееллык мәктәбендә башлый. 1955–1956 уку елларында урыс, алман, физкультура, хезмәт дәресләрен укыта. «Ул вакытта Котдус Хөснуллин, Алфира Вәлиева кебек шәхесләр җиденче сыйныфта гыйлем эстәде», – дип искә ала ул бүген.



Васил Габдулла улына 80 яшь. Сулдан уңга –Садриева Лилия Ясир кызы, Шәймәрдәнов Равил Шамил улы, Бакиров Марсель Хәернас улы, Гайфуллин Васил Габдулла улы, Садриев Фоат Миңнәхмәт улы, Әхмәтҗанов Мөҗәһит Заһит улы. 2017 ел.

Ташлыяр мәктәбендә озак еллар эшләп, бик күп буын балаларына белем һәм тәрбия биргән укытучылардан Әхмәтова Рәшидә, Лофуллина Асия, Вагыйзова Салиха, Закирова Фәрдәнә, Фәтхуллин Мәхмүт, урта буын укытучыларыннан Раскулова Равилә халыкның тирән ихтирамын казанды.

Вагыйзова Салиха апа «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены, Фәтхуллин Мәхмүт абый «Халык мәгарифе отличнигы» значогы белән бүләкләнде.

Төрле елларда Ташлыяр авылы мәктәбе мөдире һәм директоры булып түбәндәге кешеләр эшләде:

Газизова Нәбирә – Минзәләбаш авылыннан
Миңнегулова Сорур – Чуар Абдул авылыннан
Зарипов Әхмәди – Мәндәй авылыннан
Аблаков Шәмсемөхәммәт – Ташлыярдан
Шакирова Әсхия – Сарайлы авылыннан
Кормашев Кәшиф – Тәкермән авылыннан
Мохтарова Җәүһәр – Чукмарлы авылыннан (1926–1928)
Туйкина Бәширә – Минзәләбаштан (1928–1930)
Мәкъсутов Галиәхмәт – Туйгелдедән (1930–1931)
Халитов Габдрахман – Баланныдан (1931–1932)
Мөхәммәтҗанов Нурлыгаян – Мәлләтамактан (1932–1934)
Мусин Лотфулла – Әгерҗе районыннан (1934–1935)



Вагыйзова Салиха (уң яктан – беренче).

Шәйхуллин Мирза – Салауз-Муханнан (1935–1941)
Нурыева Мәдинә – (1941)
Халиков Әхәт – Ташлыярдан (1941)
Фәтхуллин Мәхмүт – Ташлыярдан (1941–1942)
Шәйхетдинов Тәлгать – Ташлыярдан (1942–1943)
Фәтхуллин Мидхәт – Ташлыярдан (1943–1944)
Закирова Фәрдәнә – Ташлыярдан (1944–1945)
Хәбибуллин Хәй – Ташлыярдан (1945–1947)
Монасыйпов Миңнәхмәт – Ташлыярдан (1947–1952)
Нуретдинова Рабига – Ташлыярдан (1952–1959)
Фәтхуллин Мәхмүт – Ташлыярдан (1959–1971)
Зарипов Роберт – Вәрәшбаштан (1971–1979)
Рәхмәев Вазыйх – Красноярдан (1979–1982)
Гыйзетдинов Назиф – Югары Табыннан (1982–1985)
Хафизов Фәнис – Метрәйдән (1986–1993)
Габидуллин Наил – Красноярдан (1993–2011)
Гафурова Гөлүсә – (2011–2014)
Сәрвәрова Рәмилә – (2014–




Туйкина Бәширә.



Халитов Габдрахман.



Мохтарова Җәүһәр.



Мөхәммәтҗанов Нурлыгаян



Фәтхуллин Мәхмүт



Закирова Фәрдәнә



Монасыйпов Миңнәхмәт



Нуретдинова Рабига



Зарипов Роберт



Хафизов Фәнис



Гафурова Гөлүсә



Сәрвәрова Рәмилә



7 класс чыгарылышы. 1954 ел.



23.11.1955 ел.



8 класс чыгарылышы. 1968 ел.



4 класс. 1970 ел.



Класста 31 бала (1958–1959 елда туган балалар). 1971 ел.



8 класс чыгарылышы. 1976 ел.



7 класс. Мөслим район үзәгенә комсомолга керергә килгәннәр. 1977 ел.



Закирова Фәрдәнә апа белән.



8 класс чыгарылышы. 1978 ел.



1 һәм 2 класс укучылары
1978 ел.



1981 ел. 1 сентябрь.



Ташлыяр мәктәбе укытучылар коллективы. 1984–1985 уку елы.



Ике класс бергә. 1988 ел.



1987–88 чыгарылыш укучылары. 8 класс.



Ташлыяр мәктәбе укытучылары коллективы. 1991–1992 уку елы.



1990–1991 уку елы.



1990–1991 уку елы.



1992–1993 уку елы.



1995–1996 уку елы.



Ташлыяр мәктәбе укытучылары. 2000 ел.



2000 елгы чыгарылыш.



2002 ел. Соңгы кыңгырау.



2005 ел. Чыгарылыш класс.



2005 нче елгы чыгарылыш укучылары. Бу вакытта мәктәп 9 еллыкка калган иде.



2018–2019 елгы уку елы. Укытучылар көнендә.



2019–2020 елгы уку елы. Укытучылар көнендә.



2019 елда – 4 класска өч бала. Соңгы уку елы. Ташлыяр мәктәбе ябыла.

Безнең авыл халкында белемгә тартылу һәрчак бик көчле булды. Төрле уку йортларында укып югары белем алучылар саны йөзләр белән санала. Шуңа күрә аларның барысын да санап чыгу күп урын алыр иде. Мәсәлән, безнең гаиләдән генә Шәймәрдәнов Шамилнең югары белем алган яки төрле вузларда укучы балалары һәм оныкларының саны 17гә җитә. Ташлыяр авылы мәктәбен тәмамлаучылар арасында укытучылар, агрономнар, инженерлар, юристлар, медицина хезмәткәрләре, хәрбиләр, музыкантлар, төзүче-инженерлар, архитекторлар, фән, партия-дәүләт эшлеклеләре бар. Бик күпләре төрле дәүләт бүләкләренә лаек булдылар. Шуларның берничәсен атап китәм.



Хөснуллин Котдүс, Шәймәрдәнов Равил. Ташлыяр студентлары сессия алдыннан.



Ташлыяр яшьләре – Казан вузлары студентлары. Басып торучылар (сулдан-уңга): Шәймәрдәнов Илдус, Камалов Мисбах, Шәймәрдәнов Әзһәм, Утырып торучылар (сулдан-уңга): Абдуллин Өлфәт, Вәлиева Альфира, Шәймәрдәнов Равил.

Укытучылар:

Галиева Нурдидә Гали кызы – РСФСРның атказанган укытучысы, озак еллар Мөслим урта мәктәбендә укытты.



Вәгыйзова Салиха Вәгыйз кызы Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде, Ташлыяр мәктәбендә укытты.

Фәтхуллин Мәхмүт, Закирова Фәрдәнә, Раскулова Равилә һ.б.

Вәгыйзова Салиха
Вәгыйз кызы



Артта басып торучылардан (сулдан уңга): дүртенче – Раскулова Равилә, Кәлимуллина Гөлфирә.
Утырып торучылардан (сулдан уңга): Лотфуллина Асия, ? Фәтхуллин Мәхмүт, Закирова Фәрдәнә, Вәгыйзова Сәлиха.



Артта (сулдан уңга): Зарипова Нурия, Зарипов Роберт, Фәтхуллин Мәхмүт, Гәрәев Рафис, Галиев Радост.
Утырып торучылардан (сулдан уңга): ? Раскулова Равилә, Лотфуллина Асия, Закирова Фәрдәнә, Вәгыйзова Сәлиха, Гәрәева Һидая.

Юристлар:

Шәйхетдинов Тәлгать Шәйхетдин улы, 1918 елда туган. Ташлыяр мәктәбендә укытучы, мөдир булып эшли. Юридик институт тәмамлый. 1947 елдан башлап, 30 елдан артык, Әлмәт районы һәм шәһәре прокуроры булып эшли.



Хәмидуллин Рәшит.

Хәмидуллин Рәшит Гайнемөхәммәт улы, 1962 елда туган, Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлаган. 1981–1982 елларда Әфган сугышында катнашкан. 1993 елдан бүгенгәчә прокуратура органнарында эшли. «Сугышчан казанышлары өчен», «Рәхмәтле әфган халкыннан», «СССР Кораллы Көчләренең 70 еллыгы», «Россия Федерациясе Прокуратурасына – 290 ел» медальләре белән бүләкләнгән. Татарстан Республикасының атказанган юристы.

Музыка өлкәсендә:

Хөснуллин Котдус Мирзасалих улы, 1941 елда туган, Казан музыка училищесын һәм Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган. Композитор, күп җырлар авторы. Республикада татар музыкаль фольклоры өлкәсендә иң танылган белгечләрнең берсе. Аның зур күләмле «Мөнәҗәтләр» китабы 2001 елда Тукай бүләгенә тәкъдим ителде. Ул – Мәдәният министрлыгы каршындагы фольклор үзәген оештыручы һәм аның беренче җитәкчесе, ТАССР Композиторлар берлеге әгъзасы, ТАССРның атказанган сәнгать хезмәткәре.




Хөснуллин Котдус.



Илнар Гомәров та – Ташлыярның талантлы берсе. Илнар 2000–2008 елларда Мөслим музыка мәктәбендә шөгыльләнә. Урта мәктәпне тәмамлагач, 2008–2012 елларда Фәрит Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллиятендә, баян классында укый. 2012–2016 елларда Казан дәүләт мәдәният институтында баян буенча осталыгын чарлый. Шушы вакытта ук диярлек – 2013–2017 елларда вокал буенча да белем ала. 2017 елдан Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшли.

Гомәров Илнар.




Сәрвәров Рөстәм Мөхәммәтдин улы – Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор, продюсер, автор-башкаручы. Рөстәм Сәрвәров 1960 елда туа. Ильяс Әүһәдиев исемендәге Казан музыка училищесын тәмамлый. 1989 елда «АКСУ» продюсерлык үзәген оештыра һәм бүгенге көнгә кадәр җитәкләп бара. Татар сәнгатен үстерү һәм пропагандалауда күп хезмәт куя. Үз иҗатында яшь буынны тәрбияләү мәсьәләләренә дә зур игътибар бирә: балалар өчен җырлар, биюләр, шигырьләр, әкиятләр җыентыклары чыгара, совет һәм чит ил мультфильмнарын татар теленә тәрҗемә итә.

Рөстәм Сәрвәров 100дән артык җырлар авторы, алар арасында туган авылына багышланган «Ташлыярым» (Флүс Латыйфи сүзләре), «Язмышым – Ташлыярым» (Элиза Гариф сүзләре) җырлары да бар.



Сулдан уңга – артта басып торучылар: Рөстәм, Әгъләм, Гөлнур (килен), Гөлнара (кызлары), Марсель, Альберт, Илһам, Кифая, Илнур.
Утырып торучылар: Рәйсә, Мөхәммәтдин (1979 елгы фото).

СӘРВӘРОВЛАР ШӘҖӘРӘСЕ





Якупова (Вәлиева) Сиринә Алмаз кызы 1971 елның 25 мартында Мөслим районының Ташлыяр авылында туа. Казан театр училищесын тәмамлый. «Әлли-бәлли-бәү» телетапшыруларында дистә ел курчакларны җанландыра. Казан Дәүләт «Әкият» курчак театры артисты булып эшли. Татар Дәүләт Гуманитар институтыннан кызыл дипломлы татар һәм гарәп телләре белгече булып чыга. Казан шәһәренең Яңа Савин районындагы Балалар иҗат үзәгенә гарәп һәм сәхнә телләре мөгаллимәсе булып эшкә урнаша. Соңрак театр берләшмәсе оештыра. Яңа Савин районы күләмендә татар телендә уздырылган күпчелек бәйгеләрнең оештыручысы, алып баручысы, әлеге бәйгеләрнең сәхнәләштерүчесе дә ул. Бер үк вакытта берничә ел «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясендә режиссёр ярдәмчесе буларак хезмәт итә. 2015 елда «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясендә дөнья күргән «Сиңа кайтам» телевизион фильмының сәхнәләштермәсен иң зур иҗат җимеше дип исәпли.

Медицина өлкәсендә:


Шәймәрдәнов Равил Шамил улы, 1940 елда туган. Россиянең һәм Татарстанның атказанган табибы, медицина фәннәре кандидаты, профессор, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты, Мөслим районының шәрәфле гражданы. Озак еллар Казан дәүләт медицина академиясенең хирургия кафедрасы мөдире, Казан шәһәренең баш хирургы булып эшләде. Дәүләтнең медицина өлкәсендә иң югары бүләге – «За заслуги перед Отечественным здравоохранением» алтын медале белән бүләкләнде.

Шәймәрдәнов Әнәс Шамил улы, врач-хирург, 1949 елда туган, Казанда яши.



Сулдан уңга: Әзһәм, Рөстәм, Равил, Әнәс, Фәния, Фәнүзә, Фәйрүзә.

Шәймәрдәновлар шәҗәрәсе



Равил Шәймәрдәнов төзеде

Фән өлкәсендә:



Мәгалимов Абрик Фазлыйәхмәт улы хатыны Эра Камил кызы белән.

Мәгалимов Абрик Фазлыйәхмәт улы (Атлас), 1939 елда туган, техник фәннәр кандидаты, СССР һәм ТРның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премияләре лауреаты. Озак еллар «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең бүлек мөдире булып эшләде.

Габдрахманов Әзһәр Габдрахман улы (Атлас) – геология фәннәре кандидаты.

Бакиров Данияр Ләбиб улы, техник фәннәр докторы. 2001 елдан «Когалым НИПИнефть» институтында эшли. 2009 елның гыйнварыннан – скважиналар төзү өлкәсендә филиал директорының фәнни эшләр буенча урынбасары. 2017 елдан – «Скважиналар төзүне проектлаштыру» тармагы үзәге җитәкчесе. Уфа нефть институтын тәмамлаган. Аның җитәкчелегендә скважиналарны цементлау технологиясе эшләнгән һәм кулланышка кертелгән. Ул – ике монография, 14 патент, 90нан артык гыйльми хезмәт авторы һәм автордашы. РФ Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән



Бакиров Данияр Ләбиб улы – техник фәннәр докторы.

Спорт өлкәсендә:



Шәймәрдәнов Илдар Равил улы, 1963 елда туган. Халыкара класслы спорт мастеры. Рапирада фехтование буенча 10 мәртәбәдән артык СССР һәм РСФСР чемпионы. Дөнья чемпионатында бронза медаль яулады. Россиянең атказанган тренеры. Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре. Казан шәһәренең фехтование буенча яшьләр спорт мәктәбе директоры. Хатын-кызлар рапирасы буенча Россия җыелма командасының баш тренеры. «Дәүләт алдындагы хезмәтләре өчен» (За заслуги перед Отечеством) II дәрәҗә орден белән бүләкләнгән.

Партия һәм хуҗалык эшләре өлкәсендә:

Мусин Госман Габделхак улы, 1929 елда туган, укытучы, мәктәп директоры, Мөслим район партия комитетының оештыру бүлеге мөдире.

Камалов Рафаэль Зиннур улы, 1952 елда туган, агроном, районның Калинин исемендәге колхозында (Метрәй) партком секретаре, «Татарстан» (Югары Табын), «Урал» (Баек), «Яңа Карамалы» колхозларында рәис, «Трудовик» совхозында директор булып эшләде. Татарстан Югары Советы депутаты булды.



Шәймәрдәнов Әзһәм Шамил улы.

Шәймәрдәнов Әзһәм Шамил улы, 1936 елда туган. Озак еллар «Маяк» колхозы председателе, юл төзү буенча күчмә колоннаны (ДПМК) җитәкләде. Берничә чакырылыш район Советы һәм Мөслим авыл Советы депутаты, шулай ук Мөслим авыл Советы рәисе.

Шәймәрдәнова Фәнүзә Шамил кызы, 1946 елда туган. Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Озак еллар Чаллы шәһәрендә урта мәктәп директоры булып эшләде.

Шәймәрдәнов Илдус Гафур улы, 1940 елда туган, Татарстанның атказанган агрономы. «Ташлыяр» совхозының директоры булып эшләде.

Камалов Мисбах Минһаҗетдин улы, 1947 елда туган. Татарстанның атказанган экономисты, «Трудовик» совхозының баш бухгалтеры, Дәүләт үзәк банкының Мөслим бүлеге идарәчесе булып эшләде.

Хөснуллин Рим Мирзасалих улы, 1947 елда туган, Россиянең һәм Татарстан Республикасының атказанган агрономы. Озак еллар «Татовощпром» концерны генераль директорының беренче урынбасары булып эшләде. Татарстан Республикасы Президентының, РФ һәм ТР авыл хуҗалыгы министрлыкларының, Казан шәһәренең мактау грамоталары белән бүләкләнгән.



Хөснуллин Рим Мирзасалих улы.



Вәлиева Әнисә Салихҗан кызы

Авзалов Ринат Сәхәбетдин улы, 1940 елда туган, «Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре». Озак еллар «Трудовик» совхозының Ташлыяр бүлекчәсен җитәкләде. Ташлыяр авылының экономикасын һәм көнкүрешен үстерүгә күп хезмәт куйды.

Вәлиева Әнисә Салихҗан кызы, 1941 елда туган. «Татарстанның атказанган терлекчесе».

Ташлыяр авылының шәрәфле гражданнары:

Шәймөхәммәтов Нурмөхәммәт Шәймөхәммәт улы (авылда партячейка оештыручы) – 1967 елның 10 августында бирелде.

Сәләхетдинов Зиятдин Сәләхетдин улы (авылда партячейка оештыручы) – 1967 елның, 10 августында бирелде.

Мөхетдинов Сәет Фәхригалләм улы (авылда беренче колхоз оештыручы) – 1967 елның 10 августында бирелде.

Минһаҗева Хөршидә – сыер савучы, 4000 килограмм сөт сава, 1973 елда бирелде.

Шәймәрдәнов Шамил Шәймәрдән улы – алдынгы, үрнәк шофер. 1973 елның 22 декабрендә бирелде.

Закирова Фәрдәнә Закир кызы – 35 ел рус теле укытучысы, актив җәмәгать эшлеклесе. 1976 елның 24 августында бирелде.

Фәтхуллин Мәхмүт Гомәр улы – 42 ел укытучы, актив җәмәгать эшлеклесе. 1978 елның 29 июлендә бирелде.

Халыкка медицина хезмәте күрсәтү

Революциягә хәтле татар авылларында, шул исәптән, Ташлыярда да дәвалау учреждениеләре булмый. Медицина хезмәтен имчеләр башкарган. Алар бала табуда булышканнар, сынган, тайган сөякләрне утыртканнар һәм башка ярдәмнәр күрсәткәннәр. Әле мин хәтерлим: сугыш елларында безне – малайларны, башка тимрәү чыкса (тире чире), абыстай янына алып бардылар. Ул бу чирне «Зәңгәр таш» (бакыр купоросы) белән дәвалый иде. Безнең якларда халыкка медицина хезмәтен 1890 елда ачылган Карамалы земство больницасы күрсәтә. Минзәлә өязендә барлыгы 8 больница (Минзәлә, Зәй, Чаллы, Карамалы, Пучы, Останково, Афанасово, Такталачык) һәм 11 врач участогы ачыла. Карамалы больницасы ачылганда, нибары 10 урын, 1910 елда 16 койка була. Анда доктор А.А.Черемшанский, акушерка Тимошина, фельдшерлар Сармалов һәм Абельманов, чәчәк салучылар (оспопрививатель) булып Вәлиәхмәтов һәм Асадуллиннар эшли.

Патша Россиясендә медицина хезмәткәрләренең эше югары бәяләнә һәм зур хезмәт хакы түләнә. Врач елына – 1800 сум, акушерка – 660 сум, фельдшерлар – 300 сумнан 500 сумга кадәр, ә аптека провизорыныкы – 1350 сум тәшкил

иткән. Хәтта провизор ярдәмчесе земский укытучыга караганда күбрәк хезмәт хакы алган. Чөнки аларның эше, бигрәк тә эпидемияләр вакытында тыгыз һәм үз сәламәтлекләре өчен дә куркыныч була.

Земство больницаларында дәвалау түләүле була. Түләү хакы авыруның экономик хәленә карап билгеләнә. Эшләүче кешеләрдән тәүлеккә – 25 тиен, чит өяз кешеләреннән 50 тиен хак алына. Ярлы яки гарип кешеләргә түләү хакы азрак була, кайбер очракларда бөтенләй дә акча алынмый.

Карамалы больницасы революциядән соң да эшли. Совет заманында ул Сарман районының участок больницасы булды.

Ташлыярда бүгенге медицина пункты 1938 елда ачыла һәм аның беренче җитәкчесе Шәрәфетдинова Нажия була. Ул 1941 елга кадәр эшли. 1941–1946 елларда анда эшләрлек медицина белемле кеше булмый. Кулыннан килгән хәтле медицина ярдәмен Могыйнова Нәкыя апа күрсәтә.

Сугыштан соңгы елларда авылда медицина ярдәмен түбәндәге хезмәткәрләр күрсәтә:

Монасыйпова Мәдинә – 1946–1953
Фәйзрахманов Л.Ф. – 1953–1958
Шәймәрдәнов Р.Ш. – 1958–1960
Сөләйманова Тәгъзимә – 1960–1977
Фәррахова Люция – 1977–1978
Хаҗиева Илгизә – 1978
Насыйрова Энҗе – 1979
Шәйхетдинова Илсөя – 1979
Камалов Фалих – 1980
Хәмидуллина Энҗе – 1980
Шәйхелова Рәмзия – 1980–1982
Нигъмәтуллина Хәния – 1982
Җәләева Рәмзия – 1982–1986
Камалова Тәслия – 1986–2008
Насыйрова Рәмзия – 2008 –



Хәмидуллина Энҗе.

Сугышка кадәр Ташлыяр авылы тарихында, беренчеләрдән махсус уку йорты тәмамлап, шәфкать туташы дипломы алып, түбәндәге кешеләр Мөслим районына эшкә кайта:

Вилданова Гайшә Имаметдин кызы – 1918 елда туган, 1938 елда Алабуга медицина училищесын тәмамлый, район больницасында эшләде.

Гайсина Нурлыһода Гайсә кызы – 1919 елда туган, 1938 елда Минзәлә медицина училищесын тәмамлый, 1939–1942 елларда Саба, аннан соң безнең район больницасында эшли.



Шәйхелова Рәмзия.

Ихсанова Хәдичә Фәхрислам кызы – 1919 елда туган,



Фәррахова Люция.

1938 елда Минзәлә медицина училищесын тәмамлый. Район больницасында эшли. Мөслимнән Ташлыярга җәяү кайтканда, буранда адашып, туңып үлә.

Шәйдуллина (Батырханова) Мөгаллимә – Ташлыярда туган. 1939 елда Минзәлә медицина училищесын тәмамлый, Туйгелде авылында эшләде.

Сугыштан соңгы елларда һәм соңрак та Ташлыяр авылы халкына медицина ярдәме күрсәтүдә Михайловка участок больницасы зур роль уйнады. Башта ул агачтан корылган балалар бакчасы бинасында ачылып, 1970–1971 елларда таштан салынган бинада эшләде. Мин бу больницада 1957–1958 елларда фельдшер вазыйфасын башкардым. Бу больницада эшләгән врачлардан Л.В.Кондратьева, Ә.С.Галләмов, Р.Гыйләҗева, М.М.Хәйбрахмановлар халыкның зур хөрмәтен казанды. Кызганычка каршы, үзгәртеп кору заманнары килеп җиткәч, барлык урыннардагы шикелле, Михайловка участок больницасы да ябылды. Мин моны зур ялгышлык дип саныйм. Гомумән, тотрыклы эшләп килгән авыл сәламәтлек саклау системасы җимерелде.

Мәчетләр һәм дин әһелләре

Октябрь революциясенә кадәр Ташлыярда Мәлләтамак авылыннан килгән Биккинин фамилияле карт хәзрәт муллалык иткән һәм мәдрәсә тоткан. Бу мәдрәсәдә хәллерәк кешеләрнең ир балалары укый. Укыган өчен һәр җомга сәдака бирелә торган була. Биредә уку дини кагыйдәләрне гарәп телендә ятлаудан гыйбарәт булган. 1906 елда хәзрәт Биккинин үлгәч, аның улы Хафизетдин, Олы Чакмак авылындагы муллалыгын калдырып кайтып, Ташлыяр авылының икенче (урта) мәхәлләсенә муллалык итә, балаларны укыту да аның карамагына күчә. Ул мәдрәсәне зурайтуга, ашханә булдыруга ирешә һәм укыту эшен берничә класска бүлә. Укыту искечә (кадимчә) алып барыла. 1906–1912 елларда шушы мәдрәсәдә укыган Фәтхуллин Әбүбәкер һәм Фәтхуллин Гомәрләр дә балаларга дәрес бирә. Гомумән, ул заманнарда өлкән сыйныф шәкертләренең түбән сыйныф шәкертләрен укытуы гадәти хәл булган.

1909 елны Хафизетдин хәзрәт хаҗга киткәндә, Зәй-Каратай авылыннан (хәзерге Лениногорск районы) Фазыл Туйкинны мөгаллим итеп чакыртып ала.

ИСКӘРМӘ: Фазыл Кәрим улы Туйкин 1887 елда Зәй-Каратай авылында мөәзин гаиләсендә туа. 77 яшьлек әтисе дөнья куйганда, аңа нибары 7 яшь була. Ул башта авыл мәдрәсәсендә, аннан соң Уфада – «Хакимия» мәдрәсәсендә, соңрак Казанга күчеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып урта сыйныфны тәмамлагач, Зәй-Каратайга кайтып, 1909 елга кадәр мөгаллимлек итә, 1909-1911 елларда Ташлыярның урта мәчетендә өлкән мөгаллим була. Фазыл Туйкин

мәктәптә җәдитчә укыту кертә башлый, шәкертләр Тукай, М.Гафури әсәрләрен өйрәнәләр, хәтта спектакльләр дә куялар.

Хафизетдин хәзрәт хаҗдан кайткач, аңа бу хәлләрне җиткерәләр. Волостьтан старшина, урядник, пристав чакырыла. Мәдрәсәдә, мөгаллимнәрнең өйләрендә тентү ясала, рөхсәт ителмәгән китаплар, география карталарын эзлиләр. Фазыл Туйкинны яңалык ягында торганы, яңача укытырга омтылганы өчен авылдан куалар. Ул Ташлыярдан киткәч тә мөгаллимлек эшен дәвам итә, фольклор җыйный, танылган мәгърифәтче булып җитешә, Һади Атласи белән хезмәттәшлек итә. Ул, Атласига теләктәшлек итүдә гаепләнеп, 1938 елның 15 февралендә Казан төрмәсендә Һади хәзрәт белән бергә атып үтерелә.



Фәтхуллин Әбүбүкер 1887 елда туган. Мулла. 1913 елда Казанда Алафузов сабын заводында эшләгән.

Авылда хатын-кызларны Газизә, Җәмилә абыстайлар һәм башка хәзрәтләрнең остабикәләре укыткан. Ләкин укыту дини догалар ятлаудан гына гыйбарәт булган. Кызларны язарга өйрәтмәгәннәр. Мәдрәсә нигездә дин белемен генә биргән. Гарәп теле һәм шул телдә дини китаплар уку иң әһәмиятле белем алу саналган. Фарсыча да укытканнар. Ләкин гарәп һәм фарсы телләрен камил белүче булмаган. Дин дәресләреннән башка шәкертләр акыл фәннәре (гакылият) өйрәнгәннәр. Мәсәлән, мантыйк (формаль логика), дин нигезләре (кәләм) һәм аның хокукый ягы (шәрыгият) белән танышканнар. Арифметикадан дүрт гамәл, геометрия буенча кайбер мәгълүматлар мирас бүленеше (фәраиз) турындагы мәсьәләләрне өйрәнгәндә үтелгән. Хәзрәт мәдрәсәсендә татарча уку китабы (әрбәгыйннәви), арифметик мәсьәләләр җыентыгы, гарәп теле морфологиясе (гарәп сарфы), педагогика-методика дәреслеге (тәлагими тәгаллем), дөньяның физик географиясе дәреслеге кебек, 1902–1907 елларда Казанда басылган китаплардан укыганнар.



Фәтхуллина Маһәвәрә (абыстай).

Авылыбыз укымышлыларыннан берсе – Зиннур абый Халиков, шул чорда укыган кеше буларак, мәдрәсәдә уку-укыту тәртибен Мәхмүт абый Фәтхуллингa сөйләп һәм язып калдырган. Күргәнебезчә, авыл мәдрәсәсендә укыту дини догалар өйрәнү белән генә чикләнмәгән икән.

1913 елда авылның иң бай кешеләренең берсе Бикиев Әхмәтлатыйп Боровецкий нарат урманыннан (Чаллы янында) нарат кайтартып, авыл уртасына ике катлы мәчет – «Зәңгәр мәчет» салдырган. Иске мәчетне сүтеп, түбән очка, хәзерге Шәйдуллин Вәзир ихатасы урынына, ремонтлап (сипләп) салганнар. Түбән оч мәчетендә Сәлах мулла, Зариф мулла, 1921–1924 елларда Гомәр муллалар (Фәтхуллин) имамлык иткән.

Югары оч мәхәлләсенең мәчетен («Күк мәчет») Аблаков Гарифулла салдыра. Ул мәчет хәзерге Абдуллин Нәсим ихатасы урынында урнашкан була. Аның мулласы һәм мөгаллиме Аблаков Гарифулланың улы Бикмөхәммәт мулла 1920 елларда гаиләсе белән Урта Азиягә сөрелә. 1929 елның 19 маенда булган зур пожарда авылның мәктәбе яна һәм мәчетләрне мәктәп итү мәсьәләсе көн тәртибенә куела. Авылның янгын сараенда волость вәкилләре, активистлары һәм муллалары катнашында авыл җыелышы була. Ике көнгә сузылган бу җыелышта зур каршылыклар белән югары һәм түбән оч мәчетләрен мәктәпкә бирергә дигән карар чыгаралар. Шул ук елда югары оч мәчетендә укулар башлана. Түбән оч мәчетендә укый-яза белмәүчеләрне укырга өйрәтергә керешәләр. Шул ук елны югары оч мәчетен төнлә ут төртеп яндыралар. Шуннан соң урта «Зәңгәр мәчет»не мәктәп итәргә карар кабул ителә. Түбән оч мәчете сөргенгә сөрелгән Биккинин хәзрәт хатыны Мәчтүрә абыстай ихатасына, урта мәчеткә якын гына урынга, икенче мәртәбә күчереп салына. Абыстай өе дә мәктәпкә бирелә. Мин әлеге мәктәптә укыган елларда (1947–1954) бу бинада укытучылар бүлмәсе һәм бер уку бүлмәсе урнашкан иде. Беренче классны мин шушы уку бүлмәсендә, Асия апа Лотфуллина классында тәмамладым. 1929 елда урта мәчетне мәктәп иткәч, аның манарасын кисәләр. Манараны кисүчеләр: Йосыпов Билал, Морзаханов Салихҗан, Шәрәфетдинов Сабиржан, Халитов Габдрахман, Галиев Миңнемөхәммәт. Манараның тимердән чүкеп ясалган аен Фәтхетдинов Шәмсетдин бабай гомере буе яшереп саклый. Үзе үлгәч, айны каберенә куялар, хәзер дә ай шунда тора.

1983–1984 елларда мәчет-мәктәпне сүтеп, аның урынына кирпечтән ике катлы мәктәп бинасы салдылар. 1990 елларда илдә яңа үзгәрешләр кузгалгач, күп кенә авылларда һәм шәһәрләрдә мәчетләр төзү башланды. Ташлыяр авылында да яңа мәчет салырга тотыналар. Бу эшне ул вакыттагы «Ташлыяр» совхозы директоры Илдус Шәймәрдәнов башлап җибәрде. «Ташлыяр» «Трудовик» совхозына кушылгач, мәчетне управляющий Ринат Авзалов төзетеп бетерде. Мәчетне ачу тантанасы бәйрәм төсендә узды. Якын-тирә шәһәрләрдән, шул исәптән Казаннан да бик күп авылдашлар кайткан иде.

1929–1930 елларда мәчетләрне бетерү белән генә халык дин тотудан туктамый, догаларын, дини йолаларын шәхси йортларда үтиләр, җомга намазларын укыйлар. Ул елларда муллалык вазыйфасын түбәндәге кешеләр башкарды:

Кәримов Муса (1930–1952) 1904 елгы рус-япон сугышында катнашкан.

Фәтхуллин Әбүбәкер (1952–1959) үз теләге белән муллалыгын ташлап, агроном булып эшли.

Гайсин Габделихсан (1959–1963).

Сөләйманов Галимәрдән (1963–1978).

Хәмидуллин Мөхтәр (1978–1985).

Вәлиев Камалетдин (1985–1993).

Гыймазетдинов Муллашәех (1999 елдан).



1929 елда манарасы кисеп төшерелгән мәчетнең тимердән чүкеп ясалган ае.

Авылым урамнары турында

Хәзерге вакытта Ташлыяр авылы, Атласка бара торган юл буенда урнашкан 3 йорттан торган урамны исәпләмәгәндә, өч чакрымга сузылган бер генә урамнан тора. Урамның киң, тигез һәм озын булуыннан файдаланып, революциягә кадәр заманнарда, күрше-тирә авыллардан да килеп, ат юрттыра торган булганнар. Революциягә кадәр дә, аннан соңрак та авылыбыз берничә урамнан торган:

Сары бармак урамы – колхоз һәм совхоз заманнарында терлекчеләр йорты, автоүлчәгеч урнашкан калкулыкта олы урамга аркылы, 15–20 йорттан торган урам була. 1929 елдан соң бетерелә. Бу урамда яшәүче хатын-кызлар тырнакларын сарыга (кына гөле сыекчасына) буяп йөрткәннәр. Шуның өчен аларны Сары бармак урамы дип атаганнар.

Ындыр арты урамы – хәзерге Шәйдуллин Лиф тыкрыгыннан алып, олы урамга аркылы урнашкан 20–30 хуҗалыктан торган урам. Бу урамда Заһидулла солдат, Хәмидуллин Шәймәт, Сафина Хәдичә, Нурислам, Шакиржан һ.б. яшәделәр. 1965–1970 елларда бетерелә.

Тау асты урамы – хәзерге Шәйхетдинова Мәрзияләр турыннан Шәйдуллин Нуруллаларга кадәр бакча башында урнашкан. Гаделшин Әюп, Мөхәммәди, Сөләйман һ.б. кешеләр яшәгән тыкрыклар 1929 елда бетерелә.

Ас урам – хәзерге Шәрифуллин Мөхәммәтдиннәр турыннан Каһарманов Хөснимәрдәннәр турына кадәр бәрәңге бакчалары башында (яр буенда) урнашкан урам. 1929 елда бетерелә.

Колхоз урамы – 1930 елдан соң төзелә, авылның зур урамына параллель бер рәтле урам. Бу урамда Вәлиев Минһаж, Сафиулла, Шәрәфетдинов Нурулла, Галиев Фазлый, Фәтхуллин Әбүбәкер, Гаделшин Әюпләр яши. Бу урамны башта Комгансызлар, соңрак Тукай урамы дип йөртәләр. 1970–1978 елларда тарала.

Елга-күлләребез, чишмәләребез

МӘЛЛӘ ЕЛГАСЫ – Азнакай районының Мәлбагыш авылы җирләрендә чишмә булып башланып, Мәлләтамак авылына кадәр ага торган 60-70 чакрым озынлыгындагы борынгы елга. Ык елгасының сул як кушылдыгы.

КӘҮҖИЯК СУЫ – Сарман районы, Кәүҗияк авылыннан башланып, Ташлыяр авылы янында Мәллә елгасына кушыла торган 10 чакрымнар озынлыгындагы инеш (кизләү).

БӘЧКӘЙ – авылның түбән очында, Мәллә елгасының уң як ярында Михайловка һәм Туйгелде авыллары арасындагы җирләр. 1930 елга кадәр бу болыннар Ташлыярныкы була. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк: Тегермән буасының уң ярындагы (Михайловка ягындагы) әрәмәлек һәм иске Мәллә урынына (старица) кадәр болыннар да Ташлыярныкы була.

«Трудовик» совхозында М. Баһауов директор булып эшләгән елларда, Мәллә елгасының агымын үзгәртеп, югары очтагы бу болыннар Ташлыярга кире кайтарылды. Бу эшнең инициаторлары Хөснуллин Рим, Закиров Риф булдылар.

БӘЧКӘЙ КҮЛЕ – Бәчкәйдә Иске Мәллә (старица) елгасы урынында сазлыклы-баткак җирдә барлыкка килгән кечкенә күл.

ТОРФЛЫК КҮЛЕ – Мәллә елгасының уң як ярында торф катламнары бар. Ягу өчен кисеп, ашлама өчен казып, озак еллар буе аны казудан барлыкка килгән чокырлар. Яз көне ташу суы белән тулып күлгә әйләнә. Бу күл җәй көне саега иде, хәзер инде бөтенләй кипкән.

ЮГАРЫ ОЧ КҮЛЕ – 1937–1938 елларда Мәллә елгасын буып тегермән коргач, су арту аркасында авылның югары очында барлыкка килгән күл. Хәзерге вакытта буа булмаса да, күл сакланган. Күлне берничә вак чишмә «туендырып» тора.

БУА БАШЫ КҮЛЕ – 1910 елларда (Столыпин реформасы чорында) Буралы авылы бае Әхтәмов Нурмөхәммәт хаҗи Михайловка авылы турында буа буып, 4 ташлы тегермән төзегәч, югары оч басуында, тегермән буасы артында чокырлар һәм күл хасил була. Бу күл бүген дә бар. Бу урыннарны халык хәзер дә Буа башы дип йөртә.

ЯШЕЛЧӘ ЧИШМӘСЕ – Кәүҗияк суының сул як ярында кыйблага юнәлеп чыга торган мул сулы чишмә. Сугыштан соңгы елларда чишмә янында колхозның алма һәм яшелчә бакчалары оештырыла. Чишмәне буып, арыклар ясап, яшелчә түтәлләрен арыклар аша сугаралар иде. Шуның өчен бу чишмә Яшелчә чишмәсе дип атала. Хәзерге вакытта Ташлыярга һәм район үзәге Мөслимгә юан торбалар аша шушы чишмәдән су китерелде.

ГОСМАН ЧИШМӘСЕ – Кәүҗияк суының сул як ярында, яшелчә чишмәсеннән югарырак урында чыга торган мул сулы чишмә.

АТЛАС ЧИШМӘСЕ – Атлас авылының югары очында чыга торган чишмә. Революциягә кадәр бу җирләрнең хуҗасы бояр Пальчиковның управляющие Павел чишмәне буып, буа янында үзенең биләмәсен кора. Чишмә буасы хәзер дә исән, яңартылган.

НИГЪМӘЛ ЧИШМӘСЕ – Атлас авылының түбән ягында, ике урман арасында чыга торган чишмә. Хәзерге вакытта бу чишмә заманча тәртипкә китерелгән, ял итү урыннары ясалган.

КАРАН ЧИШМӘСЕ – Атлас урманыннан (Ташлыяр ягында) чыга торган шактый мул сулы чишмә. Каран инеше булып, Мәллә елгасына агып тоташа.

Ташлыярның төрле урын-җирләренә бирелгән атамалар

ЧАГЫЛ ТАВЫ – авылның иң биек урыны, югары оч басуында имән урманы янында урнашкан тау. Чагыл сүзе кыйблага карап торучы мәгънәсен аңлата. Әмирхан Еники үзенең «Башкорт курае» исемле хикәясендә бу атамага шундыйрак аңлатма бирә.

УРЫС ТАВЫ – Мәллә елгасының Михайловка ягындагы ярыннан өстәрәк урнашкан тау. Аның итәгеннән Ташлыярга бара торган асфальт юл үтә. Элек бу тау биек иде. Без, Ташлыяр малайлары, кыш көне бу тауга чаңгы шуарга йөри идек. Борынгырак заманнарда ак балчык казып алганнар. Тау ишелеп үлү очраклары да булган (Аблаков Ширияздан).

БИКТИМЕР АЛАНЫ – имәнлекнең югары оч башында ике урман арасындагы урын.

БАЙЛАР БАСУЫ – югары оч (Аблак) басуы.

ДОНБАСС БАСУЫ – Атласның Югары Табын ягында урнашкан басулары.

ҮТӘШ ЧОКЫРЫ – югары оч басуында урманнан Кәүҗияк елгасына кадәр сузылган зур чокыр. Элек бу чокырның урман башында кое бар иде – Үтәш коесы. Игенчеләр, чалгычылар, урманга җиләккә барган кешеләр, бу кое янында туктап, су ала торганнар иде.

КӘРӘКӘ-КУЛ ЧОКЫРЫ – түбән оч басуында урманнан Кәүҗияк суына кадәр (яшелчә бакчасыннан түбәнрәк) сузылган авыл басуларындагы иң зур чокыр. Бу чокырның исеме каян алып бирелгәндер – билгесез. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «кәрәкә» – балык исеме (табан балык дип күрсәтелгән. Бүтән мәгънәсе юк.) Кул сүзе бу урында икенче мәгънәсендә, тар үзәнлек мәгънәсендә килә, күрәсең, әүвәл Кәрәкә-кул дип кенә йөртелгән, аннан, заман-дашларга аңлашылсын өчен, чокыр сүзе дә өстәлгән.

КАРА ТАЛ ЧОКЫРЫ.

МАРҖА ЧОКЫРЫ.

МУЛЛА ЧОКЫРЫ.

Авылның түбән оч басуларында урман буендагы ваграк чокыр исемнәре:

КЫРҮЗӘН – Каран суы буендагы урыннар, болыннар. Колхоз вакытында хуҗалыкның печәнлек болыннары.

ЧӨГЕРМӘК – Кәүҗияк елгасының уң як ярында зираттан алып Петровкага кадәр сузылган яр буендагы чокырлар.

ОЛЫ ТҮМГӘК (Югары әче дип тә йөрттеләр) – югары оч басуында сазлыклы, кыяклы үлән генә үсә торган урын. Анда икмәк чәчмәделәр.

ТҮБӘН ТҮМГӘК (Түбән әче) – Олы Түмгәктән түбәнрәк урнашкан шундый ук сазлыклы урын. Сугыштан соңгы елларда Түбән түмгәктә (Әчедә) кое бар иде.

ТОБА АСТЫ – Кәүҗияк елгасының уң як ярында зираттан урман полосасына кадәр урнашкан урыннар:

АЛЛА СЫЗАСЫ

ТАБЫН СЫЗАСЫ

КӘҮҖИЯК СЫЗАСЫ

«Сыза» сүзе татар телендә кипкән елга, озын чокыр мәгънәсен аңлата. Бу очракта – «юлы» дип аңларга кирәк: Алла юлы, Кәүҗияк юлы, Табын юлы.

БИККЕНӘ ТАРЛАВЫ – тарлау – урман яки болын уртасындагы аерым басу. Сүз Биккенә (Бикмөхәммәт) мулланың басуы турында бара. Хәзер бу басуның кайсы урында урнашкан икәнен белүче юк.

БҮЛЕМ КАЕН – Атлас басуы уртасында, Атлас белән Алга авыллары арасында урнашкан зур булмаган урман. Бу урман хөкүмәтнеке түгел, колхозныкы иде. Шуның өчен аннан колхоз үзенчә файдаланды.

ДӨМ КАЕН – Игенче урманындагы каенлык.

УРЫС ЧОҢГЫЛЫ – Кәүҗияк елгасының сул як ярында, Чагыл тавы итәгендәге, Петровка авылы белән янәшәдәге җирләр. Чоңгыл – Тирән түгәрәк чокыр, чокыр-чакырлы дигән мәгънәне аңлата.

КАРАН ТАМАГЫ – Каран чишмәсенең Мәллә елгасына кушылган урын.

КӘҮҖИЯК ТАМАГЫ – Кәүҗияк елгасының Мәллә елгасына кушылган урын.

ФӘТХУЛЛИН ГОМӘР ФАЗУЛЛА УЛЫ

Авыл тарихын өйрәнгәндә, бигрәк тә революциядән соңгы һәм колхоз оештыру чорларына караган төрле документларда Фәтхуллин Гомәр Фазулла улының исеме еш очрый һәм каршылыклы фикерләр уята. Ул революциягә кадәр мөгаллимлек һәм муллалык иткән, батрак тоткан. Революциядән соңгы елларда, бигрәк тә коллективлаштыру чорында байларның, муллаларның һәм хәллерәк крестьяннарның мөлкәтен конфискацияләүдә, үзләрен сөргенгә сөрүдә катнашкан иң актив кешеләрнең берсе була.

Гомәр Фәтхуллинның үз кулы белән гарәп шрифтында язылган, аның олы улы Мәхмүт абый Фәтхуллин тарафыннан урыс шрифтына (кириллицага) күчерелгән автобиографиясе авыл-мәктәп архивында саклана. Шунда ук Мәхмүт абый тарафыннан өстәп язылган, Г.Фәтхуллинның бу документ язылганнан соң булган тормыш юлы китерелә. Мин, аларны кыскартмыйча, тулаем китерүне кирәк таптым.

Тәрҗемәи хәле (автобиография)

Автономияле Татарстан Җөмһүриятенең Чаллы кантуны, Карамалы волосте, Ташлыяр авылы гражданы Гомәр Фазулла улы Фәтхуллинның тәрҗемәи хәле.

Мин, Гомәр Фазулла улы Фәтхуллин, 1895 елның 23 сентябрендә Ташлыяр авылында крәстиян семьясында туганмын. 5 яшемдә атамнан ятим калып, ятимлектә тәрбияләнә башладым.

1903 елда минем анам карчык Ташлыяр авыл мәктәбендә «Ите – сиңа, сөяге – миңа» дип, муллага илтеп бирә. 1909 елга кадәре шул мәктәптә булып, 1910 елда миңа берничә баланы укытырга кушып, үзем алган начар тәрбияне (дини тәрбия) өйрәтә-укыта башладым. 1911 елда да шул хезмәттә булсам да, ачлык ел булганлыктан, мулладан хезмәт хакы соравым аркасында, мәктәптән куылдым. 1912 елда Чакмак мәктәбендә укыттым. 1913 елга чыккач, тормыш халәте гадәттән тыш авыр булганга, берәр җиргә эшкә китәргә уйлап, Казанга барып берничә тәүлек эшсез, ач йөргәннән соң, Казанда Арслановларның сабын заводында ишегалды себерергә кабул ителдем. Айлык вазифа 6 сум иде. Көзлектә аннан кайтып, Нөркәй волосте, Кәүҗияк авылында җиде ай ярым вакыт укытуга 25 сум хезмәт хакы бәрабәренә укытучы булып киттем. (Айлык өч сум.)

1914 елның җәендә Иж заводында күмер эшендә булып, 1915 елда авылда калдым. Шул ук елда Шуганда авыл хуҗалыгы курсында 25 тиен көн хакы биргәнгә укып кайттым.

1915 елның август аеннан 1916 елның мартына кадәре Михайловка авылы Әхтәмов тегермәнендә йорт эше, мал карау, лапатка (тегермән тоткан өчен хак. – *Р.Ш.*) алу, икмәкләр үлчәү эшендә булдым. Әхтәмовтан эш бетеп чыкканнан соң, Иж заводында такта ташу эшендә эшләп, аннан Пермьнең Матавилиха заводына эшкә киттем. (Сүз атаклы «Матавилиха» заводы турында бара. Революциягә кадәр авылда кыр эшләре беткәч, Ижау-Ижевск, Воткинск, Пермь шәһәрләре заводларына барып эшләү (отхожий промысел – читкә китеп эшләү) безнең авыл кешеләре өчен гадәти хәл булган. – *Р.Ш.*). Бу заводта тимер йөртү, такта, кирпеч ташу, аннан соң пычкы яру эшендә эшләп, 1917 елның октябрь башында авылга

кайттым. Ул вакытта мин эш көнен 12 сәгатьтән 8 сәгатькә калдыру турында иптәшләргә катнашуым өчен берничә иптәш белән эшемнән чыгарылган идек. 1917 елда октябрьдә авылга кайтканнан соң авыл Советы (сельский комитет) секретаре булып эшли башладым. Шулай итеп җыелышларга баргалый башладым. Минзәләгә Советлар съездына бардым. 1918 елдан иске кооперациягә идарә члены итеп куелдым. Шул ук вакытта авыл секретарьлыгын да алып бардым. 1919 елга кадәрле шушы хезмәттә булып, 1919 елда авылда аң-белем түгәрәге төзеп, уку йорты ачып, шуның мөдире булып эшләдем. Шулай ук 1918 елның башыннан 1919 елның ахырына кадәр Ташлыяр авылы җир вәкиле булып бояр җирләрен алуда һәм җирне тигезләп бүлүдә эшләдем. 1919 елда кантун съездына барып, Карамалы волбашкармасы тикшерү кәмпәниясе әгъзасы булып эшләдем. 1920 елда Минзәләгә избачлар курсына барып, аннан кайткач, эшләгән вакытта сәнәк вакыйгасына туры килеп, сәнәкчеләр мине һәм бөтен китапханәне (600дән артык китаплар) туздырдылар. Мин берничә көн качып ятканнан соң, китаплар очканнар иде. Аннан соң 1921 елның җәенә кадәр уку йорты ачылмый торды. 1921 елның җәендә Ташлыяр авылыннан Атлас исемле поселка чыгаруда оештыру эше алып бардым. Шул ук елдан ачлыкның гадәттән тыш каты булуы мине указсыз мулла итәргә мәҗбүр итте. Шул елдан башлап 1924 елга кадәрле дини авыру белән авырып, аңсызлык һәм тормыш көчләве аркасында, шул юлда һәм Атлас поселкасы эшендә калдым. Көннәр үтү белән, гәзитәләр укый-укый миңа аң кереп, ул эшнең тиеш түгеллеген аңлап, диннең һәм руханиларның халыкны томалавын сизеп, 1924 елның 20 маенда ул эштән ваз кичтем. 1924 елның июлендә, Ташлыяр авылында потребкооперацияне оештыру уена тотынып, 18 августта убший собраниедә мине кооперация оештырырга сайлап куялар. Сентябрьнең 28ендә кооперация оештырып эш башлана. Шул ук елда миңа инструкторлар хисапчылык эшен өйрәткәч, хисапчы булып калам. Шул ук 1924 елдан башлап Минзәлә «Игенче» газетасының хәбәрчесе булып, муллалар һәм башка карагруһлар турында, шулай ук башка төрле хәбәрләр яза башлыйм. «Игенче»дә авыл хулиганнары һәм башка җитешсезлекләр хакында язгалап торганлыктан, берничә тапкыр һөҗүмнәр дә булгалады. Шул елларда авыл ярлыларына урман алу, гәзитәгә язылу кампанияләрен үткәрү, җир кәмиссияләрендә, судта утырышчы булып утыру, налог кәмиссияләрендә эшләү, авыл хуҗалыгын күтәрү юлларында волость вәкиле булып эшләүләр, киң җәмәгать эшләрен дә үткәрергә туры килде.

1925 елда бөтен нәрсә, бернәрсә калмый янып киттем. Янганнар өчен урман кайтару вәкиле булып эшләдем. 1926 елда мәктәп Советы әгъзасы булып сайланып, Ташлыяр мәктәбен эшләтеп бетердем. Ул елларда авыл яшьләре журналы чыга башлап, шулай ук крәстиян гәзитәсе дә чыга башлаганга, анда да языша башладым. Бу елда (1929) авыл Советы тикшерү кәмиссиясе рәисе, волость сайлау җыелышы вәкиле, волость съезды, мандат кәмиссиясе әгъзасы, халык суды заседателе, Горчаков урманын обществога эш йөртеп алу, шулай ук яшьләрнең оештыру эшендә, алар арасында активлык кузгату эшендә эшләдем. Шушы хезмәтемдә 1927 елга кадәрле эшләдем. 1928 елда радио сөючеләр түгәрәге оештырып, шулай ук пожар ирекле дружинасы оештырып, аның тикшерү

кәмиссиясендә булсам, 1929 елда балтачылар отряды начальнигы булып сайландым. 1928–1929 елда стена газетасы чыгарышуга катнашып эшләдем. Кооперация эшендә 1919 елдан катнаша башлап, 1927 елдан бу көнгә кадәрле, 1929 елның шушы көненә – 20 сентябрьгә кадәрле хисапчылык эшен үтәп киләм. Шушы вакыт эчендә хисапчылык эше буенча бер мәртәбә курста һәм 3 тапкыр кыска сруклы инструкторский совещаниеләрдә булдым.

Имзам: имза (Гомәр Фәтхуллин)

1929 ел, 20 сентябрь.

ӨСТӘМӘ:

1928 һәм 1929 елларда Ташлыяр авылындагы ясле кәмиссиясе рәисе булып эшләп килдем. Пожар дружинасында, авыл хуҗалыгы секциясендә, уку йорты шурасы әгъзасы һәм Ташлыяр кооперациясенең аң-белем кәмиссиясендә, мәктәп советында һәм башка кәмиссияләрдә катнашып эшләп киләм. Шуның белән бергә хисапчылык эшен алып барып кооперациядә, райондагы авылларга докладлар белән дә чыккаларга туры килде.

1930 елның 7 февралендә, Ташлыяр потреб җәмгыяте Карамалыга кушылу сәбәпле, «Марс» колхозы идарәсенә бер аваздан идарә әгъзасы һәм хисапчы итеп сайланып куелдым. 1929 елның көзеннән башлап кыш буе колхоз оештыру эшендә эшләп, нәтиҗәдә 40 хуҗалыктан гыйбарәт колхоз оештырылды.

Бөгелешләр һәм Сталин мәкаләсе вакытында, колхозлар таралган вакытында, ник тырышлык белән, 40 хуҗалык – иң фәкыйрь һәм баерак ларны саклап кала алдык. (Әлбәттә, иптәшләр белән берлектә). Ул вакытта шундый авыр моментлар үткәрергә туры килде. Фәтхуллинны үтерсәк, бәлки, тынычларбыз. Аны асарга кирәк, ГПУга бирергә һәм башкаларны эшләргә кирәк, дип янаулар булды. Ләкин аңа карамастан (хәзер дә әле кулак һәм аларның коерыклары ул фикердән кайтканнары юк), ут, сәнәк, кычкырыш, талаш, үлем белән куркыту эчендә эшләргә туры килде. 1919 һәм 1920 елда ике бертуганым Красный әрмиягә добровольно китүләре сәбәпле (үзем гарип булу сәбәпле солдатка ярамадым). Миңа аклар тарафыннан тентүләр ясалса да, сәнәк вакыйгасында качып котылуым булса да, хәзерге вакытта колхоз эшендә ирекле Советларның ирекле эшендә эшләсәм дә, үлем белән куркытудан котылганым юк. Хөкем аркылы минем мулла булуым белән гаепләргә тырышулар, һәр атна диярлек редакцияләргә һәм РКИ һәм прокурорга жалобалар тезеләләр. Мин әллә ни зур укыган кеше түгел, бары 4–5 сыйныфлы авыл мәктәбен генә бетереп чыктым. Советлар хөкүмәте матбугаты һәм Советлар тәрбиясе белән ник тәрбияләндем һәм үземнең үзлегемнән тырышып өйрәнүем (самоучка) белән генә йөрим. Элек тә татарның бер надан хәлфәсе булып эшләп маташтым. 1924 елдан бирле үзем динсез яшим. Муллалыгын ташламаган динле муллалар белән бер төрле дә күрешү дә, ни дә сизелми. Элек моннан 6–7 ел элек мулла булып торып та, хәзерге көндә динсез бер кеше белән көрәш бара.

9 май, 1930 ел. Гомәр Фәтхуллин.

Аның олы улы Мәхмүт Фәтхуллинның өстәп язган язмасын китерәм:

«Колхозлашу елларында Ташлыярда сыйнфый көрәш шактый кискен була. Авылдан (Латыйпов) Сабирҗан, Латыйплар (Аблаков), Хафизетдин хәзрәт хатыны Мәчтүрә абыстай, Атластан Бикмөхәммәт дигән кешеләр раскулачивать ителеп, Магнитогорск якларына җибәреләләр. Мифтахов Гыйльфанның, Вилданов Әгъләмнәрнең (хәлле крестьяннар) налог түләмәгән өчен өйләре тартып алына. Әхмәтлатыйп Гарифы (5 ай) качкач, аның өйләре колхозга алына. Рамазанов Лотфи, Сапа (Сафа – яргыч тоткан. – *Р.Ш.*), Бакыев Латыйп һәм башка хәлле крестьяннарга да өлеш чыкмый калмый. 25 меңче Мөхетдинов Сәет белән Фәтхуллин Гомәр һ.б. Совет яклы, колхоз яклы кешеләр авылда колхозлашу үткәрәләр (Ибраһимов Вагыйз, Сөләйманов Гайнетдин һ.б.). Ләкин яшьләр арасында Шәрәфетдинов Кыям кебек хулиган, кулак койрыклары да була. Алар правление членнарына яла ягу кебек эшләр белән шөгыльләнәләр, хәбәрчеләрне эзәрлеклиләр. Ләкин Мөхетдинов Сәетләр, Фәтхуллин Гомәрләр көрәшне дәвам итәләр. Фәтхуллин Гомәр бу чорда Минзәләдә чыга торган «Игенче», Казанда чыга торган «Крестьян» газеталарының актив хәбәрчесе була. Ул үзенең хатлары аркылы дошманнарның, хулиганнарның, кулак койрыкларының битлекләрен салдыра, фаш итә. 1926–1928 елларда ул 42 хат җибәрә, 1927–1928 елда 57 хат юллый. 1928 елның октябреннан мартка кадәр вакыт эчендә стена газеталарына гына да 30 мәкалә яза. Мондый шартларда газеталарда чагылган кешеләр Фәтхуллин Гомәрдән үч алу юлына басалар. Менә шуңа артык түзәр хәле калмагач, ул вакытлыча Ташлыяр авылыннан китәргә мәҗбүр була. Ул 1930 елның 20 февраленнән «Марс» колхозында хисапчы эшеннән үз теләге белән китә.

1931 елның 10 ноябреннан Пахтаррол районы, Октябрь сельпосында (кайсы өлкәдә икәне әйтелмәгән. – *Р.Ш.*) хисапчы (бухгалтер) һәм внештатный инструктор булып эшли, 15 май 1932 елда үз теләге белән эштән китә (6 ай).

1932 ел, 26 майдан 5 июль 1935 елга кадәр яңадан авылга кайтып үзе төзешкән «Марс» колхозында хисапчы булып эшли. Авыру сәбәпле дәваланырга китә һәм дәвалангач, 1935 ел, 22 июльдән 1 август 1936 елга кадәр Уфада башкорт җир эшләре халык комиссариатында инструктор-бухгалтер булып эшли. 1936 елның 29 сентябреннән 1937 елның 10 июненә кадәр Башкорт АССР Туймазы райпотребсоюзында инструктор-бухгалтер булып эшли һәм 1937 елның 10 июнендә воспаление брюшины белән авырып, кинәт үлеп китә һәм Туймазы татар зиратында күмелә. Күп яклы җәмәгать эшлеклесе, армас-талмас, хезмәт яратучы, яшьләй һәм картая башлагач та рәхәт күрмәгән көйгә әнә шулай һәлак булган безнең әтиебез Гомәр Фәтхуллин.

9 март, 1974 ел.

P.S. Гомәр Фәтхуллин физик яктан бик көчле кеше була. «1927 елда авылда партячейка оештыру буенча зур каршылыклар белән узган җыелышта ул югары авторитеты һәм физик яктан көчле булуы аркасында гына фаҗига булмый калды», – дип сөйләгән иде миңа Зыятдин абый Сәләхетдинов. Һичсүзсез гадәти булмаган бу шәхес Ташлыяр авылы тарихында аерым урын алып тора. Гомере чит җирдә, 42 яшендә фаҗигале рәвештә өзелә һәм җәсәде чит җирдә күмелә. Ул воспаление брюшины – перитониттан үлә. Перитонитның иң еш сәбәпләре:

аппендицит, ашказаны җәрәхәте тишелү, үт куыгы ялкынсыну (холецистит) һәм башкалар. Гомәр Фәтхуллинның үлеме гап-гади аппендициттан да булырга мөмкин.

Аның семьясын калдырып авылдан китү сәбәпләрен һәркем үзенчә гомәнлый ала.

Г.Фәтхуллинның заманында мулла булып торуы аркасында, репрессияләнүдән куркып яшәве мөмкин. Шуның аркасында аңа даими рәвештә Совет властена лояль булуын исбатларга туры килә. Үз чиратында Советлар өчен күрсәткән артык активлыгы аны авыл халкының күпчелеге белән конфликтка китерә.

Бүтән шәхси сәбәпләре дә булырга мөмкин.

ҺӘНҮЗ МИҢНӘХМӘТ

Безнең күршедә, йорт аркылы гына – Миңнәхмәт абыйлар ихатасы. Ул Миндияровлар нәселеннән. Аның олы абыйлары Салих, Гариф, аннан кечерәкләре – Вагыйз һәм бердәнбер кыз туганнары Сәйдә апа (Әсвәт Харисовның әнисе) күрше Чия-Түбә авылында кияүдә, укытучы булып эшләде.

Миңнәхмәт абый төп йортта, ата-бабасы нигезендә яшәде. Ул уртача гына буйлы, чандыр гәүдәле, күп сөйләшергә хирыс түгел, сүз арасында «һәнүз» сүзен еш кыстырып сөйләшә иде. Семьяда лидер – Миңнәхмәт абыйның хатыны, Кәүҗияк авылыннан килен булып төшкән таза бәдәнле Заһинур түти булды. Ул бик тәвәккәл, калын тавышлы, сөйләшкәндә дә боерык биргән төслерәк итеп сөйләшә иде. Заһинур түти күрше-тирә хатын-кызлары арасында да лидер, башлап йөрүче булды.

Илленче еллар башында басуда яшен вакытында ат арбасында кайткан өч кешене яшен сукты. Алда утырган бригадир Гаптерәүф абый Ситдиков белән җигүле ат урында үләләр. Арбада артта утырып кайткан Заһинур түтиләрнең күршесе Зәйнәб түтигә бер зыян да килми. Зәйнәб түти кычкырып та сөйләшми торган бик тыныч холыклы «Алла бәндәсе» кеше иде. Өенә кайткач, моны Заһинур түти эләктереп ала да «яшенеңне чыгарырга кирәк», дип бәрәңге бакчасына алып чыгып җиргә күмеп куйган. Җирдән Зәйнәб түтинең башы гына күренеп тора икән. Шул хәлдә ул аны кичкә кадәр тоткан.

Миңнәхмәт абыйның колхоз эшендә эшләгәнен мин хәтерләмим. Мин белгәндә ул заготовщик, җидееллык авыл мәктәбендә завхоз һәм башка шундыйрак эшләрдә эшләде. Үзе оста итекче иде. Мөгаен, безнең авылда бердәнбер киез итек басучы булгандыр. Гадәттә итек басучылар кыш көннәрендә Кукмара якларыннан килеп, кешеләрнең мунчаларында айлар дәвамында итек басалар иде. Ә менә Миңнәхмәт абый үз мунчасында бик матур киез итекләр басты. Мин Минзәләдә ФАШта укыганда, миңа да бер пар ак киез итек басып биргән иде. Әни итеккә дип ак йон керткәч: «Син, Хәдичә, нәрсә, шул малайдан берәр жүн чыгар дип уйлыйсыңмы? Ярамаган аңа кара итек», – дип әйтеп, әнинең хәтерен калдырган булган.

Миңнәхмәт абый чабата да үргән. Бәлки шуның өчендер, аның кушаматы «чөшле Миңнәхмәт» булды. Чөшле – чабата үргәндә кулланыла торган корал.

Безнең авылда чабата үрү булмады. Халык чабатаны Михайловка базарыннан алып кайта иде. Без, малайлар, тал чыбыгыннан каз оялары үреп, базарда сатып, акчасына чабата сатып ала идек. Яз көннәрендә чабаталарга күтәрмәләр җайлап кия идек.

Авылның югары оч басуында сазлы, кыяклы үлән генә үсә торган ике урын бар. Аларны Югары һәм Түбән әчелек дип атыйлар. Анда үскән үләнне мал ашамый. Ә менә күрше Миңнәхмәт абый һәр елны шушы әчелекләрне чалгы белән чабып ала иде. Мал ашамый торган кыяклы үлән белән ул ни эшләгәндер – мин белмим. Шундый ук хәл югары очның мүклекләре белән була торган иде. Безнең югары оч болынында, күл башында чыккан кечкенә чишмәләр тирәсендә бик яхшы мүк үсә иде. Халык әлеге мүкне, шул исәптән күрше-тирә авыллардан да килеп, йортлар салганда ниргә арасына сүс урынына җәю өчен әзерли иде. Билгеле булганча, мүкне мал ашамый. Ә менә Миңнәхмәт абый шул мүкне чабып җыеп ала иде. Күрше-тирә халкы аның бу гадәтенә ияләнеп, аңа әһәмият бирмәде.

Безгә, югары оч малайларына, иң әһәмиятле булган нәрсә – Миңнәхмәт абыйның прәтниге (ятьмә) иде. Ул елларда сирәк кешедә була торган әйбер. Шушы прәтникне сөйрәп, югары очның бик күп буын малайлары елгада балык тотты. Гадәттә, 14–15 яшьлек малайлар сөзде ул балыкны. 16–17 яшькә җиткәч, аларны икенче яшьрәк буын алыштырды. Балык сөзү үзе бер ритуал иде. Миңнәхмәт абыйның прәтниге киптерү өчен бакча коймасына элеп куелган була. Иң әүвәл җыелышып прәтникнең ертылган урыннарын кәтүк җебе белән «ямап», төзәтеп чыгабыз. Аннан соң прәтникне кул арбасына салып, елга буена төшеп китәбез. Безнең Ташлыяр Мәллә елгасының сул ягына урнашкан. Уң ярында Михайловка авылы. Ул безнең югары оч турыннан башланып, елганың югары агымына таба яр буйлап сузылган. Гадәттә балык сөзүне Михайловка турыннан башлыйбыз. Елгага кайданрак кереп китү, кайсы ташлык тирәсендә чыгу күптән билгеле. Прәтникнең «канатлары»на беркетелгән ике таякны ике ярдан ике малай тартып йөрибез. Бездән кечерәк ике-өч малай бәләкәй арбаны, безнең киемнәрне салып, ярдан тартып бара. Прәтник белән чыгасы урынга (гадәттә ул ташлык була) якынайгач, Миңнәхмәт абый, каршы яктан суга кереп, суга сугып тавыш чыгара. Янәсе, балыклар түбән агымга китмәсеннәр. Прәтник «койрыгында» балык булса: «Менә мин аларны җибәрмәдем, куып керттем», – дип үзенең бу эштәге ролен искә төшерә. Әгәр дә бу керүдә балык эләкмәсә: «Мин аның монда булмасын алдан белдем, менә киләсе дугайда балык әбәзәтелне була», – дип, безне дәртләндерә. Әйтергә кирәк, гадәттә балыксыз кайтмый идек. Төрле балык эләгә: чабак, кушбаш, шүкә (чуртан) һәм башкалар. Иң кызыгы Миңнәхмәт абыйларның ишегалдына кайткач башлана. Башта прәтникне таратып бакча коймасына элеп куябыз. Иң әүвәл зуррак балыкны (гадәттә, сазан) Миңнәхмәт абый алып куя: «Бусы Заһинур апагызның өлеше, прәтник ямаган өчен», – дип аңлата. Аннан соң балыкларны өемнәргә бүлә. Баштан ук бер өлешне прәтник өлеше дип алып куя. Аннан соң инде берәр малайны арты белән борып: «Бусы кемгә? Бусы кемгә?» – дип, балык өемнәрен бүлеп чыга. 16-17 яшьләргә җиткәч, бу буын егетләрен икенче яшьрәк буын алыштыра.

Миңнәхмәт абый белән Заһинур түтинең сугышка кадәр туган ике уллары – Наил абый белән Таһир абыйлар һәм сугыштан соң туган ике кече уллары – Фатих белән Заһир бар. Сугыш вакытында туган бик матур Нурия исемле кызлары үсте.

Мин һәр елны җәйләрен авылга кайтып, үзебез уйнап үскән болыннарны, басу-кырларны, Чагыл тауларын, үзебезнең очның җиләк җыеп йөргән урман аланнарын әйләнеп кайтам. Алан дигәннән, хәзер без бәләкәй чакта җиләк җыйган аланнар юк инде. Аларга нарат агачы утыртып бетергәннәр. Нарат урманын мин яратмыйм, анда катнаш урман яме, исе юк. Ул урманда кошлар да сайрамый. Ә менә су буйлары, болыннар – икенче дөнья. Сугыш һәм сугыштан соңгы елларда югары оч болыннарында өч-дүрт печән эскерте куялар иде. Анда хәзер авыл көтүе генә иркенләп йөри. Анысы да елдан-ел сан ягыннан кими. Югыйсә, көтүлек күп, су эчү өчен янәшәдә генә елга ага. Хәзер авылда чалгы белән печән чабучы юк, комбайн белән генә чабалар. Ә шулай да безнең очта чалгы белән печән чабучы бер кеше бар. Ул – Һәнүз Миңнәхмәт абыйның төп нигездә яшәүче улы Фатих. Ул һәр иртә бакча башына, болынга атын илтеп озын дилбегә белән бәйләп куя. Ел саен болынны чалгы белән чабып, бакча башына икешәр-өчәр зур-зур печән кибәннәре куя. Аннан башка бер кеше дә чалгы белән печән чапмый. Аны күреп, мин гореф-гадәтләрнең атадан балага ничек шулай күчүенә сокланам. Сокланырлык та бит – чын җир кешеләре әле бөтенләй бетмәгән бит авылыбызда!

ЗИННУР БАБАЙ

Безнең йорттан түбән очка таба ике өй аркылы гына Зиннур бабайлар йорты урнашкан. Аларның фамилиясе – Гобәйдуллиннар. Зиннур бабай Беренче бөтендөнья сугышында бер аягын өздереп кайткан. Беренче бөтендөнья сугышында безнең авылдан унга якын кеше катнашкан. Алар арасында гарипләнеп кайтучылар да (Сөләйманов Галимәрдән, Вилданов Имаметдин), әсирлектә булганнар да (Камалов Шәмсемөхәммәт, Мифтахов Гыйльфанетдин) бар.

Зиннур бабай уртача гәүдәле, бер аягы агачтан, таякка таянып йөри торган, без малайлар өчен кырыс кына кеше иде. Ул көннәр буе диярлек капка төпләрендә яткан зур ташта утырырга яратты. Без, бала-чагалар, якынрак килсәк, янында гына торган таягы белән безгә элэктереп тә алгалый иде. Ул вакытларда бала-чаганы олылар янына якын җибәрмәделәр. Олылар сөйләшеп утырган җирне без әйләнеп уза торган идек. Сугыш елларында югары оч малайларының чәчен Зиннур бабай алды. Чөнки барыбызның да диярлек әтиләре сугышта иде. Аның чәч ала торган чалгы пәкесе һаман да истә. Әниләр безне, чәчләре җиткән малайларны, Зиннур бабай хозурына алып киләләр, ә без карышабыз. Чөнки чәч алдыру безнең өчен бер экзекуция була иде. Зиннур бабай безнең башны салкын су белән чылатып ала да чалгы пәкесе белән шатыр-шотыр кыра. Башны сабынлау, җылы су белән чылату турында сүз дә юк.

Зиннур бабайның хатыны кечкенә гәүдәле Сәгыйдә исемле карчык иде. Чыгышы белән ул бүтән очтан, Фәрхетдинов Шәмсетдин бабайның сеңлесе. Авылда кушаматсыз кеше юк. Зиннур бабайлар «Әкет» кушаматлы. Үзен «Әкет» Зиннуры, карчыгын «Әкет карчыгы» дип йөрттеләр. «Әкет» сүзенең нәрсә аңлатканын мин белмим. Аңлатма сүзлекләрдә андый сүз юк.

Зиннур бабайларның өч улы һәм ике кызы бар иде. Олы уллары Сәхәбетдин һәм Мизхәт сугышта катнашты. Сәхәбетдин абый сугыштан исән-сау кайтып, гомере буе колхоз-совхоз фермаларында ветеринария санитары булып эшләде. Тынгысыз, аз сүзле, һәрвакыт нәрсәдер эшләп йөри торган кеше булды. Сәхәбетдин абыйны мин аттан башка җәяүле итеп күз алдына китерә алмыйм. Маллары авырганда, авыл халкына да бик ярдәмчел булды. Хәләл җефете Хаят апа белән алар ун бала үстерделәр. Хаят апага «Герой ана» исеме бирелде.

Зиннур бабайның кече улы ФЗУга алынып, Кузбасста шахтада эшли. Сугыш елларында 1930–1931 елларда туган малайларны мәҗбүри рәвештә ФЗУга алып, шахталарда эшләттеләр. Безнең авылдан киткәннәр Прокопьевский шахталарында җир астында эшлиләр. Ул елларда шахталарда, нигездә, татарлар хезмәт куя. Эш авыр булу сәбәпле, качып кайтучылар да була (Әһли Зөфәре). Ләкин суд ясап, аларны төрмәләргә утырталар. Араларында авырып кайтучылар да була. Зиннур бабайның кече улы Фәрит абый да авырып кайтып, бик яшьли үпкә чиреннән вафат булды. Зиннур бабайның кызлары Хәмдүнә һәм Әлфия исемле. Әлфия миннән бер генә яшькә зур. Зиннур бабайның уллары Мизхәт белән Фәрит бик тә ыспай егетләр иде. Безнең авылда чиста, матур итеп киенеп йөргән кешене «ыспай кеше» диләр. Кичләрен кешеләр капка төпләрендә җыелышып сөйләшеп утырганда, алар бервакытта да утыргычка яки ташка утырмадылар. Баскан килеш киемнәрен сыпыргалап кына торырлар иде. Сугыштан кайткач, Мизхәт абый медальләр тагып йөрергә яратты. Ул күн итекләрен ялтыратып, түшләренә медальләрен тагып йөргәндә, сугыш елларында егетләргә «сусаган» авыл кызларын кызыктырырлык егет иде. Үзе бик шаян, тапкыр сүзле кеше булды. Егет чагында кызлар янына барганын сөйләгәндә: «Төшәм инде, малай, түбән очка медальләрне тагып, чыга инде шунда каршыга Сөләйман кызы шахтер башмагын сөйрәп», – дип көлдерә иде. Янында басып торган хатыны Гөлчирә апа (Сөләйман кызы) Мизхәт абыйга кушылып кет-кет көлер иде. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, ул елларда резинадан эшләнгән шахтер башмагы затлы аяк киеме саналды.

Бер елны авылга ялга кайткач, кичкырын капка төбендә сөйләшеп утырабыз. Югары оч ягыннан гармунын тартып, шактый гына кызмача Мизхәт абыйның олы улы Мисбах урамга килеп керде. Аның Михайловка совхозында «кунак булып» кайтып килүе икән. Михайловка ул елларда якын-тирәдә бер үзәк булды. Анда сельпо (рабкооп), больница, почта, ашханә бар иде. Мизхәт абый миңа борылды да: «Менә, күрше, эчүне ташлаган идем, Мосбах тапкан бит. Ераккарак ташлыйсы калган икән», – дип шаяртып куйды. Мизхәт абый Мисбахның исемен үзгәртеп Мосбах дип әйтә торган иде. Бу семья бик музыкаль семья булды. Дүрт малайлары барысы да гармунчы, кичләрен капка төбендә гармун уйныйлар иде. Бер уллары Алин (Мизхәт абый аны «Олень» дип йөртә иде) – районыбызда

танылган баянчы. Зәйтел (Зәйтелҗинан) исемле кызлары бик матур тавышлы җырчы булды. Ул Сарман районы, Әлмәт шәһәре ансамбльләрендә солистка булды. Зөлфия исемле кызлары да бик матур җырлый иде.

Мизхәт абыйның балаларына кош койрыгы исемнәрен кушып сөйли торган гадәте бар иде. Мисбахны ул – карга койрыгы, Зәйтелне сандугач койрыгы дип йөртте.

Югары очның бакча башында күл буенда үсә торган карт өянкеләр бар. Болар – Зиннур бабай утырткан өянкеләр. Яшьләр моны белсеннәр, онытмасыннар һәм соклансыннар иде.

ДУСТЫМ КОТДҮС



Минем гомеремдә иң якын, аңлашып, аралашып яшәгән дустым Котдүс Хөснуллин булды. Без – күршеләр, туган йортларыбыз урам аркылы бер-берсенә каршы гына урнашкан иде. Соңрак алар безнең су буе урам рәтенә, бездән өч кенә өй аркылы урынга йорт салып күченеп утырдылар.

Мин Котдүстән бер яшькә өлкәнрәк. Шуның өчен мәктәптә бер класска алданрак укыдым. Котдүснең әтисе чыгышы белән Буралы авылыннан (хәзер Азнакай районына керә). Революциягә кадәр Буралы, безнең Ташлыяр авылы шикелле, Минзәлә өязе, Карамалы-Александровка волостена караган. Бу авыллар аралашып, килен алышып-бирешеп яшәгәннәр. Җәмәгате Мәбрүрә апа белән өйләнешкәч, Мирзасалих абый безнең авылда төпләнеп калган. Ул мәһабәт гәүдәле иде, Балтыйк флотының «Марат» линкорында хезмәт иткән. Шуның өчен аны «Краснофлотец» дип йөрттеләр. Котдүснең әнисе Мәбрүрә апа – Аблак Морзаханнар нәселеннән Морзаян кызы.

Мирзасалих абый белән Мәбрүрә апа икесе дә табигатьне искиткеч аңлаучы, яратучы кешеләр иде. Минем аларның икесенең бакча коймасы янында чүгәләп, тын да алмыйча, бакчаларына оя ясаган сандугачның сайраганын тыңлап торганнарын күзәткәнем бар. Һәр яз шул сандугачның килгәнен көтеп алып, сандугач килгәч, аларның ничек шатланганнарын күргән кеше генә аларның нинди нечкә күңелле кешеләр булуын аңлый ала. Күрәсең, шуннандыр, аларның балалары да табигатьне аңлаучы, яратучы нечкә күңелле кешеләр булды. Котдүс, миннән аермалы буларак, бәләкәй чактан ук бөтен кошларның, җәнлекләрнең, үләннәрнең исемен белә иде.

Котдүснең абыйсы Әнвәр абый авылның танылган гармунчысы иде. Аларның өендә тальян гармун, соңрак ике рәтле «хромка» гармуннары булды. Без Котдүс белән шул гармуннарда уйнарга өйрәндек.

Котдүснең абыйсыннан башка бик чибәр Рәзинә исемле апасы (күбрәк читтә яшәде) һәм Рим исемле энесе бер иде. Рим – атасы шикелле мәһабәт гәүдәле, фи-

зик яктан бик көчле, заманында Ташлыяр һәм күрше-тирә авылларның Сабантуйларында мәйдан тоткан батыр. Ул – РФ һәм ТРның атказанган агрономы.

Безнең очның бәрәңге бакчалары башында гына тегермән буасы җәелеп ята иде. Буаның югары оч болынына ярты чакрымга сузылган зур култыгын «Югары оч күле» дип йөртәләр. Буа һәм күлнең ярларында өянкеләр, Бикмөхәммәт мулла утырткан тупыллар, яшь таллар үсә. Безнең югары оч малайларының бәрәңге бакчасындагы эшләрдән (утау, матиклау, күмү) бушаган вакытлары шул су буенда үтте. Кичләрен күлдә бакалар симфониясе яңгырый. Ни гажәп, Котдүс бәләкәй чагында бакалар яратты. Ул аларны тотып, шулар белән уйный иде. Хәтердә, шулай бервакыт төш вакытларында безгә Котдүс килеп керде. Йөзе шундый шат, авызы ерылган. Чалбар бөрмәсенә кыстырылган күлмәк эченә, башындагы фуражкасына тутырылган бакалар дыбыр-дыбыр киләләр. Башындагы фуражкасы очып китәрдәй булып дерелди. Бу минутта Котдүстән дә шат кеше юк иде. Төшке ашка кайтып ашап утырган минем әти, Котдүсне күргәч, сүзсез калды, кулындагы кашыгы төшеп китте. Бу хатирәне әти соңыннан да искә алып елмая торган иде.

Бераз үскәч, Котдүснең бакаларга булган «мәхәббәте» сүрелде. Мәктәптә укый башлагач, мин аның бакалар белән уйнаганын хәтерләмим инде. Без Котдүс белән балык тотарга һәвәс идек. Кармак белән дә, җәтмә белән дә тоттык. Буада балык күп булды.

Җир җиләге җитешкәч, көн саен диярлек урманга, өч чакрым ара үтеп, җиләк җыярга йөри идек. Кайткач, җиләкне катык белән бутап ашый идек (ипи юк). Шулай итеп без «йогурт» ашап үстек.

Сугыштан соңгы елларда Котдүснең әтисе Мирзасалих абый умартачы булып эшләде. Колхозның (соңрак совхозның) умарталыгы бик матур урында, мул сулы чишмә буенда урнашкан иде. Чишмә кыйблага карап чыга, инеш булып, авылның төньягында ага торган Кәүҗияк елгасына (кизләвенә) килеп төшә. Чишмә мул сулы. Хәзерге вакытта шушы чишмәнең суын куәтле насослар ярдәмендә район үзәге Мөслимгә куалар. Ул вакытта шушы чишмәне буып, суны умарталык белән янәшәдә генә урнашкан яшелчә бакчасы арасындагы тирән арыкларга җыялар иде. Яшелчә түтәлләренә суны буадан арыклар аркылы гына агыздылар. Яшелчә бакчасында кыярлар бик уңа иде. Авылдагы шаянрак яшьләрнең кичен (клубтан соң) яшелчә бакчасына һөжүм иткән чаклары да була иде. Яшелчә бакчасында бригадир булып Шәйдуллин Нурулла абый, ә каравылчы булып бик күп еллар Һидият абый Галимов эшләде.

Умарталык белән яшелчә бакчасы биек тупыллар белән әйләндереп алынган. Умарталыкта алма агачлары, кура җиләге һәм башка куаклар үсә иде. Печәнне без Котдүс белән төнлә, бал кортлары тынгач, ай яктысында чаба идек.

Умарталыкта умартачы йорты бар. Анда умарта кораллары, буш умарталар, аертылган бал, Мирзасалих абыйның олы бидонда ачы балы (медовуха) булыр иде. Безнең медовуха белән шаярганны мин хәтерләмим. Ә менә кружкадан яңа аерткан бал эчкәндә (аны күп эчеп булмый), минем телне корт чакканы истә. Кортның угын Котдүс телнең төбеннән үк алгач, тел бик тиз шеште, авызга сыймый башлады. Ярга ятып чишмә суына тыгып торгач, шеше бик тиз кайтты тагын.

Җидееллык авыл мәктәбен тәмамлагач, мин Минзәлә медицина училищесына (ФАШ) укырга кердем. Ә Котдүс Алабуга культура-агарту техникумына укырга китте. Аның профессиональ музыкага юлы шуннан башланды. Без Май һәм Октябрь бәйрәмнәренә, кышкы һәм җәйге каникулларга сагынышып кайта идек һәм бергә уздыра идек. Кышкы каникул вакытларында мылтыклар алып басуларда, урманнарда йөри идек. Котдүс мылтыктан бик төз ата иде. Бервакыт Кәүжияк елгасының урман як яры буйлап барганда, карда куян эзләре күрдек. Зур ишегалды кадәр мәйдандагы каты карның һәр ягында да яңа үткән куян эзләре ярылып ята. Котдүс шунда ук: «Куян монда, эз бутаган», – диде. Миңа кар кырыеннан барырга кушып (эт урынына), үзе мылтыгын әзерләп куйды. Чыннан да, бер урыннан куян сикереп чыкты, Котдүс куянны бер атуда хәл итте.

Культура-агарту техникумын тәмамлагач (ул анда Вафирә Гыйззәтуллина белән бергә укый), Котдүс Казан музыка училищесының хор дирижерлыгы бүлегенә укырга керде. Алар Шамил Әхмәтҗанов, Хәнәви Шәйдуллин, Имбир Шәфыйковлар белән бергә төрле бүлекләрдә укыдылар. Минем бу танылган шәхесләр белән танышу, якыннан аралашу шул елларда башланды. Мин ул вакытта Казан медицина институтында укый идем. Музыка училищесының тулай торагы булмау аркасында, Котдүс белән безнең тулай тораста бер койкада йоклаган чаклар да булды. Училищеда укыганда, Котдүсне армиягә алдылар. Без аның белән хатлар алыштык. Мин аңа яңа җыр текстлары җибәрә торган идем. Аның Рөстәм Маликов җырлый торган «Солдат кайта туган ягына» җырының сүзләрен (Шәүкәт Галиев шигыре), газетадан кисеп алып, мин җибәргән идем.

Армиядән кайткач, ул укуын дәвам итте. Музыка училищесын тәмамлагач, аны Мөслимгә эшкә җибәрделәр. Ул вакытта Мөслимдә музыка мәктәбе ачылган чак иде. Котдүс шул мәктәптә укытты. Шул ук вакытта район сәнгать йортында актив эшләде, хор оештырды. Ул оештырган хорга соңрак «академик хор» исеме бирелде, Мәскәүдә Бөтенсоюз фестивалендә катнашты. Ул елларда Мөслимдә үзешчән сәнгать шактый зур югарылыкта иде. Гаяз Авзалов, Васил Гайфуллин, Халидә Уразаева, бертуган Спартак һәм Карл Әхмәтовлар танылган җырчылар булдылар.

1976 елда Котдүс, гаиләсе белән Казанга күчеп килеп, Казан консерваториясенең теория-композиторлык бүлегенә укырга керде. Соңрак ул консерваторияне, кичке бүлеккә күчеп, профессор Луппов классында тәмамлады. Диплом эше итеп «Көмеш дага» исемле балет язды.

Котдүс консерваториядә укыган еллардан башлап, аның аркылы мин Мирсәет Яруллин, Фасил Әхмәтов белән танышып якынлаштым. Без гаиләләр белән аралашып яшәдек. Фасил дә, Мирсәет тә бик яхшы баянчылар иде. Алар икесе дә музыка училищесын баян классы буенча тәмамладылар. Фасил филармониядә ике ел баянчы булып эшләгән. Мирсәет аккордеонда да бик яхшы уйный иде.

Котдүс – бик күп җырлар, инструменталь әсәрләр авторы. Кайвакыт ул үзенең авторлыгын дәгъваламый да. Мәсәлән, аның Шәүкәт Галиев сүзләренә язылган «Сөенечкә дисәм» исемле җырын халык җыры дип йөртәләр. Мин бу җырның язылу тарихын яхшы беләм. Котдүс безнең авылга багышланган «Ташлыярым» җырын (сүзләрен дә, музыкасын да) язды.

Казанга күчеп килгәч, Котдүсләргә төрле урыннарда яшәргә туры килде. Алар, хатыны Кафиянең Савин поселогында үз йортлары белән яшәүче бер туганнарының ишегалдында, тактадан, ике кат такта арасына пычкы чүбе тутырып («насыпушка») өй эшләделәр. Без бу йортны җыелып өмә формасында Нурулла абый (Кафиянең туганы) җитәкчелегендә эшләдек. Бу урыннар түбән җир, якын-тирәдә сазлыклы күлләр булу аркасында, яз көне идән өстенә кадәр су чыга иде. Ә идәндә пианино тора. Алар биредә Котдүс квартира алганчы яшәделәр. Бу йортта без еш очраша торган идек. Кафия әйтмешли, бер селедка алып кайтсаң да, бәрәңге пешереп дусларны чакырыш иде. Баксаң, бу еллар, ярлы еллар булса да, тормышның иң кызык еллары булган икән.

Котдүс ИЯЛИдә музыкаль фольклор бүлегендә эшләде. Ул – магнитофонын күтәреп, фольклор экспедицияләре составында Советлар Союзының татарлар яшәгән бөтен төбәкләрен җәяүләп әйләнеп чыккан кеше. Аның искиткеч бай, әле эшкәртелеп бетерелмәгән архивы бар. Шул материаллар нигезендә ул «Мөнәҗәтләр һәм бәетләр» исемле зур күләмле (724 бит) хезмәтен бастырып чыгарды. 2001 елда бу китап Г.Тукай исемендәге премиягә тәкъдим ителде. Ул бүләкнең бирелми калуы кызганыч, әлбәттә.

1984 елны Котдүс, Культура министрлыгына эшкә күчеп, министрлык каршында фольклор үзәге оештырды, җитәкчесе булды. Аның башлангычы белән шушы елларда «Уйнагыз, гармуннар» дип аталган музыкаль-этнографик бәйрәм, яңа халык бәйрәме барлыкка килде. Илнең төрле төбәкләреннән татар гармунчылары җыелып сәхнәдә ярыштылар, Казан урамнарын шаулатып, гармуннарда уйнап йөрделәр. Бу еллар халыкның милли аңы үсеше, яңарыш еллары булдылар. Котдүс Хөснуллин – татар милли музыкаль культурасының яңарышына, үсешенә зур өлеш керткән шәхес.

Котдүс – ТАССР Композиторлар берлеге әгъзасы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

МӘХМҮТ ФӘТХУЛЛИН

Авылыбызның тарихында, аның зыялы кешеләренең берсе буларак, Мәхмүт абый Фәтхуллин аерым урын алып тора. Һәр көнне аралашып, дөнья мәшәкатьләре һәм һәрдаим каршылыклар булып торган бу дөньяда без кешеләргә дөрес бәя биреп бетермибез. Еллар узгач кына, вакыт ераклыгыннан кешеләрнең колачы-масштабы дөресрәк, яхшырак күренә башлый. А.Пушкин әйтмешли, «Лицом к лицу – лица не видать, лицо видится на расстоянии». Мәхмүт абый, һичсүзсез, кеше һәм шәхес буларак, укымышлы, масштаблы фикер йөртүче, шул ук вакытта үзенчәлекле, каршылыклы кеше иде. Минем уйлавымча, аның характерына, дөньяга карашына бала чагының шаукымлы елларга туры килүе, әтисенең фаҗигале язмышы һәм башка факторлар тәэсир иткәндер. Ул эре сөякле, олпат гәүдәле, калын тавышлы, һәрвакыт нәрсәдәндер канәгать булмаган шикелле, йөзен «җимереп» йөри торган кеше булып хәтердә калган. Кеше белән сөйләшкәндә, аның йөзенә туры карап сөйләшми иде. Мин аның көлгәнен

хәтерләмим. Бу Фоат Садриевның «Көлми торган кеше» исемле повестендагы тормыш авырлыгы аркасында көлүдән бизгән Газизҗан түгел. Мәхмүт абыйның көлмәве – аның характерының нәселдән килгән бер чагылышы, минемчә. Мәхмүт абый 1918 елда туган. Ул – мулла Гомәр Фәтхуллинның олы улы. Бу гаиләдә Мәхмүт абыйдан башка Мидхәт, Суфиян, Мәрнүсә исемле балалар була. Энесе Мидхәт абый сугыштан соң гомере буе Мөслим урта мәктәбендә укытучы-военрук булып эшләде. Суфиян исемле икенче энесе (офицер) Ватан сугышында танкта янып һәлак була. Бердәнбер сеңелләре Мәрнүсә Туйгелде авылында яшәде, укытучы булып эшләде.

Мәхмүт абый Ташлыяр авылы мәктәбендә, соңрак укытучылар институтында белем ала. Сугышка кадәр авыл мәктәбендә укытучы, мәктәп директоры вазыйфаларын башкара. Бөек Ватан сугышында катнаша. Үзен чекист дип яза. Чекист буларак нинди хезмәт башкарганы билгесез.

Сугыштан соңгы еллардан башлап, аның бөтен гомере мәгариф эшенә бәйле. Дөрес, 1957 елның гыйнварында аны колхоз председателе итеп сайлыйлар. Ул бу эшне ярты ел гына башкара. «Марс» колхозын «Мөслим» совхозына кушып, Ташлыяр авылы бүлекчә булып калгач, ул председательлекне ташлап, мәктәпкә кире кайта. Сугыштан соң башта Олы Чакмак авылында укытучы һәм мәктәп директоры булып эшли. Илленче еллар башында аны Ташлыяр мәктәбенә күчерәләр. Ул биредә тарих укыта. 1959 елда мәктәп директоры һәм партия оешмасы секретаре булып эшләгән Рабига апа Нуретдинова авылдан күчеп киткәч, Мәхмүт абыйны мәктәп директоры итеп билгелиләр. Ул бу эштә 1971 елга кадәр эшли. Бер үк вакытта башлангыч партия оешмасы секретаре вазыйфасын да башкара.


1958–1960 елларда мин Ташлыяр авылында фельдшер булып эшләдем. Медицина пункты мәктәп белән янәшәдә генә урнашкан иде. Мин мәктәпкә еш керә идем һәм миңа бу елларда Мәхмүт абый белән якыннан аралашырга туры килде. Мәхмүт абый мәктәп канцелярисендә даими төнге сәгать унберләргә кадәр эшләп утыра торган иде. Без, яшьләр, клубтан таралышкан чакларда да, аның тәрәзәсендә ут янар иде. Аның миңа берничә мәртәбә: «Син нигә кичләрен үз өстеңдә эшләмисең, укымыйсың?» – дигәне булды.

Ул партия эшендә бик актив катнашты. Партия турында берәр сүз чыкса, яки берәрсе партиянең кайбер политик юнәлешенә шик белдерсә (укытучылар арасында андыйлар бар иде), Мәхмүт абый шунда ук сикереп торып, үзенең калын тавышы белән: «Партиянең политикасы обсуждению не подлежит!» – дип сүзне туктатыр иде. Ул партия исеменә тузан да төшермәслек дәрәҗәдә бирелгән кеше булды. Ул эшләгән елларда сайлау кампанияләрендә Мәхмүт абый алыштыргысыз сайлау комиссиясе рәисе булды, бу хезмәтне бик яратып башкарды.

Мәхмүт абый район, республика газеталарының актив хәбәрчесе булды. Үзе төзегән архивта район газетасының ул язган мәкаләләр урнашкан саннарының зур теркәмә-төпләмәсе бар. Ул төрле характердагы, күбрәк эшчеләр, терлекчеләр, механизаторлар турында язган. Тарихны өйрәнгәндә, Фәтхуллиннарга (әтисе Гомәрне, энесе Мидхәтне дә кертеп) газеталарга мәкалә язу «чире» хас булуы күзгә ташлана.

Фәтхуллиннар шәҗәрәсе

Мәхмүт Фәтхуллин төзеде



Искәрмә:

1) Фәтхулланың Сәгъдетдин, Мөхетдин ир балалары ботаклары корыган (үлеп беткән);

2) калган балаларының берәр тармагы гына күрсәтелгән.

Мәхмүт абый турында сүз барганда, аны хатыны Фәрдәнә апа Закировадан аерып карап булмый. Фәрдәнә апа (авылда аны Фая апа, Фая Закировна дип йөрттеләр) Ташлыяр мәктәбендә рус теле укытты. Сугыш елларында бер ел мәктәп директоры булып эшли. Ул тәҗрибәле, белемле укытучы иде. Фәрдәнә апа үзешчән сәнгать белән бик актив шөгыльләнде. Гомумән, ул елларда мәктәп һәм укытучылар коллективы авылның сәнгать үзәге булды. Укытучылар, авылның актив яшьләре катнашында спектакльләр, концертлар куйдылар. Күрше авылларга барып спектакльләр кую гадәти күренеш иде. Бу эштә әйдәп йөрүче, спектакльләрне куючы режиссер Фәрдәнә апа булды.

Мәхмүт абый белән Фәрдәнә апаның дүрт балалары була. 1942 елда туган олы кызлары бәләкәй чагында ук менингит авыруыннан үлә. Олы уллары Джек 1946 елда туган, әтисе төсле олпат гәүдәле бик чибәр егет иде. Ул Ульяновск хәрби танк училищесын тәмамлагач, Германиядә (ГДР) хезмәт итә. 1973 елны онкологик авырудан 27 яшендә дөнья куя.

Язучы Роза Хәбибуллинаның «Чишмә башы» повестендагы («Миләш елы» исемле китапта) Илдар образы Джек Фәтхуллинның фаҗигале язмышыннан алып язылган. Джек Фәтхуллин чит җирдә, Ульяновск шәһәрендә җирләнә. Джекның язмышы бабасы Гомәр мулла язмышы белән аваздаш, минемчә.

Мәхмүт абыйларның 1955 елда туган кече уллары Илдар юл һәлакәтендә бик яшьли һәлак булды. Фәтхуллиннарның нәселен Чаллы шәһәрендә яшәүче 1951 елда туган уллары Илгиз һәм аның балалары дәвам итә.

Мәхмүт абый үзе 1988 елда, нибары 70 яшендә йөрәк авыруыннан дөнья куйды.

Мәхмүт абый озак еллар Ташлыяр авылы тарихы буенча материаллар җыйган, бик күп кешеләр белән хатлар алышкан, шактый бай архив оештырган. Без – яшьләр: «Бу Мәхмүт абый төнлә мәктәптә нишләп утыра икән?» – дип әйтә торган идек. Баксаң, ул изге эшләр эшләп утырган икән. Мин ошбу язмамда Мәхмүт абый калдырган материаллардан, архивтан киң файдаландым. Урыны җәннәттә булсын.

ЙОМГАКЛАУ СҮЗЕ УРЫНЫНА

Кеше, бигрәк тә авылдан китеп чит җирләрдә яшәүчеләр, гомере буе үзенең туган-үскән җирен, авылын, бергә уйнап үскән иптәшләрен сагынып яши. Гомерендә кешегә күпме дуслар очраса да, бала чактагы шикелле эчкерсез дуслык булмый.

Ташлыярда туып-үскән (1924), авыл мәктәбен тәмамлаган Рамазанов Өлфәт абыйның (ул үзен Олфат дип яза) язмаларын китерәм. Мин аның исемен искә алган идем инде. Ул – Рамазан байның оныгы, Казан химия-технология институтын тәмамлаган инженер-химик. Бөек Ватан сугышында Сталинград өчен барган иң дәһшәтле сугышларда катнаша. Аңа исән-сау кайтырга насыйп була. Хәзер Уфа шәһәрендә яши. Өлфәт абый гомере буе туган авылы Ташлыярны сагынып яши. Зарипов Таһир абый белән хат алышалар. Аның язган хатларын һәм шигырьләрен миңа Таһир абый тапшырды.

Бөек Ватан сугышында ятып
калган Ташлыяр авылы
егетләренә багышлыйм

Изге әманәтем

Идел яр буйларын тирән карлар баскан,
Сугыш кыры ярсый. Кырык градуслы салкыннар;
Соры шинель кигән минем авылдашлар
Атакада – уттан чыгалар да, ургылалар тагын ялкынга.
Сезгә, дуслар, һаман кырык өченче ел,
Идел үзәнендә өзеп ала торган салкыннар;
Һаман йөгерәсез алга, билдән карлар ерып,
Фашист дигән дошман артыннан.
Ватан батырлары! Туган Ташлыярга
Нигә шулай озак кайтмыйсыз?
Приказ килмәдеме, әллә Идел буйларында,
Мамай даласында
Хәрби маршларга атлыйсыз?
Идел буйларында, сугыш кырларында
Сез унсигез яшьтә калдыгыз;
Минем күңелемдә, минем җырларымда
Мәңге сүнмәс урын алдыгыз.
Сталинград, Идел ярлары,
Утлы траншеялары әле дә күз алдымда;
Атакага йөгердегез алга, күктән гайрәт алып,
Батыр яшьтәшләрем, инде ничә еллар
Төшләремә шулай керәсез.

Идел сулышын тыңлап йоклый
Минем яшьтәшләрем...
Шинель кесәсендә әнкәсенең
Күз яшьләре тамган хатлары;
Инде мамык булсын, дуслар,
Яткан мендәрегез –
Туган илебезнең изге туфрагы.
Изге әманәтем сезгә, Идел дулкыннары,
Җиткерегез дусларыма кызыл чәчәкләрнең
Венок – бәйләмен.
Канлы сугыш кырларында яшьтәшләрем калды,
Ватаным, яулаганда сиңа
Җиңү бәйрәмен!

Курск-Орлов дугасындагы легендар танклар сугышында катнашкан курку белмәс танкистка – яшьтәшем һәм дустым Зиннур Камаловка багышлыйм.
Рамазанов О., 1964.

Күпме еллар узды, ничә тапкыр
Атлас урманнары, яшел имәннәр,
Минем хисләремдә үскән ак каеннар –
Назлы чибәркәйләр, яшел хәтфәләр
Яфраклардан яулык чөйгәннәр.
Ничә тапкыр көмеш Мәллә
Ярларыннан чыкты ургылып.
Калын бозлар яр буйларын җимереп,
Диңгезләргә алып киттеләр.
О, мең йолдызлар, сезнең кодрәтегез!
Бәлки сездән килә
Кара төндәй кара язмышлар...
Кайсы кайда ята микән –
Минем ахирәтләр, утыз ике яшьтәш –
Батыр егетләрең, Ташлыяр?

Зиннур абый Камалов сугыштан исән-сау кайтып, озак еллар авылда агроном, авыл Советы рәисе булып эшләде.

Зөфәр истәлегенә, җырчы дустыма

Кырүзәннең болыннарын айкап,
Офыкларны буяп зәңгәргә,
Ал таң ата, Зөфәр җырлап кайта!
Эх, мин гармунчы булсам әгәр дә...
Җырлар идем өзелеп сөйгәнемнең
Иң яраткан матур җырларын.

Ап-ак шомырт, сирень чәчәкләренең
Иң матурдан-матур дигәнен.
Гөлзаһирә, таң атканда тәрәзәңне яба күрмә!
Синең өчен җырлый Зөфәр-сөйгәнең.
Тирән шахталардан кайнар йөрәгендә
Саклап алып кайткан көйләрен:
– Шахтер егет күмер кисә,
Кемнәр ала исәбен.
Гомерем булып, исән кайтсам,
Ташламам, җан кисәгем!..

Шигырь авторның яшьтәше, дусты Харисов Зөфәргә багышлана. Зөфәр абыйның искиткеч матур, сирәк очрый торган бәрхет тембрлы лирик тенор тавышы бар иде. Минем аның 1950 еллар тирәсендә, Мәллә буасында көймәдә Әпсәләм Салихы белән (ул гармунда уйный) җырлаганын ишеткәнем, күргәнем булды. Кешеләр аның җырлавын ярга тезелеп тыңлады.

Язмамны тәмамладым, ә торып, кузгалып китәсем килми. Әйтерсең лә мине кемдер тотып тора. Әлбәттә, күңелем белән сизәм: мине авылдашларым тотып тора. Барысы да күз алдымда, холык-фигыльләре, гыйбрәтле тормышлары, бәхет-фаҗигалары – һәммәсе, һәммәсе күз алдымда. Без – бер гаилә бит. Инде күптән бакыйлыкка күчкәннәре дә янәшәдә генә кебек. Авылга ераклардан килеп нигез салучы татарның гаярь улларын да онытып булмый. Бу бит – шушы җирләрдә, иксез-чиксез ил халкы белән бергә-бергә кичергән җәбер-җәфалар да, шатлык белән алышынган бәхетле мизгелләр дә. Халык, чыннан да, бөек. Патша заманнарында күпме газаплар, иҗтимагый-сәяси гарасатлар кичерелмәгән! Халык барыбер баш имәгән, рух ныклыгын да, үз кавемен дә саклаган, ишәйткән. Октябрь революциясе, гражданнар сугышы, ачлык еллар, коллективлашу дәверләре, коточкыч кайгы-хәсрәт китергән, авылыбызның газиз балаларын һәлак иткән Бөек Ватан сугышы чорлары. Аннан соңгы бер-бер артлы дулкын булып килгән колхоз-совхозларны әле кушу, әле аеру шаукымнары төрле-төрле рәвешләргә кереп дәвам итә. Инде кыйбла Совет җәмгыятеннән кабат капитализмга таба борылды. Ә халык, авылыбыз яши. Мин горурланып, татарның ныклыгына сокланып китабымны әле генә язган сүзем белән төгәллисем килә: халык, чыннан да, бөек! Җирдә тормышны тоткан өчен рәхмәт сиңа, халкым! Ташлыярны иң кыен дәверләрдә дә саклаган, бүген дә үз иңнәрегез, көчле рухыгыз белән аны яшәткән өчен мең-мең рәхмәт сезгә, хөрмәтле авылдашларым! Тормышта ниндидер тыйнак кына уңышларга ирешкәнмен икән, алар өчен дә мин сезгә бурычлы. Авыл каны, авыл җаны, авыл чырышлыгы миңа гомерем буе булышты. Сез, ара ерак булса да, гел минем янәшәмдә булдыгыз. Минем бу кечкенә китабымны сезгә булган ихтирамым, рәхмәтем билгесе дип кабул итегез.

Еллар үтәр. Безнең буын да бу якты дөньяны калдырып китеп барыр. Бу китап киләчәк буыннарга да бер истәлек булсын иде.

Равил Шәймәрдәнов.

Хөрмәтле авылдашлар!
Монда язылган кайбер белешмәләр чынбарлыкка туры килмәскә яки тулы булмаска мөмкин. Сездән яңа мәгълүматлар көтеп калабыз. Киләчәктә, китапның яңа басмасын нәшер иткәндә, шәт, аларны өстәп, дөресләп чыгарырбыз.

УҢЫШ УРАМЫ



№ 2. Бер ишек алдында ике йорт. Йорт буш тора.

№ 1. Латыйпов Мисхәт Сабиржанулы (1939–1990) белән Латыйпова Җәүһәр Габделиксан кызы (1943–2015) йорты. Балалары: Марат (1961), Резидә (1962), Азат (1965). Азат Латыйпов белән Латыйпова Гөлнара Нәркис кызы (1966) яши. Балалары: Ландыш (1991), Миләүшә (1993).



№ 2(а). Сабитов Әслах Фатыйх улы (1938) белән Сабитова Суфия Вәҗетдин кызы (1940–1985) йорты. Балалары: Марс (1963), Лиза (1966), Лена (1971), Сирин (1980), Әслах Фатыйх улы белән Сабитова Рәзинә Гайни кызы (1944) йорты. Балалары: Илмир (1986).





№ 3. Гайсин Вәлиәхмәт Миннәхмәт улы (1928–вафат) белән Гайсина Маһинур Фатих кызы (1927–2016) йорты. Балалары: Миңнеяр (1952–1984), Өлфәт (1950), Әнәс (1955), Нәсим (1959–2002), Рәсимә (1958), Нәфис (1962), Рәсилә (1968), Ирек (1969–1998). Хәзерге вакытта Гайсин Өлфәт яши.

№ 4. Сафиуллин Раиф Закир улы (1939) белән Нургалиева Әҗимә Нургали кызы (1937–2011) йорты. Раиф Закир улы яши.





№ 5. Фәхразыев Наил Фәхразый улы (1939–2003) белән Фәхразыева Зәкия Тажи кызы (1935–2000) йорты. Балалары: Розалия (1961), Разил (1964), Гүзәлия (1968), Рушания (1966), Флүс (1970). Өй буш тора.



№ 6. Абдуллин Әзһәр Сибгатулла улы (1940) белән Абдуллина Рәсимә Яппар кызы (1940) йорты. Балалары: Тәслия (1962), Фирая (1967), Лилия (1965), Нәфис (1974–2007), Ләйлә (1978).



№ 7. Мөҗипов Шәйхенур Мөҗип улы (1932–2009) белән Мөҗипова Заһирә Фәрхетдин кызы (1928–2012) йорты. Балалары: Вәзирә (1958), Газинур (1961), Гүзәлия (1963), Мәгъдәнур (1964), Илсөяр (1968). Өй буш тора.



№ 8. Әхмәтҗанов Әзһәр Хәйбрахман улы (1938) белән Әхмәтҗанова Саимә Шәрип кызы (1940) йорты. Балалары: Хәния (1964), Айрат (1966), Илнур (1973). Айрат Әзһәр улы белән Әхмәтҗанова Роза Миңнулла кызы (1975) яши. Балалары: Лилия (1999).



№ 9. Сабитов Фатих Сабит улы белән Исламова Миңниямал Исламгали кызы (1918–2001) йорты. Балалары: Әслах (1938). Өй буш тора.

№ 10. Гайфуллин Мөдир Талибулла улы (1931–1999) белән Әгъзамова Галия Мотыйгулла кызы (1930–2014) йорты. Балалары: Камил (1959). Йорт буш тора.





№ 11. Шәйдуллин Рәүф Мотыйгулла улы (1937–2001) белән Шәйдуллина Фәтхия Мирзаян кызы (1948) йорты. Балалары: Фәридә (1973), Резедә (1974), Рүзилә (1976), Рөстәм (1980–2004), Рәдиф (1984) Фәтхия Мирзаян кызы улы Рәдиф белән яши.

№ 12. Кашапов Ясир Кашапетдин улы (1927–1997) белән Кашапова Мәсхүдә Фаретдин кызы (1923–1999) йорты. Балалары: Гөлгенә (1951), Наилә (1955), Наил (1959), Рәшит (1962). Йорт буш тора.





№ 13. Мөҗипов Мәгъдәнур Шәйхинур улы (1964) белән Мөҗипова Дамира Габделбари кызы (1961) йорты. Балалары: Илмира (1987), Алсу (1990), Динара (2001).



№ 13(а) Салихов Гариф Салих улы (1930–1972) белән Салихова Миңниса Сөләйман кызы (1927–1983) нигезе, балалары: Хөрмәт (1959–2005), Фәнүсә (1963) Иксанов Илмир Рафаэль улы (1976) белән Иксанова Резедә Яхья кызы (1979) йорты. Балалары: Айзилә (2000), Илвир (2005). Яңа йорт салдылар.

№ 14. Шәрәфетдинов Зәет Нурулла улы (1941–1997) белән Нурмиева Миннехаҗәр Нурми кызы (1933–2016) йорты. Балалары: Гөлфия (1953), Әлфия (1953). Хәзерге вакытта Елистратова Әлфия Васыйл кызы (1953) яши.





№ 15. Галимов Габдрахман Идиятулла улы (1928–1999) белән Галимова Хәдия Вагыйзь кызы (1928–2003) йорты. Балалары: Габдрахман, Галия (1930–2017), Габдрәүф, Оркыя, Рафига. Низамов Гаяз Низаметдин улы (1928–1987) белән Низамова Галия Идиятулла кызы (1930–2017) йорты. Балалары: Венера (1957–2009), Нияз (1959), Марсель (1966). Нияз яши.



№ 16. Хакова Мөгаздадә Әхмәделхак кызы (1910–1984). Малае Салихов Галимжан нигезе. Камалов Әзһәр Зиннур улы (1929–1974) белән Хәлиуллина Сабира Хәлиулла кызы (1924–2015) йорты. Балалары: Люция (1950), Суфия (1953), Альбина (1960). Йорт буш тора.





№ 17(а). Минһажев Дамир Мәүҗетдин улы (1961) белән Минһажева Роза Рифкат кызы (1964) йорты. Балалары: Эльмира (1987), Эльвира (1988), Данир (2005).



№17. Гайфуллин Илгизәр Талибулла улы (1938–2013) белән Гайфуллина Нурлыхода Мөхәммәтдин кызы (1941-2020) йорты. Балалары: Наилә (1963), Раилә (1964), Илдар (1966)



№ 18. Хаков Тәлгать Әхмәделхак улы (1918–2005) белән Зөһрә апа нигезе. Балалары: Рифкать, Нурия (1950–2017). Габдуллин Мөнир Габдулла улы (1954–2018) белән Габдуллина Рәмзия Нурмөхәммәт кызы (1957) йорты. Балалары: Марат (1977), Ирек (1980), Алия (1988).



№ 19. Абдуллина Мөсаппиха Лотфисорур Сәхипҗан кызы (1918–2004) нигезе. Йосыпов Миннәхмәт Хөсәен улы (1935–1979) белән Йосыпова Нурия йорты. Балалары: Алфир (1972), Мизхәт (1975). Нигез буш тора.



№ 20. Шәйдуллин Лиф Хөснелгата улы (1934) белән Шәйдуллина Зәкия Җаббар кызы (1938) үз йортын тыкрык урынына күчереп салды. Йорт буш тора.



№ 21. Вәлиуллин Хөснулла Вәлиулла улы (1889–1978) белән Вәлиуллина Хупҗамал Габдулла кызы нигезе. Балалары: Гыйздулла, Әхтәм, Асия, Хәйдәр, Зиннәтулла (1909–1983) Хөснуллин Зиннәттулла Хөснулла улы (1909–1983) белән Хөснуллина Тәгъзимә Муллагали кызы (1925–2000) йорты. Балалары: Рәис (1949–1993), Тимергали (1949–2019), Фәнис (1952–2001), Тәнзилә (1958–1994), Зәкәрия (1956). Зәкәрия Зиннәтулла (1956) улы белән Хөснуллина Илдания (Илфия) Тәкыйулла (1958) кызы тора. Балалары: Илнур (1979–2009), Ленар (1983)

№ 22. Галимов Нигъмәтулла Мөхәммәтгалим улы (1921–1978). Галимов Идиатулла Мөхәмәтгалим улы (1904–1980) белән Галимова Әсма Сәхбетдин кызы (1906–1996) нигезе. Галимов Мөхәммәтулла Мөхәммәтгалим улы (1914–1992) белән Лотфуллина Асия Лотфулла кызы (1922–2006) йорты. Балалары: Камил (1946), Гөлфизә (1952), Гөлфирә (1954), Рәмилә (1956), Суфия (1958), Шамил (1961), Равилә (1964). Галимов Шамил Мөхәммәтулла улы (1961) белән Галимова Розалия Фоат кызы (1975) яши. Балалары: Эльза (2010).





№ 23. Гайсә кызы Мөгаллимә (1917–2000) – әтисенең сеңлесе. Гайсина Гайниямал Габделҗәлил кызы (1898–1982) – әнисе. Иксанов Рафаил Габделиксан улы (1940–2016) белән Иксанова Фалия Гимазетдин кызы (1943) йорты. Балалары: Илгиз (1964–1996), Гөлтавис (1966–2001), Раил (1968–1973), Фирая (1973), Илмир (1976), Рөстәм (1980).



№ 24. Хафизов Нурмөхәммәт Әхмәтхафиз улы (1925–1983) белән Хафизова Фатыйма Мәүләветдин кызы (1927–2007) йорты. Балалары: Расих (1952), Рәмзия (1957), Сәрия (1959), Рәшит (1961–1984), Марсия (1964), Разин (1965), Рамил (1967).



№ 25. Харисов Варис Мазһар улы (1957) белән Харисова Оркыя Идиятулла кызы (1935–2014) йорты. Шириева Розалия Равил кызы (1971) яши. Балалары: Илдар (2000).



№ 26. Сәйфуллин Госман Әһлиулла улы (1936) белән Сәйфуллина Фәндия Нурислам кызы (1939–2017) нигезе. Балалары: Энҗе (1962–2006), Айрат (1964), Илфак (1965–1996), Илсур (1974), Илшат (1981–2011).



№ 27. Шакирова Мөкәррәмә Шакир кызы (1924 ?–197 ?) Шакирова М-Бәдәр Шакир кызы (1910–1985). Шакиров Әнвәр Шакир улы (1920–1962) белән Шакирова Бибигайшә Шакиржан кызы (1923–2012) нигезе. Балалары: Фәрит (1942–2011), Альберт (1952), Ринат (1956), Альфира (1958), Әлфия (1961) Шакиров Ринат Әнвәр улы белән Шакирова Гөләмзия Фәрит кызы (1980) яши. Балалары: Радик (1978), Гөлнара (1980), Гөлназ (1984)



№ 28. Бахманов Мөхтәр белән Сәхбетдинова Нуриәсма Сәхбетдин кызы йорты. Хәзер читтән килеп сатып алдылар, ялга гына кайтып йөриләр.



№ 29. Галимова Әсма Сәхбетдин кызы (1906–1996) Идиятов Гәбдрәүф Идият улы (1932–1997) белән Идиятова Илгизә Шәйхрам кызы (1947–2009) йорты. Балалары: Илфат (1968), Альбина (1972), Фаяз (1973–2017), Илмира (1975), Фәнис (1978), Индира (1985). Идиятов Фәнис Габдерәүф улы (1978) белән Идиятова Мөнирә Рафаэль кызы (1981) йорты. Балалары: Мәрьям (2012), Мәликә (2014).



№ 30. Закирова Өммегөлсем (1926 – вафат). Балалары: Зөлфия (1949), Хыйммәт (1952), Сәүдия, Каюм (1956)



№ 31. Салахиев Зилбар Нургали улы (1941) белән Салахиева Мозаллия Хафиз кызы (1951) яши. Балалары: Илдар (1978).

№ 32. Хәмидуллин Нурмөхәммәт Хәмидулла улы белән (Мөхтәр абыйның абыйсы) Хәмидуллина Халисә нигезе. Балалары: Мөхәммәтулла (1939), Нуриәхмәт, Халидә, Хакимә, Мирсәит, Рафис, Радис. Варданян Екатерина Евгений кызы тора (сатып алган).



№ 34. Шәйхелисламов Ислам Шәйхелислам улы (1915–1996) белән Латыйпова Махрибикә Латыйп кызы (1918–1992) йорты. Балалары: Фирдәвес (1961–2018), Гөлзирә (1965). Йорт буш тора.



№ 36. Мостафин Мөнир Мортаза улы (1930–2010) белән Мостафина Мәсхудә Ахунҗан кызы (1927–2015) нигезе. Балалары: Венера (1952), Розалия (1956), Алфира (1958). Өй буш тора.





№ 33. Хөсәенов Ринат Наил улы яши Венера Дмитрий кызы белән. Балалары: Айсылу (2001), Рифат (2006), Айгөл (2012).



№ 35. Сәйфуллин Илсур Госман улы (1974) белән Сәйфуллина Вәсимә Әгъзәм кызы (1971) яши. Балалары: Алсу (1997), Язилә (2005).



№ 37. Харисов Сәгыйт Харис улы (1920–1989) белән Харисова Мәймүнә нигезе. Харисов Зөфәр Харис улы (1925–1972) белән Харисова Рәйхана Сабир кызы (1927–1998) йорты. Балалары: Илгизә (1948), Рим (1950), Рәшит (1952), Римма (1954), Диләрә (1957), Индира (1966), Заһир (1968). Харисов Заһир Зөфәр улы (1968) белән Харисова Сиринә Сәгадәт кызы (1967) йорты. Балалары: Гөлназ (1983), Илназ (1986).

№ 38. Гайфуллин Ахияр Салих улы (1938–2006) белән Гайфуллина Зөләйха Абдулла кызы (1927–2005) йорты. Балалары: Нәҗибә (1951), Илмира (1965). Нигез буш тора.





№ 39. Солтанов Нургали Арслан улы (1924–1964) белән Солтанова Мәликә Шәрәфетдин кызы (1923–2007) йорты. Балалары: Нурия (1950), Рафаэль (1951), Сиринә (1959), Марсель (1961).

№ 40. Фәрхетдинова Гайшә Фархетдин кызы (1909–1981), Яхьяның әнисе. Гомәров Яхья Фәхранур улы (1930–1997) белән Гомәрова Роза Насифулла кызы йорты (1933–1966). Балалары: Вәсилә (1953–1997), Зәнфәрия (1958), Ягъфәр (1960–2007), Зилия (1962), Гомәрова Мөнирә Фәйзулла кызы (1934) йорты. Балалары: Васил (1968), Резедә (1979).





№ 41. Әхмәтгәрәй улы Миңнәхмәт (1902–1962) белән Мөзәянә Әхмәтгәрәй кызы (1907–1978) нигезе. Харисов Рәшит Зөфәр улы (1952–2020) белән Харисова Флүрә Гаян кызы (1955) йорты. Балалары: Айгөл (1979), Алсу (1983).

№ 42. Заһидуллин Хәбибулла Даһидулла улы (1915–1992) белән Заһидуллина Мәхмүдә Дәүләтша кызы (1916–1984) нигезе. Балалары: Гөлдамия, Фәнир (1953), Нәзир (1953–2017), Заһидуллина Нурия Мәрдан кызы яши. Балалары: Раушания (1980), Ландыш (1986)





№ 43. Галиев Мәксут Гали улы (1927 – вафат) нигезе. Зәйнуллин Рамил Газиз улы яши. Мөнирә апа малае.

№ 44. Җәләев Мөдәррис Мөхәррәм улы (1930–1993) белән Кадыйрова Разия Габдрахман кызы (1929–1999) нигезе. Балалары: Фәнис (1959–2003), Рәмдис (1961), Рәмзия (1963), Фәридә (1966). Хәзер читтән килгән кешеләр тора.





№ 45. Миңһаҗетдин Камал улы (1905–1985) белән Сәгыйдә Фәррәхетдин кызы (1904–1989) нигезе. Балалары: Мөнҗия (Үзбәкстанда җирләнде), Мәгъсүм (очучы) Ташкент шәһәрендә җирләнде), Зәйнуллина Мөдирә Миңһаҗетдин кызы (вафат), Камалов Мисбах Миңһаҗетдин улы (1948–2004) белән Камалова Вәсимә Мәкъсүт кызы (1948) йорты. Балалары: Илнур (1972), Энҗе (1975). Бүгенге көндә Илнур яши.

№ 46. Сафиуллина Хәдичә нигезе. Нигез икегә бүленгән. Ярты сы № 44, икенче ярты сы № 48.



№ 47. Фатхуллин Мәхмүт Гомәр улы (1918–1988) белән Закирова Фәрдәнә Закир кызы (вафат) (Фая апа) яшәгән йорт. Балалары: Джек (1946–1973), Илгиз (1951), Илдар (1955–вафат), Бүгенге көндә буш.



№ 48. Җаббарова Мөнирә Җаббар кызы (1923–2006) Римасның әнисе. Җаббаров Римас Фазылян улы (1953) белән Җаббарова Гөлфинә Кәшиф кызы (1961) йорты. Балалары: Илфинә (1980), Илшат (1983), Айсинә (1984).



№ 49. Хафизов Бикмөхәммәт Мөхәмәтхафиз улы (1901–1992) белән Хафизова Рәйханә Әхмәтҗәләл кызы (1904–1979) нигезе. Балалары: Каюм, Әзбәр, Рәсимә, Рәмзия, Зөлфия. Шәйдуллин Вәлиәхмәт белән Шәйдуллина Гыйзденур Шәйдулла кызы (1913–2000) йорты. Балалары: Вәзир (1949). Шәйдуллин Вәзир Вәлиәхмәт улы (1949) белән Шәйдуллина Сәкинә Әхәт кызы (1956) йорты. Балалары: Лена (1976), Флүр (1979–1987), Ләйсән (1988), Ләйсирә (1989).

№ 50. Вәлиуллин Хөснулла Вәлиулла улы (1889–1978) белән Вәлиуллина Оркыя Әсәдулла кызы (1897–1982) нигезе. Хөснуллин Хаҗи Хөснулла улы (1926–1994), Хөснуллин Өлфәт Хөснулла улы (1934–2002) белән Хөснуллина Гөлфия Габделхәй кызы (1938–2010) йорты. Балалары: Фәйрүзә (1959), Илһам (1962), Альбина (1966).





№ 51. Минһаҗетдин улы Дөлфәт (1942–1972) нигезе. Гыймазетдинов Муллашәех Кираметдин улы (1936) белән Гыймазетдинова Фәһимә Минһаҗетдин кызы (1936–2017) йорты. Балалары: Наилә (1961), Рәмилә (1969)



№ 52. Бадихшан Нуретдин абый белән Рәшидә апа нигезе. Балалары: Заһретдин (1933), Яхъя (1940), Котдүс, Нажия. Салихова Фәнүсә Гариф кызы (1963) йорты. Балалары: Мирзанур (1997). Хәзер Фәнүсә улы Мирзанур белән яши.



№ 53. Мифтахетдинова Бәгъдинур Мифтахетдин кызы (1896–1994) нигезе. Балалары: Тәнфидә. Камалов Илфак Зиннур улы (1960) белән Камалова Тәслия Әзһәр кызы (1963) яши. Балалары: Илкам (1983), Ләйсән (1995).



№ 54. Хәбибуллина Нурикамал Хәбибулла кызы (1888–1964) нигезе. Балалары: Сабиржан (1923–1983). Насыйров Сабиржан Насыйр улы (1923–1983) белән Насыйрова Минҗиһан Хәмидулла кызы йорты. Балалары: Венера (1948), Зәмфирә (1951), Ринат (1952), Рөстәм (1955–1996), Разим (1959–2013). Хәзер Зәмфирә яши.



№ 55. Монасыйпов Әбүзәр Габделмәннан улы (1930–2009) белән Монасыйпова Әнисә Хәмидулла кызы (1936–2015) йорты. Балалары: Рамазан (1958–2013), Айдар (1964), Газинур (1965), Инсаф (1966), Булат (1971–2017). Салават (1977). Хәзер буш тора.



№ 56. Фаретдин бабай нигезе. Балалары: Мәсхүдә, Рабига, Сәүбән, Хаҗәр. Фәрдиева Рабига апа яшәде.



№ 57. Шәйдуллина Нәһерлеҗинан Хафиз кызы (1888–1976) нигезе. Шәйдуллин Нурулла Шәйдулла улы белән Шәйдуллина Гайнелҗинан Мөхәммәтсәлим кызы (1918–1999). Балалары: Нурия (1947–1966), Өлфәт (1948–2012), Вәзирә (1952), Нәзирә (1950), Рәшит (1955–1993), Нәфис (1959). Шайдуллин Рәшит Нурулла улы (1955–1993) белән Шәйдуллина Розалия Наил кызы (1961) йорты. Балалары: Ришат (1979), Рузилә (1984). Йорт буш тора.



№ 58. Сәхбетдинова Зәйнәп Сәхбетдин кызы нигезе (1909–1991). Салихов Айрат Галимҗан улы (1968–2018) белән Салихова Альбина Габдерәүф кызы (1972) йорты. Балалары: Илнар (1992), Алинә (1996), Руфинә (2011).



№ 59 Фәтхуллина Мәдинә Мөхәммәтхафиз кызы (1896–1957). Фәтхуллин Әбүбәкер Мөхәммәтхафиз улы (1887–1959) белән Фәтхуллина Маһиәнвәрә Шәйхетдин кызы (1901–2005) нигезе. 105 нче яшендә бакыйлыкка күчә. Балалары: Мөнәвәр (Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган), Бакиров Гамбәр Әбүбәкер улы (1940–2003), Фәүзия (1933), Ләбиб (1943–1999). Фәтхуллин Ләбиб Әбүбәкер улы белән Фәтхуллина Люция Тәлгать кызы йорты. Балалары: Данияр (1970), Нияз (1979)

№ 60. Шәйдуллин Хөснелгата белән Шәйдуллина Мөгаллимә Габдулла кызы (1902–1979) нигезе. Лифнең әнисе. Беляева Рауза Хөснелгата кызы (1928–2014), Шәйдуллин Лиф Хөснелгата улы (1934) белән Шәйдуллина Зәкия Җаббар кызы (1938) йорты. Балалары: Клара (1958), Линар (1961), Зинира (1965), Нияз (1970), Фәнис (1975).



№ 61. Йорт юк, бу урында Заляева Рәзимә апаның малае Суфиян яңа йорт сала.

№ 62. Шәймәрданов Габделгафур Шәймәрдан улы белән Шәймәрданова Зәкия Нургали кызы (1910–1997) нигезе. Шәймәрданов Илдус Гафур улы (1940) белән Шәймәрданова Нажия Әбүзәр кызы (1951) йорты. Балалары: Элмир (1972), Илнар (1978).



№ 63. Шәйхетдинова Мәрзия Шәйхетдин кызы (1911–2004). Балалары: Люция (1937), Фәния (1928–2015).



№ 64. Галиев Наил Миңнегали улы (1931–1959) белән Җәләева Рәзимә Нурулла кызы (1931) йорты. Балалары: Бәрия (1954), Әсхадулла (1957), Суфьян (1959). Гафуров Факил Гафур улы (1936–1987) белән Җәләева Рәзимә Нурулла (1931) кызы йорты. Балалары: Азат (1970).



№ 65. Шәмсиева Җәүһәрия Шәмсетдин кызы (1928–2003), Шәмсетдинов Мәксүт Шәмсетдин улы (1933–1999) белән Шәмсетдинова Илгизә Муллаян кызы (1939–2013) нигезе. Балалары: Ләйсирә (1962), Лилия (1964), Ләззәт (1965), Фәридә (1968), Марат (1975), Ләйсирә яши. Баласы Фәйрүзә (1991).



№ 66. Әхмәтҗанов Фиргат Хәйбрахман улы (1936–2007) белән Әхмәтҗанова Нуржиһан Заһидулла (1936) кызы йорты. Балалары: Гөлнур (1961), Гөлсинур (1962), Равил (1964), Нурания (1967), Гөлия (1973).





№ 67. Ганиева Мөсәббиха Гәбделгани кызы (1926–2004) йорты. Хәзер Сафина Габделгани кызы Гыйзденисаның малае Сафин Рамазан Әхмәдзыя улы (1956) яши.

№ 68. Абдуллин Әсгать Абдулла улы (1913–1997) белән Абдуллина Сабира Габделхак кызы (1915–1983) йорты. Балалары: Нәсибә, Факил (1941–вафат), Әминә (1948–вафат), Әнвәр (1951), Әнәс (1955). Йорт буш тора.





